Р. САФИН

ТАТАР ЮЛЫ

(татар язмышына геосәяси анализ)

«Иман» нәшрияте
Казан — 2001

Р. САФИН

ТАТАР ЮЛЫ

(татар язмышына геосәяси анализ)

«Иман» нәшрияте
Казан — 2001

МИЛЛИ ГЕОСӘЯСӘТ СЕРИЯСЕ

Җаваплы редактор —
тарих фәннәре докторы

Д. М. ИСХАКОВ

Басарга кул куелды 04.04.2001 Формат 60×90/16
Офсет басма. Басма табагы 6,75
Заказ № 100 Тираж 200.
«Иман» нәшрияты. Казан, К.Насыйри ур., 27.

© Издательство «Иман», 2001

ЭЧТӘЛЕК

Автордан 4

Кереш сүз 5

Геосәясәт: исеме һәм җисеме 9

Урталык җирләрендә гәосәяси дуализм чагылышы 28

Татар милли хәрәкәте геостратегиясе нигезләре 38

Милли үзтиңләнү мәсьәләләре 49

Милли идея 68

Татар күңеле — Далада 77

Татар исламы 87

Милли хәрәкәтнең тарихы сабаклары 93

Йомгаклау сүзе 100

Искәрмәләр 105

АВТОРДАН

Кешегә юктан бар итү кодрәте бирелмәгән. Бу китаптагы фикерләр дә буш җирдә тумады. Алар — милли хәрәкәтнең унике елын (1989–2000 еллар) үсеше җимеше. Милли хәрәкәтнең алдынгы сафларында катнашу тормышымны милләт язмышына, милләт киләчәген кешелекнекенә бәйләп күзалларга өйрәтте.

Китапның чыгуына «Татар юлы» җәмгыятендәге фикердәшләрем сәбәпле булды. Аларның терсәген тоемлау кыелык вә тәвәккәллек бирде. Рәхмәтләр яусын аларга! Аеруча Дамир Исхаков белән бертуганнар Фаат һәм Фәрит Уразаевларга рәхмәтем зур. Аларның киңәшләре кульязманы басмага әзерләгәндә бик тә игелекле булды.

Милли аңнары югары булган һәр милләтне үзенең язмышы, киләчәге, гомере озынлыгы кебек мәсъәләләр даилы кызыксындыра. Кешелекнең һәм милләтләрнең җәмгыяви үсеше турында төрле гипотеза-теорияләр әледән-әле туып тора. Берәүләр үз теориясен нинди дә булса биологик циклга бәйләп нигезли, икенчеләре икътисадый үсеш закончалыклары белән дәлилли, өченчеләре... Хәер, аларны санап торуның кирәге юктыр, чөнки, тарих күрсәткәнчә, алар берсе дә тулы хакикатьне чагылдырмый. Күрәсең, тулы хакикатьне адәми затлар белергә дә тиеш түгелдер — борынгылар әйтмешли, Аллага-Алланыкы, кешегә-кешенеке.

Инсаният яшәешенә кагылышы хакикатьнең кеше аналы җитәрлек өлешең Аллаһ безгә иләһи тәгълимат итеп иңдергән. Кешелек язмышы аның Коръән-Кәримдә бирелгән шушы тәгълиматы аңлап һәм дөрес кулланып яшәвенә бәйле. Аерып милләтләрнең исә яшәеше һәм аларның үзара мөнәсәбәтләрен билгеләүче иерархия баскычындагы урыны, шуның өстенә, аларның бу мәсъәләгә карата психологик куелышыннан да тора. Әлеге куелган никадәр югарырак булса, милләтнең дөнья сәхнәсендә тоткан урын да шул кадәр биек, гомере дә шул кадәр озын, тормышы да шул кадәр мул һәм яшәеше хәр була.

Татар иҗтимагый аңындагы үз киләчәгенә карата психологик куелышның югарылыгы да, киңлеге дә, томан артындагы маяк сыман, әле ачык күренми. Шуңа күрәдер, сәяси адымнарыбыз да адашкан юлчыныкын хәтерләтә. Әлбәттә, милләттәрвәрләрнең, киләчәгебез маягын ачык итеп күрәсе килә. Язмышыбызга геосәяш анализ әлеге томанны тарата кебек. Томан таралгач, киләчәгебезнең психологик куелышы Дала киңлегендә һәм татар исламы югарылыгында күренә. Татар киләчәген менә шулай күзаллау җәмәгатьчелек игътибарына да тәкъдим ителә.

Кайнадың син озак
Гел үз Казаныңда.
Күр, колак сал, ни бар
Дөнья базарында.

Илдар Юзеев.

КЕРЕШ СҮЗ

«Булыргамы яки булмаскамы?» — моннан дүрт гасыр элек инглиз даһиы, шагыйрь һәм драматург Уильям Шекспир сүзләре аркылы кешелек аерым шәхесләр язмышында менә шундый хәлиткеч моментлар булуын таныган. Өч гасыр үткәннән соң шундый ук проблеманың аерым җәмгыять алдында да туу ихтималлыгы танылган. Анысы татар даһиы Гаяз Исхакыйның милләтебез алдында нинди куркыныч туганын кисәтү аркылы эшләнгән («Ике йөз елдан соң инкыйраз»). Тагын бер гасыр узуга Җир Акылы әлеге проблеманың бөтен кешелек алдына килеп басканын танырга мәҗбүр — XX гасырның 80 нче елларыннан соң төрле гыйлем белгечләре, сәясәтчеләр бик зур борчылу белән хәзерге цивилизациянең глобаль кризис чорына керүен, инсаниятка юк ителү куркынычы янавы турында әйтә башладылар. Дөньяның бик югары дәрәҗәле галимнәре, проблеманы тану белән генә чикләнмичә, аны бергәләп хәл итү чараларын да эзли башладылар.

Бәхет юк иде, бәхетсезлек булышты дигәндәй, дөньяда туган бу вәзгыять татар кебек юк ителү куркынычы янаган милләтләрнең үз киләчәкләренә өметләрен арттыра төште. Ни өчен дисәң, кешелек хәзер үзен саклап калу һәм цивилизациянең алга таба да үсеш шартларын гарантияләү өчен аерым җәмгыятьләр (шул исәптән милләтләр) һәм шәхесләр ихтыяҗын да истә тотып эш итәргә мәҗбүр. Чөнки массакүләм юк итү коралларының күплеге һәм төрлелеге, куркыныч технологияләр үсеше, җәмгыятьтәге энергетик коралланганлык һ.б. цивилизацион казанышлар шундый дәрәҗәгә җитте ки, аерым төркемнәр, хәтта аерым шәхесләр дә Җир шарындагы бөтен тереклек яминлеген куркыныч астына куярга мөмкин (халыкара экстремизм-терроризм — шушы вәзгыять тудырган күренешләрнең берсе). Кыскасы, кешелек алдында торган проблема зурдан һәм аны хәл итүдә бөтен халыклар да (димәк, без дә) катнашырга тиеш.

Әлеге кризис нидән гыйбарәт соң һәм ул нәрсәдә чагыла? Дөнья галимнәре беренче урынга аның — экологиягә, икенче урын-

га — демографиягә кагылышлы ягын куя. Кайбер сәясәтчеләр һәм икътисадчылар җәмгыяви байлыкны вә табышны бүлешү һәм социализм җимерелүе сәбәпле туган вәзгыятьне дә аерым проблемалар итеп карау ягында. Алар барысы да бер-берсенә нык бәйләнгән, шуңа күрә, аларны бергә карау дөрес булыр.

Бүген Кешелек үзе яшәгән планетага — Җиргә мөнәсәбәте стратегик проблемага әверелде — аның алдындагы «булыргамы яки булмаскамы?» дилеммасы иң әүвәл шуның аркылы чишеләчәк. Дөнья икътисады торган саен күбрәк чимал таләп итә, әмма ул чикле. Дөнья җәмәгатьчелеге моны беренче тапкыр 1973 елгы энергетик кризистан соң танырга мәҗбүр булды. БМО белгечләре хисаплавынча, оптималь кулланганда Җирдәге чимал һәм энергия күләме 1 миллиард кешегә генә җитәрлек («Алтын миллиард»). Икенчел чимал (вторичное сырье) эшкәртүдә яңа технологияләр куллану нәтиҗәсендә бу санны 2 миллиард кешегә җиткерергә мөмкин. ЮНЕСКО белгечләре шуннан да югарырак нәтиҗәгә ирешү мөмкин түгел, дип саный [1]. Дөньяда исә инде бүген 6 миллиард кеше яши һәм халык сан ягыннан үсеп дәвам итә (50 елдан 9 миллиардка җитәчәк дип фаразлана) [2]. Бу үсеш башлыча артта калган илләр хисабына бара. БМО документларында җиһандагы бөтен халык өч өлешкә бүленә: «төп халык» (чимал һәм энергия белән тәэмин ителгән — «Алтын миллиард»), «ярым төп халык» (икенчел чимал хисабына тәэмин ителүчеләр) һәм «өстәмә халык» (тиешенчә тәэмин ителә алмаучылар). Алтын фондка АКШ, Япония, Көнбатыш Аурупа, Канада кебек илләр керә. Чимал һәм энергия куллану буенча башка илләр алардан шактый калыша. Мәсәлән, 1991 елда АКШта кеше башына 2614 кг нефть туры килгән булса, Һиндстанда — 62 кг, Эфиопиядә — 14 кг, Заирда — 10 кг [3]. Башка чимал белән дә шундыйрак хәл. Әгәр үсеп килүче илләр («өстәмә халык») бу мәсьәләдә алга киткән илләрне («Алтын миллирад»ны) куып җитәргә теләсә, чимал чыгаруны, төренә карап, 75–250 тапкыр арттырырга кирәк булыр иде. Бу исә якындагы ике дистә ел эчендә планетадагы чимал запасы бетүенә китерер иде. Бу — бер яктан. Ә икенче яктан, «өстәмә халык» та үз өлешен дәгъвалачак бит. Аларның таләпләре канәгатьләндерелмәсә, «ач Көньяк» (Африка һәм Көньяк Азия халкы) «бай һәм тук Төньяк»ны (ягъни Көнбатыш илләрен) чәйнәмичә йотарга мөмкин. Ачның ачуы яман дигәндәй, монда массакүләм юк итү кораллары да, идеологик кризис моның белән генә чикләнми. Байлыкны һәм табышны бүлү мәсьәләсендә аерым илләр арасында гына түгел, илләр эчендә дә тигезлек юк. Русиядәге

хәлләр турында без мәгълүматлы, ә бит дөньяның иң бай иле Американың үзендә дә бу мәсьәләдә гаделсезлек зур. Моны рәсми хакимият вәкилләре дә таный. Элекке вице-президент А. Гор АКШ «бүлү кризисы» алдында тора, дип раслый. Аның сүзләренчә, куллану-үзләштерүгә нигезләнгән базар системасы, нәфесне канәгатьләндерүгә генә корылган цивилизация Америка җәмгыятен алга таба үстерә алмый, хәтта бөтен планетаны өкренләп һәлакәткә илтә. Ул, әхлаксызлык һәм рухи кризис илгә куркыныч китерәчәк, дип кисәтә.

Бүгенге глобаль кризисның тирәнлеген чагылдыручы тагын бер фактор — ул реаль социализмның җимерелүе. Элегрәк кешелек дөньяның гаделсез тәртипләреннән котылуны социализмда күрә иде, социалистик идеяләр бөтен җир шарында җиңәр дә, кешелек глобаль кризистан котылыр, дип өметләнә иде. Өметләр акланмады. Күпләр, беренче чиратта «өстәмә халык», «туры» дип санаган юл бетте. Кешелек, җиде юл чатына килеп баскан юлчы сыман, аптыраш хәлдә калды. Татар кебек көчсезләр генә түгел, бик көчле илләр дә кризистан чыгу юлын күрми. Чөнки хәзер геосәяси конфликтларны элеккеге кебек көч кулланып хәл итү мөмкин түгеллеге һәркемгә ачык күренә. Югарыда китерелгән проблемалар кагылышы һәм аларны хәл итү сәясәт, икътисад һәм фән белән генә чикләнми, ә әхлак-әдәп, аң-зиһен, дин-иман сфераларын да колачлый. Глобаль кризистан чыгу өчен Кешегә яңа үзбәяләнү, кыйммәтләр иерархиясен алыштыру зарур.

Дөньяда чимал ресурслары җитми. Көнбатыш илләре бүген үз ихтыяҗларын башка төбәкләр (шул исәптән без яшәгән Урталык Җирләре) хисабына канәгатьләндерә. Шуның белән алар үзендәге системалы кризисны бер-ике дистә елга кичектереп тора алыр. Әмма ул аларны да читләп үтмәячәк, чөнки бу планетар кризис, бу кешелекнең куллану-үзләштерүгә нигезләнгән Көнбатыш культурасы гегемонлыгы астында формалашкан яшәеш системасы кризисы. Туймас нәфесне канәгатьләндерүне яшәү максаты дип санаган һәм табигатьне чиксез-чамасыз эксплуатацияләүгә корылган цивилизация үзенең соңгы фазасына керде. Инкарьне инкарь итү законы аңа да үз хөкемен чыгарды — инсаният үсешенең тиешле бер чорында уңай роль уйнаган бу цивилизация үзенең экологик катастрофалары, дәваларга бирешми торган авырулары, этник һәм социаль антогонизмы, дәүләтара, сәяси һәм дини конфликтлары белән бөтен биосферага юк ителү куркынычы тудыруы сәбәпле җир йөзеннән китәргә тиеш.

Заманның «бозыклыгын» — кешелекнең глобаль кризис кичерүен, без генә түгел, башкалар да таный, аннан чыгу юлын ке-

шелек, бөтен тереклек алдында үзен җаваплы санаган барлык милләтләр дә әзли. Әлеге җаваплылык татарга да хас. Ул дөньяга миссионер милләт итеп яралтылган. Шуның өстенә Аллаһы татарга бүгенге глобаль кризистан чыгу өчен иң отышлы идеологик тәгълимат та иңдергән. Ул — татар исламы.

Татар иҗтимагый фикерләвендә татар язмышын кайгыртуга, аның киләчәген билгеләүгә кагылышлы чыгышлар аз түгел. Әлбәттә, бу — уңай күренеш, тик бүгенге татар милли хәрәкәте моны үз активына яза алмый — бу мәсьәләдә безнең әле XX гасыр башындагы дәрәҗәдән югарырак күтәрелгәнебез юк. Монда төп ике кимчелекне танырга кирәктер. Беренчесе — милләт язмышына урыс-татар каршылыгыннан чыгып кына карау, икенчесе — киләчәгебезне үзебез яшәгән индустриаль чор тәртипләренә бәйле рәвештә күзаллау. Моны алга, киләчәккә караш дип булмый. Чөнки индустриаль чор үтеп бара, империяләр гомере дә озакка сузылмас. Безгә фикерләвебезне бүгенге тәртипләр белән чикләргә ярамый, ә, гасырлар аркылы карап, үзебезне меңъеллыклар дәверендә күрергә (һәрхәлдә, шуңа омтылырга) кирәк.

Акыл гыйлеме өйрәтүенчә, аерым шәхеснең дә, милләтнең дә тормышы үзе теләгәннән яхшырак була алмый, җәмгыятьтә дә башкалар тарафыннан бәяләнүләре аларның үзтәңгәлләнүенә (үзидентификациягә) бәйле. Шуңа күрә, киләчәк турында уйлаганда, милли максат планкасын югары куярга кирәк (һәм тормыш сыйфаты, һәм гомер озынлыгы ягыннан да). Әлбәттә инде, милләт стратегиясе комга корылган булмасын, илаһи кануннарга, дөнья үсеше тенденцияләренә нигезләнсен. Бу исә постиндустриаль чорда милләт язмышын бөтен кешелек үсешенә бәйләп караганда, бөтен Җир-анабыз турында кайгыртуны истә тотканда гына мөмкин. Димәк, без глобаль кризистан чыгу юлын эзләү хәр яшәүче алга киткән илләр-милләтләр эше, дип кенә карый алмыйбыз. Кешелек алдында әлеге кризис тудырган каршылыкны глобаль катастрофасыз үтүдә татар да үз өлешен кертә ала һәм тиеш.

Татар дәүләтләренең чәчәк аткан һәм җитлеккән заманнары да булган. Үз заманы өчен картайган чаклары да булган һәм алар корыганнар. Хәлбуки дәүләтчелек орлыклары югалмаган, алар безнең кендек җиребездә сакланган. Дым һәм җылылык җитмәү сәбәпле генә шыта алмый торган татар яңарышында корылык һәм салкынлык вакыты үтеп бара, үзенең ләйсән яңгырлары, саба җилләре белән яз килә. Әйтелгәннәр матур сүз яки татар милләтчесенең хыялый теләге генә түгел. Бу — җир йөзендә бара торган объектив тенденцияләргә, сәрешләргә (процессларга)

һәм татар язмышына геосәяси анализ нәтиҗәсендә кылынган раслау вә фаразлау. Моның белән килешү яки килешмәү — һәркемнең үз эше. Әмма тегe яки бу фикергә килү, әгәр ул геосәясәт фәне һәм дәүләтчелек үсешен анализлауда аның методологиясе нигезләре белән танышудан башланмаса, баш белән түгел, йөрәк белән фикерләү нәтиҗәсе булыр.

Бу хезмәт баш белән фикерләүче татарлар өчен язылды һәм түбәндәге темаларны тикшерүгә багышлана:

а) төбәктәге милләтара мөнәсәбәтләргә геосәяси караш;

б) төбәк үсешендә геосәяси закончалыклар чагылышы;

в) геосәясәт һәм татар милли хәрәкәтендә дәүләтчелек идеясе эволюциясе;

г) геосәяси үзтицләнү;

д) милли ихтыяҗлар, милли идея һәм татар геостратегиясе.

Геосәясәт милли мәнфәгатьләрне кайгыртуга хезмәт итә, ул — милләтчеләр фәне. Бу китапта да геосәяси анализлау татар милли хәрәкәте ихтыяҗын күздә тотып эшләнде. Ул бүгенге һәм якын киләчәктә туачак катлаулы вәзгыятьтә адашып калмау, империя эчендәге һәм тышындагы вакыйгаларны дөрес бәяләү, милләт мәнфәгатенә тәнгәл үсеш юлы сайлау өчен методологик кулланма буларак тәкъдим ителә.

ГЕОСӘЯСӘТ: ИСЕМЕ ҺӘМ ҖИСЕМЕ

Татар милли хәрәкәтендә милләт язмышына геосәяси караш әле формалашмаган. Хәтта термин буларак та, геосәясәт — безнең өчен яңа нәрсә. Геосәясәт термины соңгы вакытта гына киң кулланышка керде. Көнбатышта ул инде XX гасыр башыннан бирле фән буларак формалашып килсә дә, бездә аның белән киң җәмәгатьчелек СССР салкын сугышта җиңелгәннән һәм урыс империясенең тулысынча таркалу ихтималы туганнан соң гына таныша алды — державачылар аны үзләренә идеологик-сәяси корал итеп куллана башлады. Урыс телендә геосәясәт буенча беренче дәреслек 1997 елда чыкты [4]. Аңарчы аны югары хакимият даирәләрендә, Дәүләт иминлеге комитеты (КГБ) һәм !Баш разведка идарәсе (ГРУ) кебек үзгәле дәүләт органнарында өйрәнгәннәрдер, дияргә кирәк, чөнки СССРның тышкы һәм эчке сәясәтендә (бигрәк тә Сталин чорында) геосәясәт положенияләренең кулланышта булуы чагыла.

Сүзлекләр, белешмә китаплары, авторлар геосәясәт терминына аңлатманы төрлечә бирә [5]. Бүгенге публицистикадагы кулла-

нышы да бер генә мәгънәле түгел. Шуңлыктан әлеге терминның аңлатмасына тукталып үтү урынлы булыр.

Геосәясәт — ул дөньяга караш. Төгәлрәк әйтсәк, ул — дөньяга хакимият күзлегеннән булган караш. Ул — хакимият фәне, һәм хакимияткә хезмәт итүче фән. Гади кеше аны абстракция дип кабул итә, аның мәгънәсе һәм кирәклеге социаль баскычның югары басмаларына якынлашкач кына аңлашыла. Гәосәяст — сәяси элита фәне, аның белән илләр, милләтләр белән идарә итүче, бөтен дәүләт яки милләт мәнфәгатен истә тотып фикер йөртүчеләр шөгыльләнә. Ул — идарә итү фәне. Хаким милләтләр, дәүләтләр аны хакимлекләрен саклау һәм ныгыту-киңәйтү өчен, ә буйсынганнары азатлыкка ирешү өчен куллана. Шуңа күрә, империядә ул киң җәмәгатьчелектән яшерелеп килде. Татарда моңа кадәр геосәясәткә игътибар булмады, аңа ихтыяҗ милли хәрәкәттә дәүләтчелек идеясе үсеше нигезендә соңгы вакытта гына туды. Күпләр аны бүген дә кабул итә алмый. Хәлбуки, моны коллык психологиясе чагылышы яки иҗтимагый фикерләүнең гомуммиллӓт мәнфәгатьләре дәрәҗәсенә үсеп җитмәве белән аңлатырга кирәктер. Бу — субъектив фактор. Объективлык исә шунда: геосәясәт фәне положениеләрен инкарь иткән һәм кулланмаган хәлдә татар милли хәрәкәтенә дәүләтчелек идеясен гамәлләштерү мөмкин булмаячак, ул, мәдәни мәсьәләләр дәрәҗәсендә генә калып, хөрлек һәм азатлык турындагы хыялы үзе белән бергә сүнәчәк.

Геосәясәт законнары сәяси тарихны, дипломатия тарихын анализлау һәм стратегия планлаштыру өчен бик уңайлы. Ул, фән буларак, социология, политология , этнология, хәрби стратегия, дипломатия, диннәр тарихы һ.б. белән кисешә. Безнең заманда фәннәрнең синтезга тартылуы, фәнара макродисциплиналар тууы күзәтелә. Мондый шартларда теоретик тикшерүләр өчен дә, катлаулы цивилизацион сөрешләр белән (планета яки аерым дәүләтләр һәм дәүләтләр берлекләре масштабында) идарә итү өчен дә геосәясәтнең әһәмияте тагын да үсә төшә. Аның мәгариф өлкәсендәге ролен аерым күрсәтергә кирәк: милли максатка ирешү өчен тәрбия нинди булырга тиеш, дигән сорауга ул, милли сәясәтне билгеләүче корал (инструмент) буларак, бик ачык һәм төгәл җавап бирә. Геосәясәт — киләчәк заман фәне, аның актуальлеге торган саен яхшырак танылачак (бигрәк тә татар милли хәрәкәтендә).

Геосәясәтнең нигезен Җир (Коры) һәм Диңгез (Су) дигән ике төшенчә тәшкил итә. Алар арасындагы каршылык (геосәяси дуализм) геосәясәтнең төп принцибы санала. Геосәяси анализлау

методологиясе һәртөрле локаль сәяси вәзгыятьне шушы глобаль геосәяси дуализм чагылышы итеп карауны күздә тота. Нәкъ менә шушы ике стихия — Коры һәм Су — кешенең пространство турында күзаллавының нигезен тәшкил итә. Үзенең Коры һәм Суга, Җир һәм Диңгезгә карата кичерешләре аркылы кеше яшәешкә фундаменталь карашларын билгели: Коры — ул тотрыклылык, тыгызлык, береккәнлек, озынлык һәм күләм белән чикләнгән пространство. Су исә — хәрәкәтчәнлек, йомшаклык (сыеклык), динамика, вакыт. Бу ике стихия кеше өчен — асылда, табигатьнең иң ачык һәм аңлаешлы күренеше. Алар — кешедән тышта да (тыгыз һәм сыек матдәләр), аның эчендә дә (тән һәм кан). Һәм кеше үзенең тормышы-көнкүреше, иң әүвәл, аларның (Су һәм Корының) аңа карата булган һәм үзара мөнәсәбәтенә бәйле икәнен даими тоемлап яши. Ничек кенә булмасын, Коры, Җир, Су, Елга, Күл, Диңгез, Океаннар чынбарлыгыбызның төп категорияләре икәнен һәрберебез тоемлый, таный. Шул рәвешле әлеге ике стихиягә бәйле аерым шәхеснең дөньяга карашы, җәмгыятьнең (милләтнең) культурасы, цивилизацион традицияләре формалаша.

Су һәм Коры — геосәясәттә төп терминнар. Цивилизацияләргә һәм дәүләтләргә бәйле рәвештә алар «талассократия» һәм «теллурократия» терминнары белән бирелә. Геосәясәтнең төп законы Планетаның географик төзелешендә һәм цивилизацияләр типологиясе тарихында чагылыш тапкан фундаменталь дуализмны раслаудан гыйбарәт. Бу дуализм теллурократия («коры җир куәте») белән талассократиянең («диңгез куәте»нең) бер-берсенә каршы торулары белән билгеләнә. Шундый капма-каршылыкның характеры сәүдә цивилизациясен (Карфаген, Афина, Болгар һәм Казан ханлыклары) хәрби-авторитар цивилизациягә (Рим, Спарта, Русь-Московия) каршы кую аркылы гәүдәләндерелә. Җәмгыятьләр (милләтләр, дәүләтләр) тарихы «Су» («сыек» вә «агучан») һәм «Коры» («каты» вә «даими») стихияләреннән тора дип карала.

Теллурократия пространствоның чиклелеге һәм аның сыйфаты үзгәрмәүчәнлегенә (даимилегенә) бәйле. Цивилизацион дәрәҗәдә ул утрак яшәүдә, консерватизмда, кешеләрнең зур теркемнәрен (ыру, кабилә, милләт, дәүләт, империя) буйсындырып тотучы катгый юридик нормативларда чагылыш таба. Культурада Җирнең катылыгы этик-мораль нормаларының һәм социаль традицияләрнең ныклыгында чагыла. Коры җирдә яшәүче халыкларга индивидуализм, сәүдәгәрлек-эшмәкәрлелек — ят нәрсәләр. Аларга коллективизм һәм иерархиялелек (язмышны түрә-

ләргә — күпбаскычлы хакимият вертикале вәкилләренә тапшыру) хас.

Талассократия — капма-каршы типтагы цивилизация. Аңа динамизм, хәрәкәтчәнлек, техник үсешкә омтылу хас. Ул күчмә тормышка (бигрәк тә диңгез сәяхәтенә), сәүдәгә, шәхси эшмәкәрлеккә өстенлек бирә. Индивидум иң югары кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрелә, этик һәм юридик нормалар үзгәрүчән була. Андый цивилизация тиз үсеш ала, актив эволюция кичерә, эчке үзбәяләнүен саклаган хәлдә мәдәни билгеләрен җиңел үзгәртә.

Табигатьтә абсолютлык булмаган шикелле цивилизацияләрдә дә абсолют «чисталык» юк. Теге яки бу тип өстенлек иткән һәр цивилизациядә теллурократия чагылышларын да, талассократиянекен дә күрергә була. Кешелек тарихының күпчелек өлешендә (башлангыч чор) гәосәяси дуализм диңгез ярлары, елга бассейннары тирәсендә чикләнә. Ул чорда теллурократия глобаль өстенлек итә. Географик ачышлар эпохасында (XV гасыр азагыннан) талассократия дә мөстәкыйль планетар цивилизациягә әверелә (Бөекбритания, АКШ.

Автор белән укучы арасында аңлашуда төгәллеккә һәм фикерләүдә уртаклыкка ирешү максатында алга таба кулланылачак геосәяси терминнарны аныклап үтик:

Су (Диңгез) — талассократияне билгеләүче термин.

Җир (Коры) — теллурократияне билгеләүче термин.

Талассократия (грекчадан — «диңгез ярдәмендә килгән хакимлек» яки «диңгез куәте») — яшәешләре, башлыча, су (елга, диңгез, океан) аркылы аралашуга нигезләнгән дәүләтләр һәм халыклар (милләтләр) сыйфатламасы (характеристикасы).

Теллурократия (грекчадан — «коры җир ярдәмендә килгән хакимлек» яки «коры җир куәте») — геосәясәттә коры җир куәтенә таянучы державалар сыйфатламасы.

Геосәяси дуализм — талассократия (Су, Диңгез, Океан) белән теллурократия (Коры, Җир) арасындагы каршылыкны тарихи сәреш этәргече, дип раслаучы төп гәосәяси принцип.

Сакраль география — борынгыларның пространство сыйфатлары турындагы кузаллавы җыелмасы.

Киңлек (Пространство) — геосәясәтнең нигезен билгеләүче төшенчә. Геосәясәттә пространство күләм түгел, сыйфат билгеләүче категория (тарих структурасын, беренче чиратта сәяси тарихныкын, пространство структурасы билгели — геосәясәт фәненең төп тезисы менә шундый).

Пространстволар прогрессы законы (авторы Жан Тириар) — дәүләти пространстволарның шәһәр-дәүләтләрдән, дәүләт — би-

ләмәләр (территорияләр) аркылы, дәүләт-континентларга кадәр үсеше (хәзер инде соңгысының дәүләт-планетага әверелеп баруын күзәтәбез).

Зур Пространство — берничә дәүләтнең (державаның) бер сәяси-стратегик бердәмлеккә берләшүе.

Ауразия-Континет, Коры, Җир, теллурократия (таррак мәгънәдә, хәзерге геосәяси Русия).

Тарихның географик күчәре (Макиндер керткән) — Ауразиянең эчке континенталь биләмәләре, ягъни Урталык Җирләре (территориаль яктан хәзерге Русия биләмәләренә туры килә). Кешелекнең тарихи үсешендә пространство динамикасының шушы җирләр тирәсендә әйләнүен тәгъбирләүче термин.

Туран-Ауразия кыйтгасының төньяк-көнчыгыш өлкәләре, Ауразиянең дала киңлекләре.

Зур Татарстан — татар дөньясы.

Континент — Ауразия, Коры, теллурократик принцип

Көнбатыш — талассократия, атлантизм синонимы.

Ауразиячелек — тарихи яктан, кешелек цивилизациясенең көнчыгыш секторын, сәяси-стратегик яктан, либераль-демократик идеологияне танымаучы илләр (милләтләр) блогын, хәрби-стратегик яктан, теллурократик көнчыгыш илләрнең хәрби союзын, социаль яктан, базар системасын, капитализмны кире кагучы икътисадый стройны эченә алган катлаулы геосәяси төшенчә.

Атлантизм — ауразиячелеккә капма-каршы булган катлаулы (Су, Диңгез, талассократия терминнарына тугандаш) геосәяси төшенчә. Ул, тарихи яктан, кешелек цивилизациясенең көнбатыш секторын, сәяси-стратегик яктан, либераль-демократик идологияле Көнбатыш илләре союзын, хәрби-стратегик яктан, ТАКО (Төньяк Атлантик Килешү оешмасы) НАТОга кергән илләрне, социаль яктан, базар системасына нигезләнгән икътисадлы илләрне берләштерә.

Континентализм — ауразиячелек синонимы.

Либерализм — атлантистик лагерьдә хакимлек итүче дөньяга караш. Сәясәттә — гуманизм, индивидуализм, кеше хокуклары, этник һәм мәдәни тигез хокуклылык кебек сул кыйммәтләрне, икътисадтта — базар системасы, хосусыйлаштыру, шәхси милек, капитализм кебек уң компонентларны берләштерүче идеология.

Мондиализм (французча «monde-дөнья» сүзеннән) — дөньяда бөтен илләрне һәм халыкларны планетар бердәмлеккә җыюны күздә тотучы идеология.

Дөньяви Яңа Тәртип — мондиализм («Күптөрлелек бердәмлеге»).

Геостратегия — геосәяси ихтыяҗлар белән стратегик идарә итү (таррак, геосәяси анализның хәрби аспектлары).

Дошман (көндәш) — каршы позициядә торучы дәүләти, социаль, этник яки дини оешмалар җыелмасын белдерүче сәяси төшенчә.

Дус — бер үк позициядә торучы дәүләти, социаль, этник яки дини оешмалар җыелмасын белдерүче сәяси төшенчә.

Анаконда стратегиясе — Ауразиянең геосәяси экспансиясен чикләү максатында аның диңгезгә якын биләмәләрен аерып алуга юнәлтелгән атлантизм сәясәте.

Санитарлык кордоны — ике күрше дәүләтнең, бер көчле блокка берләшеп, өченче якка куркыныч тудыруыннан саклану максаты белән алар арасында тотрыклылыкны бозып тору ниятендә оештырылган гәосәяси бердәмлек.

Цивилизацияләр бәрелеше — Цивилизацияләр дәрәҗәсендә геосәяси конфликтларның даимилеге һәм бетмәячәге турындагы теория. (С.Һантингтон термины).

Геосәясәткә нигез салган, аны фән буларак формалаштырган классикларга һәм аларның төп фикерләренә кыскача тукталып үтик. Геосәясәт фәненең «атасы» дип нимес галиме Фридрих Ратцель (1844–1904) санала (гәрчә геосәясәт терминын кулланмаса да). Ул үзенең «Антропогеография» дигән хезмәтендә (1882 ел) халыклар эволюциясе һәм демографиянең географик җирлеккә бәйлелеген, аларның мәдәни һәм сәяси формалашуы рельеф йогынтысында баруын раслый. Аныңча, дәүләт — ул тамырлары җиргә береккән тере организм. Дәүләт, объектив яктан, географик барлыктан (җирлектән), субъектив яктан, әлеге барлыкны бу җирлектә яшәүче милләтнең (халыкларның) аңлавын чагылдыручы сәясәттән тора. Ратцель «нормаль» дәүләт дип географик, демографик һәм этномәдәни параметрлары табигый ярашуда булганнарын саный. «Нормаль» булмаган дәүләтләр кризис кичерә. Моны без татар тарихында да күрә алабыз. Мәсәлән, Алтын Урда дәүләте җимерелүе сәбәпләре арасында аның этнокультурасы һәм, эпидемиядән соң, демографик мөмкинлекләре географик урынына һәм киңлегенә ярашмауга килүен әйтергә кирәк (бу мәсьәләгә алга таба тәфсилләбрәк тукталырбыз).

Геосәясәт терминын беренче булып швед Рудольф Челлен (1864–1922) куллана. Аныңча, геосәясәт — дәүләтне пространствода гәүдәләнеш тапкан географик организм итеп караучы фән.

Геосәясәтчеләр арасында иң күренеклесе — инглиз Хэлфорд Джордж Макиндер (1861–1947). Ул үзенең «Тарихның географик күчәре» дигән хезмәтендә (1904 ел), дәүләт өчен географик урнашуның иң отышлысы — уртада булуы турында яза. Планетар күзлектән караганда, Җирнең уртасы — ул Ауразия кыйтгасы, ә аның уртасында — «дөнья йөрәге» (без яшәгән Урталык Җирләре). Аннан соң китә «эчке ярымай». Монысы Ауразия кыйтгасының диңгезләргә якын, яр буе пространстволары (аларны ул үзе керткән rimland термины белән атый). Аннан тагын да ераграк боҗра китә — «тышкы ярымай» яки «утраулар ярымае». Монда бөтен калган дөнья керә.

Макиндер раславынча, «эчке ярымай» иң интенсив үсеш алучы цивилизация зонасы булып тора. (Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, бу, цивилизация башта елгалар һәм диңгезләр ярлары буенда барлыкка килгән, дигән тарихи гипотезага да туры килә). Чөнки бу зона континенталь үзәктән дә, диңгез ярыннан да һөҗүм итеп торучыларга каршы даими көрәштә яши. Монда яшәүчеләр цивилизациясе ике капма-каршы культура йогынтысында формалаша: «дөнья йөрәге»ннән — Урталык Җирләреннән — килүче авторитар, иерархияле, демократик булмаган, сәүдәгә нигезләнмәгән континенталь культура (борынгы Спарта һәм Рим, безнең замандагы Русия империясе шундыйлар) һәм икътисадта сәүдәгә, сәясәттә демократик тәртипләргә нигезләнгән «тышкы ярымай» культурасы (борынгы заманда Афина, Карфаген, хәзерге заманда АКШ, Англия, Көнбатыш илләре шундыйлар). Менә шундый ике капма-каршы цивилизацион — географик йогынты арасында булуы сәбәпле «эчке ярымай» зонасы иң елгыр шәхесләр, иң хәрәкәтчән җәмгыять формалаштыра һәм приоритетлы цивилизация үсеше урынына әверелә.

Болгар ханлыгы һәм аның дәвамчысы Казан ханлыгы (гомумән, Идел-йорт) шундый зонага кергән — алар да Коры һәм Су юллары белән килгән төрле цивилизацион импульслар һәм Судан (әйтик, варяглар, славяннар, ушкуйниклар) һәм Корыдан (мәсәлән, хәзәрләр, урыслар тарафыннан) оештырылган һөҗүмнәр нәтиҗәсендә дәүләти-мәдәни җәмгыять булып формалашкан.

«Тарихның геосәяси күчәре» ролен күрсәтеп, Макиндер кешелек цивилизациясе үсешендә монда яшәгән төрки халыклар (һуннар, болгарлар, хәзәрләр, монгол-татарлар) әһәмиятен югары бәяли (гәрчә аларны варварлар дип атаса да). Мәсәлән, ул бүгенге тарихның зур өлеше Атилла җитәкчелегендәге һуннар

һөҗүмнәре тәэсирендә туган үзгәрешләргә комментарий буларак язылырга хаклы, дигән фикердә тора. Бу бит — хәзерге чорда өстенлек тоткан Көнбатыш цивилизациясе үсешенә төп этәргеч бирүче безнең борынгы бабаларыбыз булганын тану дигән сүз. (Без кешелек тарихында шундый хәлиткеч әһәмияткә ия булган геосәяси-цивилизацион мирасыбыз белән горурланырга хаклыбыз). Скифларны да ул, Гомер һәм Геродот хикәяләренә таянып, Далада соңрак яшәгән, ягъни, төрки кабиләләр белән бер раса вәкиле, дип саный.

Үзенең «Демократик идеаллар һәм чынбарлык» (1919 ел) дигән хезмәтендә геосәясәтнең төп законын Макиндер шулай билгеләгән: Көнчыгыш Аурупаны үз кулында тотучы «дөнья йөрәге»нә (Урталык Җирләренә) хуҗа була; «дөнья йөрәге»ндә өстенлек итүче «Дөньяви Утрау»да (Азия, Аурупа, Африка) өстенлек итә; «Дөньяви Утрау»да өстенлек итүче планета гегемоны була.

Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, АКШ һәм Көнбатыш илләренең, НАТО стратегларының планы һәм гамәле Макиндернең шушы законына нигезләнә: берничек тә Урталык Җирләренең геосәяси көчәюенә (элеккеге СССР биләмәләренең яңадан берләшүенә) юл куймаска, монда империячел көчләргә өстенлек бирмәскә, Аурaзиядә империя оешуын һәм аның экспансиясен (бигрәк тә Русия-Алмания союзын) булдырмаска.

Француз Видаль де ля Блаш (1845–1918), җирне (балчыкны) тикшереп җирлектә яшәүче халыкның характерын, холкын һәм җәмгыяви кыйммәтләрен белеп була, дип саный. Ул «поссибизм» («ихтималый» сүзеннән) концепциясен эшли. Әлеге концепция, сәяси тарих ике аспектка бәйле, дип карый: пространствога (географик аспект) һәм вакытка (тарихи аспект). Беренчесе потенциаль ихтималлык (объектив фактор) бирә, ә аны гамәлләштерү исә кешенең үзеннән тора (субъектив фактор). Ягъни, теге яки бу халыкның нинди булуы, ничек тормыш итүе үзе яшәгән җирлеккә һәм үзен ничек бәяләвенә (үзтицләвенә), җирлек биргән сыйфатларын актуальләштерүгә (аларның әһәмиятлелеген тануга) булган ихтыярына бәйле. Әйтик, татар халкы Идел-йортта (Агидел, Чулман, Нократ, Ука буйларында) яшәве сәбәпле талассократияга тартым rimland холыклы. Әмма ул үзен әле аңлап бетерми, үз язмышын һаман да теллурократик Русия империясе белән бәйләп күзаллый. Аяныч ки, бу аны империя белән бергә һәлакәткә китерергә мөмкин. Ә бит талассократик Көнбатыш цивилизациясе аның асылына якынрак, һәм ул шуңа йөз тотарга (бездә базар системасы урнашуын, Аурусоюз һәм НАТОның Көнчыгышка хәрәкәтен уңай бәяләргә) тиеш.

Милли яшәешебезнең (империядәге теллурократик тәртип) табигый холкыбызга тәңгәл булмавы милләттә эчке каршылык (дисгармония), үзенең киләчәгенә пессимистик караш тудыра, мәдәни үсешенә битарафлыкны көчәйтә, ассимиляциягә каршы тору сәләтен киметә. Болгар-татарларның күп кенә тискәре сыйфатлары (таркаулык, тарлык, кирелеккә чиктәш битарафлык-пассивлык, мескенлек, йомыклык һ.б.) яши торган җирлегебез биргән объектив мөмкинлекләребезне гамәлләштерү өчен субъектив шартлар булмавында. Бу сыйфатларның формалашуы халкыбызның милли аңында, теллурократияга (империягә) каршы көрәшү өметсез, дигән фикер урнашу белән башланды һәм шушы фикердән арынганчы дәвам итәчәк. Иҗтимагый аңыбызда, милли азатлык өчен көрәш мөмкин һәм тиешбез, дигән фикер өстенлек алу белән (әле аңа ирешкәнче үк), ягъни, үзебезнең rimland холыклы икәнлегебезне танып, табыгый эчке хәләтебез белән тышкы омтылышыбызны (гамәли ниятебезне) тәңгәлләштерү белән, мәдәниятебез үсешендә күзгә күренерлек уңышларга ирешә башлаячакбыз.

Америка геосәясәтчеләре Альфред Мэхэн (1840–1914) һәм Николас Спикмен (1893–1943) геосәясәткә географик күзлектән түгел, сәяси күзлектән карап фикер йөртәләр. Мэхэн фикеренчә, сәясәтнең төп инструменты — сәүдә, диңгез цивилизациясе — ул сәүдә цивилизациясе, Америка — «диңгез язмышлы» һәм аңа дөнья гегемоны булу өчен планетар диңгез державасына әверелергә кирәк; диңгез цивилизациясенең төп дошманы — Ауразиянең континенталь цивилизацияле державалары (беренче чиратта — Русия һәм Кытай, икенче чиратта — Алмания). Әйтергә кирәк, бу идеяләр АКШ геосәясәтендә кулланыш тапты һәм алар өчен уңышка да китерде.

Спикмен геосәясәтне халыкара сәясәттә иң отышлы стратегия билгеләү өчен аналитик ысул, зур сәясәтнең конкрет инструменты буларак бәяли. Макиндердан аермалы буларак, ул, планетар гегемонлыкка юл «дөнья йөрәге»нә хуҗа булу аркылы түгел, ә rimland аркылы, дигән фикердә тора. Макиндернең төп геосәяси законын ул үзенекенә алмаштырырга тәкъдим итә: «Rimland/та өстенлек итүче Аурзиядә өстенлек итә, Аурзияда өстенлек итүче дөнья язмышын үз кулында тота». Үзенең шушы законы позициясеннән чыгып, ул кулланышка «Урталык Океаны» дигән төшенчә кертә. Аның фикеренчә, Атлантик океан («Урталык Океаны») — Көнбатыш цивилизациясен берләштерүче фактор (борынгы заманда Урта диңгез Аурупа, Якын Көнчыгыш һәм Төньяк Африка культураларын берләштергән кебек).

Әлеге атлантик берләшмәнең нерв үзәге, аның көч-куәт механизмы булып үзенең сәүдә һәм хәрби-сәнәгать комплекслары белән АКШ тора. Көнбатыш Аурупаның сәяси мөстәкыйльлеге әкренләп кимергә, ә хакимият «атлантик пространстволар» (Көнбатыш илләре вәкилләрен берләштерүче һәм АКШ өстенлеге хөкем сөргән яңа органга күчәргә тиеш. (Соңрак бу идеяләр НАТО, Аурусоюз, Аурупа шурасы кебек органнарда гамәлләштерелде һәм алар Көнчыгышка хәрәкәтләрен дәвам итә).

Атлантизмга нигез салучы Америка геосәясәтчеләре Мэхэн һәм Спикмен идеяләрен үзенең тышкы сәясәтендә кулланып, АКШ салкын сугышта СССРны җиңүгә иреште һәм планетар гегемонга әверелде. Бу — геосәясәтнең дәүләтләр-милләтләр язмышында нинди зур әһәмияткә ия булуын раслаучы дәлилләрнең дәлиле.

Нимес геосәясәтчесе Карл Һаусхофер (1869–1946) доктринасы «континенталь блок» — «Берлин-Мәскәү-Токио күчәре» төзүгә багышланган. (Күрәсең, Сталин да бу идея белән таныш булгандыр һәм, шуңа ышанып, Икенче Бөтендөнья сугышы алдыннан Һитлер белән союзга кергәндер). Һаусхофер америкалы Гомер Ли сүзләрен еш кабатлый торган булган: «Нимесләр, урыслар һәм япуннар берләшсә, англосаксон сәясәтенең соңгы сәгате сугар». (Бүгенге урыс геосәясәтчеләре арасында да моны кабатлаучылар аз түгел). Ул нимес халкын, аның культурасын, Алмания дәүләтен Азия традициясенең көнбатыштагы дәвамы (чиге) буларак таный (инглизләр һәм французларның нимесләрне «һуннар» дип атаулары — дөнья җәмәгатьчелегенә билгеле факт)[6].

Һаусхофер, зур сәясәттә катнашкан шәхес буларак (үз вакытында ул Һитлерга да якын торган), үзенең доктринасын рәсми хакимиятнең расизм идеологиясенә яраклаштырырга мәҗбүр була — талассократия белән килешү вариантын кабул итә. Геосәясәт халыклар арасында уртаклыкны җирлеккә бәйләп эзли, расизм исә, расалар якынлыгыннан чыгып эш итә. Беренчесе күзлегеннән теллурократик менталитетлы нимесләргә азиатлар (урыслар, япуннар) якынрак, икенчесенекеннән — англосаксоннар (азиатлар исә — түбән дәрәҗәле һәм ариецларга буйсындырылырга тиешле раса). Шул сәбәпле фашистик Алмания сәясәтендә мантыйкый эзлеклелек сакланмый: башта геосәяси ихтыяҗ нигезендә СССР белән союз төзеп (Риббентроп-Молотов пакты), Англиягә каршы сугышка әзерләнә, соңрак, расистик караштан чыгып (бәлки, Макиндер законын да истә тотыптыр), СССРга һөҗүм итә. Геосәяси эзлексезлек, ахыр чиктә, Алманияне һәлакәткә китерә.

Политология һәм юриспруденция классигы немец Карл Шмитт (1888–1985) үзенең геосәяси концепциясе нигезе итеп «Халык хокуклары» («Volksrechte») идеясен ала (либераль «Кеше хокуклары» теориясенә каршы куеп). Аныңча, һәр халык мәдәни-мөстәкыйльлеккә һәм рухи, тарихи, сәяси (дәүләти) үзбилгеләнүгә хокуклы. Ул, халыкларның сәяси культурасы башлангычы пространствога бәйле, дип карый.

К. Шмитт геосәясәткә «номос» төшенчәсе кертә. Әлеге термин («номос» грекчадан — закон) пространствоны тәртипкә салынган, формалашкан, оешкан әйбер буларак күрсәтә. «Коры»га хәрәкәтләнмәүчәнлек, билгелелек (географик, рельефлы үзгәлекләрнең һәм коммуникацион юлларның даимилеге, чикләрнең билгеләнгәнлеге һ.б.) хас. Бу кеше психологиясендә дә чагылыш таба-социаль, мәдәни, техник-технологик карашта консерватизм тудыра. Шулай формалашкан традицияле җәмгыять «җир номосы» дип атала. Бу — Көнчыгыш цивилизациясе. Су пространствосы, Корыдан аермалы буларак, үзгәрүчән, билгесез, куркыныч (димәк, дошман). Анда даими ориентирлар юк, юллар күренми. Болар бөтенесе кешенең психологиясен тамырдан үзгәртә. Социаль, этик, юридик нормативларда «агучан», «хәрәкәтчән» булып формалаша — яңа цивилизация туа. Шмитт аны «су номосы» дип атый. Аның фикеренчә, индустриаль эраны тудыручы һәм яшәтүче, техник-технологик сикерешкә юл ачучы — нәкъ менә шушы «су номасы». Шмитт ике номос каршылыгы аркылы талассократиянең теллурократия белән берберсенә каршы торуына тарихи, идеологик һәм фәлсәфи мәгънә бирә.

Шмитт тагын бик мөһим геосәяси теорияне гамәлгә кертә. Ул — «Зур Простаранство» теориясе. Әлеге теория дәүләтләр үсеше сәрешен территориаль киңлекне максималь үстерү омтылышы итеп карый. Империя үсеше, дәүләтнең биләмәләре киңәюе этаплары кеше рухының табигый рәвештә универсальлеккә, берләшүгә, синтезга тартылуы этапларына туры килә. Әлеге тартылу икътисадый һәм техник үсешкә дә кагыла — аларның үсеше, билгеле бер дәрәҗәгә җиткәч, территориаль киңәюне таләп итә. Бу яулап алу, аннексия юлы белән дә (мәсәлән, Мәскәү Казанны яулап алган кебек), берничә дәүләтнең үзара килешеп, дини яки мәдәни уртаклык урнаштыру аркылы да эшләнергә мөмкин (әйтик, Болгар ханлыгы, ислам кабул итеп, Хәлифәт йогынтысындагы зонага кергән шикелле). Зур Пространстволар үсеше, шәһәр-дәүләт, территория-дәүләт, континент-дәүләт этаплары үтеп, ахыр чиктә, планета-дәүләт формасына җитәргә тиеш.

Урыс геосәясәтчеләренең беренчесе (һәм классиклардан берденбере) дип Петр Николаевич Савицкий (1895–1968) санала. Ул 1921 елда Н. С. Трубецкой белән бергә аурязиячелек хәрәкәтен җитәкли. Савицкий — Л.Н.Гумелевның остазы (алар сугыштан соңгы елларда төрмәдә бергә утыралар). Ул, Туран темасын күтәреп, монгол-татар явын уңай бәяли: «Россия обрела свою геополитическую самостоятельность и сохранила свою духовную независимость от агрессивного романо-германского мира». 1922 елны Савицкий «Степь и оседлость» дигән мәкаләсендә аурязиячелек идеясенең төп формуласын бирә: «Без татарщины не было бы России». Аныңча, Русия-Аураазия — ул Урман (Аурупа) һәм Дала (Азия) стихияләре синтезы буларак формалашкан цивилизация. П. Савицкий «Бүленмәс һәм бердәм Русия» идеясеннән чыгып фикерли. Аның «идеократия» принцибына нигезләнеп, урыс аурязиячеләре геосәяси дуализмга (Су һәм Коры каршылыгына) идеологик ачыклык кертүне тәгәллиләр: Су — либераль демократия, сәүдәгә (базар мөнәсәбәтенә) нигезләнгән җәмгыять, прагматизм; Коры — идеократия (матди мотивацияле булмаган, демократик һәм либераль тәртипкә нигезләнмәгән яшәү рәвешенең бөтен формалары), өстән аска юнәлтелгән иерархияле вертикаль ярдәмендә идарә ителүче җәмгыять, дини (православие) идеаллар өстенлеге.

Әйтергә кирәк, сәүит хөкүмәте тулысынча урыс аурязиячеләре идеяләренә таянып эш итте (гәрчә ул турыда ачыктан-ачык әйтмәсәләр дә). Бәлки, нәкъ менә шушы аурязиячелек белән марксизмнан уртак империячел (сәяси-хокукый, милли һәм дини тормышта гаять гаделсез) синтез булдырырга тырышу СССРны җимергәндер дә. Һәрхәлдә, Союзны һәлакәткә китергән сәбәпләрнең берсе — шул.

XX гасырның икенче яртысында геосәяси фикерләү үсеше геосәясәт фәненә нигез салучылар билгеләгән юлдан дәвам итә. Аңа бигрәк тә Америкада зур игътибар бирелә. Һәм нәтиҗәдә АКШ җитәкләгән талассократик Көнбатыш, кайнар сугышсыз гына, башында СССР торган блокны җиңүгә ирешә. Бүген Америка, киңрәк әйткәндә атлантизм, геосәяси диктаторга әверелде — дөнья үсеше ул билгеләгән геосәяси сценарийда бара. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, шул сәбәпле соңгы елларда «геосәясәт» термины публицистикада күбрәк «АКШ сәясәте» мәгънәсендә кулланыла башлады.

Салкын сугышта СССРның җиңелүе белән яңа тарихи эпоха башланды һәм җиңүчеләр алдында яңа геосәяси проектлар эш-

ләү ихтыяҗы туды. Салкын сугыштан соң хасил булган планетар геосәяси вәзгыятьне анықлау нәтиҗәсендә атлантистлар арасында кешелек цивилизациясенең киләчәген күзаллауда ике төрле концепция барлыкка килде. Беренчесе — атлантизм күзлегеннән, пессимистик караш. Ул дөньяның геосәяси йөзен элеккечә дуализмнан чыгып билгели, Көнбатышка каршы этник-мәдәни архетипларга һәм цивилизацион традицияләргә нигезләнгән яңа блоклар оешуы ихтималын фаразлый. Икенчесе — атлантизм өчен оптимистик караш. Ул, салкын сугышта Көнбатышның җиңүе тулы һәм тайпылышсыз, дип карый. Беренчесен «неоатлантизм» дип атыйлар. Аның иң күренекле вәкиле Самуил Һантингтон — АКШның Республика партиясе идеологы. Икенчесе «мондиализм» дип атала. Аңа нигез салучы чыгышы белән япун милләтеннән булган Америка ватандары Фрэнсис Фукуяма АКШның демократлар партиясе стратегиясен чагылдыра.

Һарвард университеты каршындагы стратегик тикшерүләр институты директоры С.Һантингтон концепциясенең асылы түбәндәгедән гыйбарәт. Континенталь көчләрнең төп таянычы булган СССРның җиңелүе — ул атлантизмның стратегик җиңүе генә. Бу цивилизацион җиңү (ягъни талассократиянең теллурократияне тулысынча җиңүе) түгел. Коммунистик идеологиянең җиңелүе белән либерал-демократия, базар мөнәсәбәтләре һ.б.ш. Көнбатышка хас кыйммәтләр планетар киңлеккә җәелсә дә, бу — вакытлы гына хәл. Озак көттерми Көнчыгышның цивилизацион һәм геосәяси үзәкләре үзләрен сиздерә башлаячак; халыклар арасында үзләрен төрле дин вәкилләре итеп тоемлау да көчәячәк. Моннан чыгып, Көнбатыш цивилизациясе дөньяның башка цивилизацияләренә каршы торырга әзер булырга тиеш. Көнбатышка каршы көчләр арасында Һантингтон беренче чиратта Кытайны һәм Ислам дөньясын күрә. Неоатлантизмның икенче күренекле вәкиле Пол Вольфовиц Көнбатышка каршы төп стратегик куркынычны Русия империясенең аякка басуында күрә.

Мондиализм концепция-буларак салкын сугыш беткәнче үк барлыкка килә, ә идея буларак, халыклар хыялында инде борынгыдан яшәп килә. Аның нигезендә кешелекнең үз үсеше идеалларын күзаллау ята: имеш, җитәр шундый заман, бөтен халыклар бер дәүләт-патшалыкка җыелыр, алар арасындагы антогонистик каршылыклар бетәр, конфликтларга-сугышларга урын калмас. Американың күренекле шәхесләреннән Морган һәм Рокфеллер кебек зур сәясәтчеләр — мондиализм тарафдарлары.

Мондиалистик проектлар күптөрле, төп вариантлары икәү: конвергенция теориясе һәм «тарих бетү» доктринасы. Беренчесен салкын сугыш чорында (70 нче елларда) Збигнев Бжезинский житәкчелегендәге аналитик төркем эшли, һәм ул геосәяси дуализмга алмашка капитализм-атлантизмның да, социализм-континентализмның да иң отышлы якларын үзләштергән яңа мәдәни-идеологик цивилизация төзүне күздә тота. Бездә Д. Сахаров та конвергенция тарафдары иде[7]. Икенчесе, СССР таркалып, салкын сугышта Көнбатыш җиңүеннән соң (90 нчы еллар башында) туды. Аның авторы — Фрэнсис Фукуяма. Аныңча, СССР җиңелүе белән кешелек тарихында караңгы, карагруһчылык, «көч законы» заманы, социаль чынбарлыкта иррациональ тәртип вакыты узды; аларга алмашка либераль-демократик идеологияле, базар системасына нигезләнгән икътисадлы рациональ Көнбатыш цивилизациясе — үзенең яшәү көчен күрсәткән капиталистик җәмгыяви строй урнашачак. Бу, кешелек тарихында геосәяси дуализм (талассократик һәм теллурократик цивилизацияләрнең бер-беренә каршы тору) чоры бетеп («тарих бетүе»), яңа планетар яшәү рәвеше — «Дөньяви Яңа Тәртип» урнашуга китерәчәк.

АКШ җитәкчелегендә Көнбатыш илләре уздыра торган агымдагы халыкара сәясәткә игътибар итсәк, анда атлантизмның һәр ике карашы (неоатлантизм һәм мондиализм) чагылышын да күрәбез. Моны, Яңа Тәртип тарафдарлары аерым бер генә версиягә өстенлек бирмиләр, вәзгыятькә карап төрле вариантта эш итәргә әзерләр, дип бәяләргә кирәктер. Бу җәһәттән С. Һантингтонның пессимистик һәм Ф.Фукуяманың оптимистик күзаллавы арасында булган Карло Санторо идеясе кызыклы. Ул җитәкләгән Халыкара Тикшерүләр Институты (ISPI — Милан) концепциясе фаразлавынча, мондиализм цивилизацион һәләкәтләр — катастрофалар аркылы урнашачак (һәлакәт арты мондиализмы — посткатастрофик мондиализм). Әлеге катастрофалар сценарие шулай күзаллана:

1) халыкара институтларның роле кимүе (бүген моны БМО мисалында күзәтәбез);

2) элеккеге Икенче (Варшава договорына кергән илләр) һәм Өченче (үсеш юлына баскан илләр) дөньяда милләтчелек тенденцияләре үсеп, моның чуалчык тәртипләргә китерүе;

3) моңарчы яшәп килгән традицион блокларның таркалуы (бу Аурупага кагылмый) һәм, нәтиҗә буларак, бүгенге дәүләтләрнең җимерелүе;

4) кечкенә һәм уртача көчтәге сугышлар аркылы яңа геосәяси

чынбарлык урнашуы (Югославия-Косово һәм Кавказ-Чечня сугышлары да бу калыпка сыя сыман);

5) планетар хаос куркынычы астында яңа халыкара институтлар ихтыяҗы туып, шуңа җавап буларак бик киң вәкаләтле Дөньяви Хөкүмәт урнашуы;

6) Дөньяви Хөкүмәт житәкчелегендәге планетар дәүләт оешуы.

Вакыйгаларның нәкъ менә шушы сценарийда үтү ихтималы зур, чөнки, Көнбатыш Аурупа илләренең рәсми хакимият вәкилләре эчке һәм тышкы сәясәттә атлантизм позициясеннән чыгып эш итсә дә, рәсми булмаган гыйльми даирәләрдә (димәк, җәмәгатьчелектә дә), Аурупаның киләчәген атлантизмнан аерып, аны Америка гегемонлыгыннан арынган мөстәкыйль континенталь Зур Пространство итеп күрергә теләүчеләр байтак. Мәсәлән, француз Ален де Бенуа фикеренчә, ул — төрле кимәлдәге милләтләр-этносларның тигез хокуклылыгы нигезендә оешкан «Федераль империя» (территориаль мәгънәдә); белгияле Жан Тириар күзаллавынча исә — Владивосток-Дублин киңлегендәге «Аурусовет империясе». Икенче белгияле Робер Стойкерс, Аурупа үзенең АКШ диктатына каршы стратегиясен Өченче дөнья (бигрәк тә гарәп илләре) белән берләшү һәм Һинд океанын үз контроленә алу юлы белән үткәрергә тиеш, дип саный. Итальян Карло Террачано Аурупаны антимондиалистик урыс-ислам блогы буларак күзаллый. Аныңча, Аурупаның Америка атлантизмына каршы көрәшендә төп рольне Русия белән берлектә Иран, Ирак, Ливия кебек теллурократик мөселман илләре альянсы уйный ала һәм тиеш. Урыс геосәясәтчесе А.Дугин да бу идеяне яклый.

Австрия парламентына соңгы сайлауларда көтелмәгән яклау табып, ярым нацист карашлары белән танылган Йорг Һайдер җитәкчелегендәге Азатлык фиркасенең коалицион хөкүмәт составына керүе дә антиатлантизм чагылышы дип бәяләнергә тиештер.

Салкын сугышта Көнбатышның җиңүе һәм СССР таркалуы нәтиҗәсендә дөньяда икеполярлылык заманы тәмамланды — берполярлылык урнашты. Атлантизмның югарыда китерелгән геосәяси проектлары барысы да, ахыр чиктә, Дөньяви Хөкүмәт җитәкчелегендә Дөньяви Яңа Тәртип урнашуын күздә тота: иртәме-соңмы Көнбатыш тибындагы универсализм өстенлек алачак, талассократик кыйммәтләр системасы доминантасы урнашачак. Әлеге проектларда Аурасиягә (геосәяси Зур Простарнство буларак) һәм урыс аурасиячелегенә урын юк. Һәм моның белән урыс державачылары да хисаплашырга мәҗбүр. Алай гына да

түгел, байтак геосәясәтчеләр олы империя (СССР) артыннан кечесенең (РФ) таркалуы ихтималын да фаразлый.

* * *

Геосәясәт — нинди генә фразеологик тышлыкка төрелгән булмасын, барыбер сәясәт инде ул. Һәр геосәясәтче үз иле, милләте, цивилизациясе мәнфәгатен кайгырта. Һәр геосәясәтче, милләтче буларак, кешелек үсеше сөрешен үз милләте-дәүләте ихтыяҗлары күзлегеннән күрергә омтыла. Шуңа күрә, киләчәкне фаразлау да, геосәяси проектлар да төрле. Шул ук вакытта аларның барысы өчен дә бер уртаклык бар: бөтен геосәяси концепцияләр дә, методологик яктан, тарихи дуализмга нигезләнә. Менә шушы планетар дуализм геосәясәтнең төп законы дип санала. Үзенең геосәясәттәге әһәмияте һәм урыны ягыннан аны физикадагы Җирнең тарту көче законы белән чагыштыралар.

Геосәясәт закончалыклары арасында икенче урынга «Зур Пространстволар законы»н куярга кирәктер. Геосәясәт дәүләтне «тере организм» итеп карый, дидек. Дәүләт тә тере организм кебек туа, үсә (киңәя, көчәя), картая һәм үлә. Җирдә беренче булып кала — дәүләтләр туа.

КАЛА-ДӘҮЛӘТЛӘР ЧОРЫ



Бу чорда халык саны аз булганлыктан алар тирәсендә «буш» җирләр күп. Шушы «буш»лык хисабына кала-дәүләтләр үсеп-киңәеп, дәүләт-биләмәләр барлыкка килә. Аларны региональ Зур Пространстволар диләр.

ДӘҮЛӘТ-БИЛӘМӘЛӘР ЧОРЫ



Башка буш җирләр юк, хәзер дәүләтләр үсеше биләмәләрне яңадан бүлү хисабына бара. Дәүләтләрнең көчлерәкләре, көчсезрәкләрен басып алып яки башкача буйсындырып (үз йогынтысы зонасына кертеп), империяләр төзи (континенталь Зур Пространстволар оеша).

КОНТИНЕНТАЛЬ ЗУР ПРОСТРАНСТВОЛАР ЧОРЫ



Алга таба империяләр үсеше аларның үзара көрәше аркылы бара. Бу көрәшнең төп этаплары дип Беренче һәм Икенче Бөтен-

дөнья сугышларын атарга була. Соңгысы нәтиҗәсендә Җиһан икегә бүленә, Коры-Су каршылыгы Планетаның глобаль каршылыгына әверелә: бер яктан — теллурократик-континенталь көчләр башында торучы СССР (Көнчыгыш), икенче яктан — талассократик-атлантистик илләрне җитәкләүче АКШ (Көнбатыш).

КОНТИНЕНТАЛЬ ЗУР ПРОСТРАНСТВОЛАР ЧОРЫНЫҢ СОҢГЫ ФАЗАСЫ



Зур Пространстволар үсәргә (йә үләргә) тиеш — бу тере организмның табигый яшәеш рәвеше. Алга таба үсеш икенче як хисабына гына була ала, һәм һәр ике як дөньяны яңадан бүлү нияте белән җиң сызганып Өченче Бөтендөнья сугышына әзерләнә башлый. Әгәр атом-төш коралы барлыкка килеп, аны куллану бер якны да җиңүгә китермичә, кешелекнең үзен юк итү куркынычы астына куймаган булса, ул башланган да булыр иде, мөгаен. Шөкер, ул салкын сугыш буларак кына үтте һәм талассократия җиңүе белән тәмамланды. Нәтиҗәдә, Планетар Зур Простанство оешуы чоры башланды.

ПЛАНЕТАЛАР ЗУР ПРОСТРАНСТВО ЧОРЫ



Югарыда әйтелгәнчә, аның оешу сценарие нинди булачагы төрлечә фаразлана, ә нәтиҗәсе бер төрле күзаллана: ул талассократик дөньяви яңа тәртип урнашуы, империяләр таркалып, мондиалистик цивилизацияле этник берәмлекләр барлыкка килүе, бер үзәктән идарә ителүче Планетар Империя (тик территориаль яктан) — «Күптөрлелек Бердәмлеге» төзелү белән йомгакланачак.

Татар милли хәрәкәте өчен искиткеч зур әһәмияткә ия булган тагын бер геосәяси закончалыкка аерым туктатырга кирәктер. Ул — Блашның милләт язмышында аның үзтиңләнүе (үзбәяләнүе) әһәмияте турындагы концепциясе. Милләт үзенең яшәгән җирлеге тәэсирендә формалашкан табигый сыйфатларын аңлыймы һәм аларны ничек бәяли, геосәяси ихтыяҗлары булырга тиешлеген таныймы һәм аларны канәгатьләндерү юлын ничек билгели, гомумән, дөнья халыклары арасында үзен кемгә тиңли, үзенең геотарихи вазыйфасын үтәү турында ни дәрәҗәдә кайгырта — аның гомере, тәрәккыяте, хөрлеге менә шуларга бәйле.

Геосәяси максатка ирешү, геосәяси ниятләрне үтәү һәрчак сугыш аркылы булды (элек тә, хәзер дә). Элек сугышта хәлиткеч рольне хәрби куәт уйнады. Андый сугышка әзерләнү, алып бару һәм нәтиҗәле тәмамлануының үз мантыйгы, үз кагыйдә-тәртипләре, классик ысуллары урнашкан иде. Аларны хәрби уку йортларында җентекләп өйрәнәләр иде. Бу — «дөрес» сугышлар иде. Хәзер геосәяси проектларны үтәүдә беренче планга «дөрес булмаган» сугыш чыга. XX гасырда «дөрес» сугышның төп таянычы хәрби сәнәгать комплексы (ХСК-ВПК) булды. Хәзер ул геосәяси көрәштә хәлиткеч рольне уйнамый. Моның иң ачык мисалы итеп СССР язмышын алырга була. Ул, «дөрес» сугышка әзерләнеп, дөньяда тиңе булмаган ХСК төзегән иде. Әмма «дөрес булмаган» салкын сугышта җиңелде. Хәзер цивилизацияләр көрәшендә тормыш сыйфаты югарырак булган, яшәү рәвешенең өстенлеген күрсәтә алган як җиңә. Бу җәһәттән гавәми мәгълүмат чараларының (ГМЧ) искиткеч ролен күрсәтми булмый. Хәзер сугышта катнашучылар көчен ХСК-ГМЧ-тирә-юнь мохит комплексы аркылы бәяләргә кирәк.

«Дөрес» (яки Зур) сугышны регуляр армия алып бара. «Дөрес булмаган» сугышта регуляр армия катнашмый, аның масштабы да зур түгел, каршы торучы яклар да глобаль конфликт чыгарырлык көчкә ия булмый Шуңа күрә, андый сугышларны иррегуляр, локаль яки кече сугышлар дип тә атыйлар [8]. Әмма нәтиҗәсе Зур сугышныкыннан да зуррак. Чөнки «дөрес» сугыш үзенең максаты итеп географик чикләре билгеләнгән пространство яулауны күздә тотса, иррегуляр сугыш бу яктан чиксез һәм төп-

сез. Ул — кеше миен яулауга юнәлтелгән психологик сугыш. Аның объекты — кеше аңы. Тик аңа карап кече сугышлар геосәяси категория булуыннан туктамый. Ни өчен дисәң, беренчедән, аларны зур геосәяси көчләр оештыра, икенчедән, ахыр чиктә аларның максаты барыбер — географик пространство. Аермасы шунда гына: элек гоесәясәттә Зур сугыш аркылы башта пространствоны яулап алып, аннан көч кулланып аны үзенеке итеп саклау күздә тотылса, хәзер әүвәл теге яки бу пространствода яшәүчеләрнең аңы «яулап» алына, соңра аларның теләге белән, ирекле рәвештә, пространство да геосәяси проект авторыныкы ителә.

Иррегуляр сугышларның формалары күптөрле: терроризм, психологик йогынты, тәрбия, дипломатия һәм разведка органнарының дошманга каршы оештырылган гамәлләре һ.б. Күп вакыт геосәяси проектлар авторлары тарафыннан андый сугышларның сәбәбе итеп каршы як дәүләт эчендәге этник, дини, социаль каршылыклар эшкә җигелә. Без моны бүген Русия империясен реформалауда кулланыла торган «ислам фундаментализмы» карачкысында, «чечен терроризмы», «татар ваһһабизмы» кебек уйдырмаларда да күзәтәбез. Татар милли хәрәкәте моны һич тә исеннән чыгармаска, сәяси беркатлылык күрсәтеп һәм төрле вәсвәсәләргә бирелеп, ят көчләр кулында курчак булудан сакланырга, үзенең геосәяси ихтыяҗларын аңлап эш итәргә тиеш.

Геосәясәткә менә шундый кыскача керештән соң татар язмышына геосәяси анализга да күчә алабыз. Анализны үзебез яшәгән төбәктәге милләтара мөнәсәбәтләргә геосәяси караш билгеләүдән башлыйк.

УРТАЛЫК ҖИРЛӘРЕНДӘ ГӘОСӘЯСИ ДУАЛИЗМ ЧАГЫЛЫШЫ

Кешелек үзенең тарихи юлын пространство һәм вакыт маяклары белән билгели. Геосәясәттә пространствоның иң мөһиме маяклары булып Коры, Су, «яр буе» (rimland) кабул ителгән, ә вакыт маяклары булып — Зур Пространстволар чорлары тора. Кешелекнең әһәмиятле өлеше булган татар язмышын да шушы маякларга бәйләп анализлау кирәк булыр.

Татарны кешелекнең әһәмиятле өлеше дип атау очраклы түгел (югарыда кешелек цивилизациясе үсешендә борынгы бабаларыбызның уңай йогынтысы турында геосәясәт классиклары фикере китерелгән иде). Ул безнең яшәү җирлегебез белән билгеләнә. Без яшәгән Урталык Җирләре геосәясәттә «тарихның геогра-

фик күчәре» дип атала. Геосәяси дуализм (Коры һәм Су цивилизацияләре көрәше) шушы күчәр тирәсендә әйләнә: Региональ Зур Пространство чорында — төбәктә хуҗа булу өчен, соңрак, Континенталь Зур Пространство чорында — Ауразияне кулда тоту өчен. Без хәзер Планетар Зур Пространство чорына кереп барабыз. Хәзер ничек соң, Урталык Җирләре үзенең әһәмиятен югалтмадымы — планетар берләшү монда яшәүчеләр проекты белән эшләнми бит?

Әйе, Планетар Зур Пространство оешуы АКШ (киңрәк, атлантизм тарафдарлары) геостратегик планнары буенча бара. Әлеге планетар геостратегия авторлары фикеренә колак салыйк. Атлантизм архитекторларының иң күренеклеләреннән берсе, политолог һәм политик Збигнев Бжезинский Ауразияне «Бөек шахмат тактасы» дип атый [9]. Аныңча, якындагы дистә елларда дөньяда Америка гегемонлыгы урнашуына һәм аны кабул итүгә каршы тору сөреше, башлыча, Ауразиядә булачак. Моннан 500 ел элек континентлар сәяси мөнәсәбәт урнаштырганнан бирле, Ауразия Җиһан үзәге булып тора. СССР таркалганнан соң беренче тапкыр Ауразиядә булмаган АКШ глобаль державага әверелә. Әмма бу Ауразиянең геосәяси әһәмияте бетте дип бәяләнергә тиеш түгел. Аның Көнбатышында (Аурупа) да, Көнчыгышында (Азия) да дөньяның мөһим сәяси һәм икътисадый куәте урнашкан. Шуңа күрә, Америкага Ауразияне үз контролендә тоту өчен яңа куәт төрләре (технологияләр, коммуникацияләр, мәгълүмат системасы, сәүдә һәм финанслар) өстенә геосәяси аспектларны да игътибарда тотарга кирәк. АКШ геостратегиясе, Ауразиядә өстенлек алырлык көндәш булдырмаска, дигән пинципта төзелергә тиеш.

Американың соңгы еллардагы тышкы сәясәтенә игътибар итсәң, әлеге принципның гамәлдә икәнлегенә шик калмый. Моны якындагы киләчәктә дөнья үсеше тенденциясе дип кабул итәргә кирәк. Ераграк киләчәк тенденциясен кешелекнең глобаль кризистан чыгу юлына бәйләп ачыкларга кирәк. Җиһан киләчәгенең якынында да, ерагында да безнең җирлек үз әһәмиятен югалтмаячак. Дөрес, Бжезинский АКШның бүгенге геостратегиясендә татар милли хәрәкәтенә турыдан-туры урын бирми (хәер, безнең үзебезнең дә дөнья җәмәгатьчелегенә геостратегик амбициябезне җиткергәнебез юк бит әле). Ә менә без яшәгән дәүләтне үз геостратегияләре булган актив илләр (Франция, Алмания, Русия, Кытай, Һиндстан) арасында күрә. Русия державачыларының геостратегик амбицияләре югарылыгын (АКШны юк иткәнче һәм дөнья гегемонлыгына ирешкәнче көрәшү) [10] истә тотып, атланти-

стлар иртәме-соңмы, татар милли хәрәкәтенә игътибарны арттырырга мәҗбүр булачаклар (әлбәттә, без геосәяси үзтицләнүебезне дөрес билгеләгән чакта). Үзләренең геостратегик максатларына ирешүдә өстәмә көч буларак һәр ике як (Русия һәм АКШ) татар факторын үз файдаларына кулланырга тырышачак [11].

Геосәяси сәхнәдә уйнаучы зур көчләр кулында курчак роленә канәгатьләнергә теләмәсәк, моннан без шундый нәтиҗә ясарга тиеш булабыз:

1) кыйблабызны ачыкларга — кем безнең дус һәм кем — дошман (геосәяси мәгънәдә);

2) милли хәрәкәтнең геостратегиясен (геосәяси максатка ирешү юлларын) билгеләргә;

3) милләтнең геосәяси ихтыяҗларын тәгаенләргә.

Менә шушы юнәлештә милләт язмышына геосәяси анализга керешик. Геосәяси кыйбла билгеләү өчен милләткә, иң әүвәл, үзтицләнү (үзбәяләнү) зарур. Русия империясе — классик теллурократия вәкиле, әле күптән түгел генә ул континенталь лагерьның башында булды, хәзер дә, аурaзиячелек идеясен гамәлгә ашырып, дөнья гегемонлыгына ирешү хыялыннан арынмаган. АКШ — чип-чиста талассократик көч, салкын сугышта җиңүгә ирешкән атлантизм җитәкчесе, де-факто дөнья гегемоны. Ә без кем? Үзебезне кайсы стихия вәкиле итеп танырга тиеш - Коры яки Су стихиялеме без? Коры стихияле империядә яшибез, әмма теллурократик менталитетлымы без? Юк, инде югарыда әйтелгәнчә, без rimland менталитетлы.

Беренче утрак тормышлы дәүләтебез Болгар ханлыгы һәм соңгы мөстәкыйль дәүләтебез Казан ханлыгы Идел-Чулман (борынгы бабаларыбыз атамасында, ягъни Идел-Агиделне бер елга санап) буенда урнашкан булуы сәбәпле аларның нәкъ менә шушы категориягә кергәнлекләрен истә тотып, «Яр буе зонасы»на тәфсилләбрәк тукталыйк. Иң әүвәл шуны искәртик, Идел-Агидел һәм Чулман буйларында яшәүчеләр культурасына килгәндә, rimland категориясен татарчалатып, аларны «Тугай» культуралы дип билгеләү табигый булыр. Rimland (һәм аның елга варианты «Тугай») — ике кисәктән торган җыелма пространство: потенциаль яктан, анда һәм талассоктария, һәм теллурократия фрагментлары булырга мөмкин. Бу иң катлаулы һәм бай эчтәлекле культура төбәге санала. «Тугай» зонасында, бер яктан Диңгез стихиясе, Су йогынтысы актив һәм ул динамикалы үсешкә этәргеч бирә, ә, икенче яктан, континенталь масса мәдәни энергияне тәртипләндерү — традицияләштерү юнәлешендә басым ясый. Бер яктан, «Тугай» Утрауга һәм Корабка әверелә (Дәрдемәнднең татар илен

Кораб образында күрүен генә искә төшерик)[12], икенче яктан — империягә һәм йортка (бу татар халык иҗатында «Идел-йорт» атамасы аркылы да чагыла)[13].

Rimland үз язмышына һәм үз тарихи ихтыярына ия. Әмма тарихи юл сайлауда ул геосәяси дуализм чикләреннән чыга алмый — сайлауда ирекле, ә сайлауга ике генә вариант бирелгән: йә теллурократия, йә талассократия. Башка юл юк — геосәясәтнең катгый законы шундый. Һәм бу — татар милли хәрәкәте өчен хәлиткеч әһәмияткә ия булган чынбарлык. Яр буе халыклары өчен дөрес юл сайлый белүнең әһәмиятен күрсәтүче мисал итеп XX гасырдагы Италия язмышын алырга була. Гасыр башында ул, Муссолинига ияреп, теллурократик ил буларак үзбәяләнде һәм фашистик Алмания белән союзга керде. Нәтиҗәсе фаҗигале булды. Сугыштан соң Италия, талассократик юл сайлап, кыска вакыт эчендә дөньяның иң алга киткән җиде иле арасына керде. Безнең алда да тарих шундый дилемма куя. Геосәяси классификациядә үзебезнең кем икәнлегебезне без, ерак тамырларыбызны барлап, бик дөрес бәяләргә һәм танырга тиеш.

Урталык Җирләре (Дала) — татарның кендеге ябышкан урын. Дала һәм аның уртасындагы Идел-йорт — безнең күңел тарткан җирләребез (земля обетованная). Борынгы бабаларыбыз Далада күчмә тормыш белән яшәгән. Гамәли яктан алар, диңгезчеләр диңгез кичкән кебек, дала кичкәннәр. Диңгездә дә, далада да билгеләнгән чикләр дә, даими ориентирлар да юк — барысы да «агучан», үзгәрүчән. Гамәли тормыш итүчеләр өчен тегендә дә, монда да чикләр офык белән генә билгеләнә, аның артында — билгесезлек. Бу куркыта һәм даими киеренкелектә тота, теләсә нинди көтелмәгән каршылыклар кичәргә әзер булып яшәргә, фикерләүдә һәм гамәлдә хәрәкәтчән булырга — динамизмга өйрәтә. Яшәү шартлары буенча Дала — Диңгезнең тыгызрак (катырак) варианты. Шуңа күрә, күчмә яшәүче Дала халкы Диңгез стихиясендәге кебек талассократик холыклы булып формалаша.

Диңгездәге сыман Далада да иҗтимагый аңда пространство (Далада — җир, Диңгездә — су) синеке дә түгел, минеке дә түгел, ул Тәңренеке (Аллаһыкы), ә куллану-файдалану өчен — Аллаһы яралткан барлык тереклекнеке. Менә шул сәбәпле, борынгы бабаларыбызда империячел омтылыш юк, ул кайбер төрки кавемнәрдә соңрак тирә-юньдәге империяләр йогынтысында барлыкка килә (мәсәлән, төрекләрдә — Византия йогынтысында). Ауразия суперкыйтгасында инде кала-дәүләт һәм дәүләт-биләмәләр чорлары үтеп, региональ Зур Пространстволар чоры башлангач, тирә-юньдә өч континенталь империя оешкан (Кытай, Персия,

Беренче һәм соңрак Икенче Рим империяләре), ә Далада геосәяси «бушлык», ягъни континенталь тәртип урнашмаган. Монда — талассократия өстенлеге. Империяләр «тере организм» буларак үсәргә-киңәергә тели, әмма Дала «бушлыгына» үтеп керерлек көч әле бирсендә дә җыелмаган. Беренче төрки империя барлыкка килгәннән соң (545 ел)[14] да Дала күрше империяләр өчен утраулар арасындагы диңгез ролен уйный — цивилизацион аралашу, сәүдә (Бөек Ефәк юллары) Дала аркылы уза. Күп гасырлар дәвамында Дала империяләр арасында баланс тота, шуның белән Ауразия кыйтгасының иминлеген саклый һәм үзенең талассократик гомерен озынайта. Бу безнең бабаларыбызга көч-куәт җыярга һәм Урталык Җирләрендәге географик-климатик яшәү шартларына тәңгәл үзенчәлекле, шул ук вакытта, күрше империяләрдән килгән төрле цивилизацион импульслар йогынтысында, толерантлы Дала культурасы формалаштырырга этәргеч була.

Зур Пространстволар үсеше законы Даланы да читләтеп үтми, әлбәттә. Урта гасырларда төрле цивилизацион юнәлештәге дәүләт-биләмәләр барлыкка килә башлый. Дала уртасында һәм, шуңа күрә, чит йогынтыдан бәйсезрәк булу сәбәпле, төрки культуралы Болгар дәүләте, Көньякта яһүди диндәге (бу динне кабул итү Якын Көнчыгышта ул вакыттагы иң куәтле ислам цивилизацияле Халифәт империясенә каршы тору теләге белән эшләнгәндер, күрәсең) Хәзәр каһанаты, Көнбатышта христианлык йогынтысында формалашкан Русь дәүләте оеша. Зур Пространстволар үсеше геосәяси дуализм (континенталь-теллурократик империяләрнең талассократик Далага каршы көрәше) аркылы бара. Континенталь импульс көчлерәк булып чыга. Нәтиҗәдә, Кытай ягыннан килгән импульс йогынтысында Алтын Урда оеша. Соңрак, талассократик Дала шартларында Көнчыгыш импульсы йомшый төшкәч, Көнбатыштан (Икенче Рим-Византия һәм Төркия ягыннан) килгән континенталь импульс өстенлек ала — Русия имерияе төзелә.

Далада теллурократиянең җиңүе белән Ауразиядә талассократиягә урын калмый. Суперкыйтга өчен бу «тарих бетүе» була. Талассократия, континентны ташлап, утрауга — Англиягә күчәргә мәҗбүр була (искәртеп үтик, Казан ханлыгы җимерелүе дә, Англиянең, континенталь яшәештән аерылып, үзен Диңгез стихияле дәүләт итеп тануы һәм бөек географик ачышлар юлына басуы да нәкъ менә XVI гасырга туры килә). Урталык Җирләрендә талассократиянең җиңелүе белән мондагы халыкларның үсешендә динамизм да кими. Дала халкы «дөнья куласасын әйләндерүдә» элеккеге ролен югалта. Талассократия исә, сыеграк

сферага (Даладан Диңгезгә) күчеп һәм хәрәкәтчәнлеген, аралашу мөмкинлекләрен арттырып, үзенең үсеш темпын тагын да югарырак баскычка күтәрә. Талассократик Англия, континентлар тирәсендәге су юлларын үзләштереп, диңгез державасына әверелә, шуның белән талассократия теллурократияне яр буйларыннан Ауразиянең эченә таба кысрыклый башлый (анаконда стратегиясе). АКШ, океан су юлларын үзләштереп, сәүдә-аралашуга хезмәт итә алырлык бөтен океаннар хуҗасына әверелгәннән соң талассократик көчләр үзәге Америкага күчә. Дөнья ике зур кисәккә бүленеп, гәосәяси дуализм каршылыгы глобаль характер ала. Бу глобаль капма-каршылыкта АКШның җиңүе белән атлантизм планетар өстенлеккә ирешә, талассократик Глобаль Зур Пространство оеша башлый. Һәм, шулай итеп, ниһаять, талассократия салкын кышларны читтә уздырган язгы кошлар күк, үзенең туган җире — Бөек Далага яңадан кайтты.

Ул югында Дала шактый үзгәргән — монда яңа хуҗа. Үзен тудырып үстергән Даланың элекке хуҗасын талассократия әле танып бетерми. Талассократия үзе дә бик үзгәргән, чит-ят җирләрдә йөреп, шактый баеган, бераз тәкәбберләнгән — элеккеге Дала хуҗасы да аны гел үз итеп бетерә алмый. Ләкин бу озакка бармас, җан тартмаса, кан тарта дигәндәй, алар бер-берсен танырлар — аларга башка чара юк. Чөнки талассократиянең элеккеге оясына теллурократия кунаклаган, һәм аңа яңа ояны Даланың тарихи хуҗасы ярдәмендә генә ясарга мөмкин. Бу хакыйкать татар милли хәрәкәте алдында торган геосәяси кыйбла билгеләү дилеммасын уңай хәл итү буенча нигез принцип булырга тиештер.

Татар юлында тарихи киртә булып Континенталь Зур Пространствоны (теллуроктарик империяне) яклаучы көчләр тора, һәм милләт язмышы шушы киртәне ничек кабул итүебезгә һәм киләчәк юлыбызны нинди вариантта сайлавыбызга бәйле. Бу мәсьәләдә татар милли аңы үсеше ике капма-каршы альтернатива алдында туктап калды: һаман да әлеге Континенталь Зур Пространство вәкиле булып яшәвебезне дәвам итәргәме, йә булмаса, Глобаль Зур Пространство вәкиле булуыбызны танып, милләтнең киләчәген планетар ихтыяҗлардан чыгып билгеләргәме? Беренче очракта без — табигый асылыбызга каршы булган теллурократия вәкиле, Русия империясен үзебезнең Ватаныбыз дип танып, аны саклауда катнашабыз, аның җимерелүенә борчылабыз-сыкранабыз, Аурусоюзның һәм НАТОның безгә килүеннән куркабыз, АКШ һәм Көнбатыш илләрен сәяси дошманыбыз дип санауны дәвам итәбез. Бу — коллык юлы. Ул татарны упкынга илтә.

Икенче очракта без, талассократия вәкиле булып, асылыбыз-

га кайтабыз, киләчәк язмышыбызны глобаль сәрешләрдән аерып карамыйбыз; урнашып килә торган Дөньяви Яңа Тәртип шартларын аңлап, оешып килүче Планетар Зур Пространствода үз кышшыбызны билгелибез; «Күптөрлелек Бердәмлеге»ндә «татар төрлелеген» саклау һәм үстерү чарасын күрәбез. Бу очракта Русия империясе безнең ил була алмый, ул без яшәгән ил була, ә Ватаныбыз дип үзәге Татарстанда булган Зур Татарстанны (кечесе) һәм Җиһанны (олысы), ә табигый союздашларыбыз дип АКШ һәм Көнбатыш илләрен таныйбыз; Русия империясе җимерелүен уңай сәреш дип кабул итеп, аның тизләтелүенә үз ярдәмебезне кертәбез; Аурусоюз һәм НАТОның Көнчыгышка хәрәкәтен безгә ярдәмгә килүе «икенче фронт» дип бәялибез. Ул чагында, «талассократик төп-йорт»ны саклаучы буларак, туган ягына әйләнеп кайткан талассократияне якты йөз белән каршы алып, аның ярдәмендә, узган заманнардагы кебек, дөнья куласасын Урталык Җирләре тирәсендә әйләндерүдә катнашу чараларын эзләргә тиеш булабыз.

Бүгенге күчеш чорында татар милли хәрәкәте алдында менә шундый хәлиткеч тарихи сорау куелган. Аңа нинди җавап бирүебез милләтнең киләчәк язмышын билгеләячәк. Беренче юлда безне һәлакәт көтә, икенчесе — татарны өченче меңъеллыкта дөньяның бөек халыклары рәтенә чыгаручы юл. Без Җиһанның талассократик Глобаль Зур Пространствога берләшү чорында яшибез. Бу — объектив тарихи сәреш. Аны беркем дә (шул исәптән Русиянең империячел көчләре дә) туктата алмаячак. Һәм, без милләт булып исән калыйк, кешелек цивилизациясе үсешенә үз өлешебезне кертеп, дөньяви сәяси сәхнәдә урын яулыйк дисәк, татар юлы талассократик юнәлештә булырга тиеш.

Дөрес, монда хакыйкатьне аңлап эш итү зарур. Әйе, татар өчен генә түгел, Русиядәге башка халыклар өчен дә бүгенге геосәяси вәзгыять бик мөһим альтернатива куя: кемгә йөз тотарга (талассократик көчләргәме, теллурократия тарафдарларынамы). Ләкин алар берсе дә халыкларга тулы суверенлык бирми һәм бирә дә алмый. Шулай да безнең өчен әлеге альтернатив вариантларның аермасы бар һәм ул менә нәрсәдә. Урыс итеге астындагы «Зур Пространство»ның нәрсә икәнен без инде беләбез: ул — империя. Анда либераль тәртипкә урын калмый, анда тоталитар тәртип кенә була (элеккеге самодержавие, большевизм яки бүгенге «федерализм»). Империя көч белән генә тотыла ала — либераль тәртип урнашса, ул таркала. Теллурократик империя милләтләргә үз теләкләре белән яшәү мөмкинлеге бирә алмый — бирсә, җимерелә (Алтын Урда кебек). Милләтләрне ассимиляция-

ләү — аның яшәү шарты. Империягә йөз тотсак, без аның хуҗасы урыска ияреп, державасын аякка бастыруда аңа хезмәтче булабыз һәм, империя ныгыгач, тәмам юк ителгәнче чукындырылачакбыз һәм урыслаштырылачакбыз. Атлантизм «Зур Пространство»сы да безгә ирек бирү өчен төзелми. Монда да татарның юкка чыгу ихтималы зур. Тик аерма шунда, бу очракта киләчәгебез өчен көрәшү мөмкинлеге кала. Чөнки ул Көнбатышның либераль-базар моделе үрнәгендә оеша. Монда һәркем үз тормышын һәм һәр милләт үз язмышын үзе кайгырта.

Шулай итеп, беренче очракта империя үсеше һәм яшәеше законнары нигезендә без объектив рәвештә ассимиляцияләнергә тиеш булабыз. Икенче очракта андый фатализм юк: саклану һәм тәрәккыять кылу яки башкалар тарафыннан йотылу милләтнең үзеннән тора. Бу очракта безнең өчен гыйбрәтле уңай мисал итеп Японияне алырга була. Икенче Бөтендөнья сугышында җиңелгәннән соң, теллурократик Япония атлантизм юлына басты һәм, андагы либеральлектән оста файдаланып, миллилеген саклаган хәлдә производствосын модернизацияләде. Ул — хәзер икътисадый-финанс системасы Көнбатышча, ә культурасы Көнчыгышча булган ил («вестернизациясез модернизация» моделе).

Бүгенге болгар-татар культурасына килгәндә, шуны искәртергә кирәктер: бездә талассократик импульс өстенлек итә. Татар дөньясы (Зур Татарстан) бүген — теллурократик империя чүлендәге талассократик оазис. Ул, күп гасырлар буе теллурократик богауларда яшәвенә карамастан, үзенең Су стихиясенә нигезләнгән менталитетын югалтмаган — анда динамизм, яңага тиз яраклашу, алга омтылу; аның иҗтимагый аңында — либерализм өстенлеге; гаделлек һәм демократия милли кыйммәткә әверелгән. Болар — барысы да талассократик культура чагылышлары. Җәдитчелекнең пәкъ менә бездә тууы һәм аның, гавәми киңлеккә җәелеп, милли хәрәкәт идеологиясенә әверелүе дә татарның талассократик культурага якынлыгы белән аңлатылырга тиеш — ул бит икътисадта капитализмны һәм базар системасын, социаль мәсьәләләрдә либерализмны кире какмаучы ислам тәгълиматына һәм гамәлиятенә нигез салучы хәрәкәт булды.

Инде килеп, милләт тарихына геосәяси анализ аркылы болгар-татар дәүләтләре җимерелүе сәбәпләренә тукталып үтик.

Бу уңайдан сүз башында ук шуны әйтү кирәк булыр: борынгы бабаларыбызның дәүләтләре котылгысыз рәвештә җимерелергә тиеш булган. Ни өчен дигәндә, югарыда әйтелгәнчә, аларның культурасы Су стихияле булып шәкелләнгән, ә яшәгән заманна-

ры Коры стихияле империяләр һәм Зур Пространстволар үсешендә континенталь көчләр өстенлек иткән чорга туры килгән. Әлбәттә, болгар-татар дәүләтләре язмышын бер генә сәбәп белән аңлату хакыйкатьтән ерак булыр, әмма монысы — беренчел сәбәп. Ул — яшәү җирлегенә (пространство) һәм яшәү чорына (вакыт) бәйле булган табигый (димәк, объектив) сәбәп. Бу — Аллаһы билгеләгән язмыш. Билгеле, башка сәбәпләр арасында да бик мөһимнәре бар (мәсәлән, Алтын Урдада империячел омтылышның йомшавы), ләкин алар — вакыт һәм пространство күзлегеннән, икенчел сәбәпләр. Сүзебез геосәяси анализ турында булганлыктан, аларга тукталып тормыйбыз.

Анализны бүгенге Казан татарларының беренче дәүләте Болгар ханлыгыннан башлыйк. Болгар ханлыгы, чын мәгънәсендә, талассократик ил булган — дәүләт куәтенең асылын сәүдә тәшкил иткән. Дөрес, халык сәүдәдән башка һөнәрчелек, игенчелек, терлекчелек белән дә шөгыльләнгән. Хәлбуки, аларның продукциясе дә үзләре үзләштерү өчен генә житештерелмәгән, сәүдәдә дә кулланылган (мәсәлән, урыс төбәкләренә һәм төньяк халыкларына икмәк сату фактлары тарихта мәгълүм. Ә Болгарда эшкәртелгән хайван тиресе һәм һөнәрчеләр ясаган булат кылыч үзләренең югары сыйфаты белән бөтен дөньяга билгеле булган).

Болгар ханлыгының Су стихияле булып формалашуына, күрәсең, ике фактор төп сәбәп булгандыр: башлангыч чорында борынгы төркиләр империясе традицияләрен дәвам итүче Хәзәрстанга буйсынган булуы (тарихи-сәяси фактор) һәм Урта Идел буенда урнашуы (географик-климатик фактор) — мондый яшәү шартлары империячел амбиция тәрбияли алмаган. Элегрәк тә болгарларда империячел омтылыш тәрбияләү шартлары булмый — алар «төркиләр тарихы» башыннан бирле (Л.Гумилев аны 545 ел белән билгели) мөстәкыйль дәүләт корып яшәми, тюркютларның Таң империясе таркалганнан соң Кубрат хан җитәкчелегендә төзелгән Болгар державасы да озын гомерле булмый [15]. 922 елда Болгар ханлыгында рәсми рәвештә Ислам кабул ителгәннән соң милләтебезнең яңа тарихы башлана. Бу вакыйганың әһәмияте татар әле торган саен югарырак бәяләчәк, чөнки шуның белән башта болгар бабаларыбыз, соңрак Алтын Урда дәүләтендә яшәгән һәм татар милләте формалашуында катнашкан кыпчак һ.б. бабаларыбыз, ислам цивилизациясен үзләштереп, үзләрен бәек цивилизация вәкиле дип бәяли башлый. Шундый үзтинләнү аларга үзләрен яулап алучылардан өстенрәк санарга һәм ассимиляциягә бирешмәскә ярдәм итә.

Болгар дәүләте Чыңгыз ханның беренче явына бирешми, әмма

Даланың һәм Иделнең сәүдә юллары монгол-татар кулына төшкәч, талассократик дәүләт буларак, аның киләчәк язмышы инде билгеләнә — ул җиңелергә тиеш була. Хәлбуки, бу рухи җиңелү булмый: ислам культурасының яулап алучылар мәҗүсилегеннән өстенрәк булуын тану җирле халыкка үз милли традицияләрен һәм югары милли аң саклауга нигез бирә (З.Бжезинский Чыңгыз хан империясе таркалуы сәбәбен монголлар культурасының яулап алынган халыкларныкыннан түбәнрәк булуында күрә). Болгар виляяте Алтын Урданың мәдәни һәм һөнәри үзәге булып әверелә (башлангыч чорда сәяси үзәге булып та хезмәт итә), шактый зур сәяси мөстәкыйльлеккә дә ирешә [16].

Талассократик болгар культурасының Алтын Урдада өстенлек алуы (Үзбәк хан заманында рәсми рәвештә ислам кабул итүне шулай бәяләргә кирәк), геосәяси күзлектән, континенталь империяне ныгытуга хезмәт итми. Хакимият башында торучы һәм Кытай импульслы монгол-татарларда үз чоры өчен бер геосәяси отышлылык була, ул — империячел омтылыш. Ә җирле халыкта (башлыча болгар һәм кыпчак) андый омтылыш булмый (Дала культурасы). Дәүләттәге менә шундый геосәяси капма-каршылык (теллурократик менталитетлы хакимияттә сәяси аң югарылыгы һәм милли аң түбәнлеге, талассократик табигатьле гавамдә исә, киресенчә, сәяси аңның түбәнлеге һәм этник аңның югарылыгы) эчке каршылыкны арттыра, дәүләт иминлеген какшата. Нәтиҗәдә, башта теллурократик дәүләт булып төзелгән Алтын Урда җимерелә. Бу Далада (димәк, Ауразия кыйтгасында да) талассократиянең соңгы җиңүе була.

«Болгар вилаятенең пайтәхете булган Казан»да [17] да дәүләт төзелешенә ике төрле караш саклана, чөнки, династия һәм гаскәр монгол-татарлардан булса, халык массасын башлыча җирле болгарлар тәшкил итә [18]. Казан ханлыгының югары катлам иҗтимагый аңында геосәяси үзтиңләнү үрнәге Кол Шәриф иҗатында ачык күренә:

Тәртип ике яклыдыр, һәм ул ике сүздә аңлатыла:
Дусларга гайрәт һәм дошманнар белән барып йөрешмәк.

Күрәбез, монда империячел омтылышның исе дә юк. Бу — бүгенге мондиализм концепциясенең асылын тәшкил иткән толерантлык чагылышы. Әлбәттә, мондый талассократик менталитетлы халык континенталь империяләр оешуы чорында җиңелергә тиеш була.

Казан ханлыгының көч-куәте сәүдәгә корылган була, һәм урыс дәүләте, аны җимерүне сәүдә юлларын үз кулына төшерүдән башлап, аның тамырын корыта.

Урыс тарихчылары, Мәскәүнең яулап алу сәясәтен яклап, Казанның Мәскәүгә каршы яу чабу очракларын китерә. Без исә, акланып, Мәскәү ягыннан андый яулар күбрәк булган, дибез. Ә мәсьәлә бөтенләй санда түгел, ә яуларның максатында. Казанлылар, яуларны үч алу һәм трофей өчен оештыра, яулап алынган җирләрне буйсындыру күздә тотылмый — алар бара да кайта. Мәскәүлеләр исә, империячел күзлектән, бик оста сәясәт алып бара, аларның максаты — пространство. Алар яулап алган җирләреннән кире китми, казык кагып, чик билгели, үзенеке итеп игълан итә, империяне киңәйтә-үстерә. Әшне үзенең төп дошманы булган Казан ханлыгының сәүдә юлларын үз кулына төшерүдән башлый: төньяктан Чулман, көньяктан Идел су юлын кисә, халыкара сәүдә ярминкәсен Казаннан Мәкәрҗәгә күчерә. Казан ханлыгы үзенең көч-куәт чыганагын югалткач, аның киләчәге инде хәл ителгән була.

Күрәбез, татарның дәүләти язмышы ачылыгы өчен милләтнең яшәгән җирлеге (Идел һәм Дала) һәм бабаларыбызның яшәү чорына (континенталь империяләр чоры) тәңгәл булмаган үзтиңләнүен «гаепләргә» кирәк. Ләкин без гаепләү юлына баса алмыйбыз, киресенчә, язмышыбызга да, бабаларыбызның, үз асылыбызга тугрылыклы калып, талассократик менталитет саклавына да рәхмәтле булырга тиешбез — Аллаһы татарны киләчәккә әзерләгән.

Татарның өметле һәм якты киләчәге бүген башлана. Киләчәгебезнең өметлелеге татарның культурасы, аның милли сыйфатлары һәм холкы Җиһанның талассократик берләшү чорына тәңгәл килүе, ягъни заманга яраклы булуы белән гарантияләнә.

ТАТАР МИЛЛИ ХӘРӘКӘТЕ ГЕОСТРАТЕГИЯСЕ НИГЕЗЛӘРЕ

Моннан алдагы бүлекләрдә үткәнебезгә кагылышлы бирелгән геосәяси анализ төп проблемага — киләчәкне фаразлауга һәм алдагы юлыбызны билгеләү мәсьәләсенә күчәргә нигез бирә.

Татарның киләчәген ике этапка бүлеп карау дөрес булыр: якын һәм ерак киләчәк. Алар бер-берсеннән якынрак һәм ераграк вакыт белән генә аерылмаслар, аларның төп аермасы кешелекнең иҗтимагый аңында цивилизацион кыйммәтләр алмашуына бәйле булыр. Якын киләчәк, бүгенге геосәяси тенденцияләрнең инерцион дәвамы буларак карала ала, ә гамәли яктан бүген күзалларлык ерак киләчәк инсаниятнең цивилизацион күчеш

чорына туры килер, дип фаразларга була. Беренчесен Урталык Җирләрендә Русия империясе кризисы тудырган вәзгыятьтән чыгып, икенчесен Планетар кризистан котылу юлына бәйләп фаразлау зарур.

Урталык Җирләрендә геосәяси дуализм бүген АКШ-СССР каршылыгының дәвамы буларак чагылыш таба. СССР таркалу белән әлеге каршылык юкка чыкмады, ул атлантизм белән аура-зиячелек көрәше шәкелендә концептуаль сферада дәвам итә. Америка дөньяда үз гегемонлыгын саклау өчен иң әүвәл Аура-зияне кулда тотарга кирәк икәнен яхшы аңлый, әмма монда зур проблемалар туу ихтималын да истә тота. Америка дөнья хакимлеге өчен хәлиткеч әһәмияткә ия булган дүрт өлкәдә өстенелккә ирешти: хәрби өлкәдә глобаль җәелү мөмкинлеге буенча аңа тиң юк; икътисадта тәп этәргеч ролен уйный (гәрчә Алмания һәм Япония бу өлкәдә конкурентлыкка дәгъва кылсалар да, алар башка өлкәләрдә АКШка көндәш була алмый); технологияләр мәсьәләсендә алдынгы техник һәм фәнни өлкәләрдә абсолют лидерлыгын саклый; мәдәнният өлкәсендә, үзенең примитивлыгына карамастан, бөтен дөнья (бигрәк тә яшьләр) аңа теләп тартыла. Менә шушы дүрт факторның бергә килүе Американы бердәнбер супердержава — дөнья гегемоны итә, дип яза З. Бжезинский. Бүген моны танымаучы юктыр. Ләкин тану моның белән килешү дигән сүз түгел бит әле.

Америка геосәясәтчеләре бу мәсьәләгә реаль карый. Алар төзегән глобаль геостратегия асылын менә нинди концепция тәшкил итә.

Ауразия кыйтгасының салкын сугыш тәмамланганнан соңгы геосәяси үзәкләренә үзтиңләнүдә ярдәм күрсәтергә һәм аларны сакларга. Моның гади телгә тәрҗемәсе ничегрәк була соң? Дөрес җавап табу өчен, «геосәяси үзәкләр» төшенчәсенә ачыклык кертик. Геосәяси үзәкләр дип Америка геостратегиясе авторлары геосәяси әһәмиятләре үзләренең куәтләре һәм омтылышлары белән түгел, ә географик урыннары белән билгеләнә торган, әмма актив геостратегияле державалар каршында зәгыйфь илләрне саный.

Актив геостратегияле державалар, ягъни АКШның глобаль ихтыяҗларына куркыныч янарлык дәүләтләр рәтенә америка720нар Франция, Алмания, Русия, Кытай һәм Һиндстанны кертә. Ә геосәяси үзәкләр роле, хосусан, Украина, Үзбәкстан һәм Әзәрбәйҗанга (Русиягә карата) бирелә. Хәзер инде әлеге концепциянең гади телгә тәрҗемәсе аңлашыла булса кирәк: Американың глобаль гегемонлыгына куркыныч янау ихтималы булган державаларга каршы геосәяси үзәкләр билгеләп, аларга, актив геост-

ратегияле державалар йогынтысыннан арынып, атлантизм юлына басарга ярдәм итәргә, аларны халыкара сәясәттә якларга һәм, кирәк калса, әлеге державалар экспансиясеннән дә сакларга.

Хуш, шулай булсын, тик татар милли хәрәкәтенә моның нинди кагылышы бар соң? Дөнья гегемоны геостратегиясенең принципиаль аспекты, аның асылын тәшкил итүче положение буларак, мондый концепция континенталь империяләргә каршы көрәшүче милли хәрәкәтләргә турыдан-туры кагыла. Шул исәптән — безгә дә: димәк, империягә каршы көрәштә без ялгыз түгел.

Урта гасырлардан бирле болгар-татар милли хәрәкәте, талассократик көч буларак, теллурократик көчләргә каршы бер ялгызы көрәште. Хәзер исә, дөньяда туган яңа геосәяси вәзгыятькә тәңгәл үзтицләнгән очракта, дошманымның дошманы — минем дустым, принцибында эш итеп, Хәлифәт белән союзга керү юлы белән мөстәкыйльлеккә ирешкән болгар бабаларыбыз үрнәгендә, безгә дә гасырлар дәвамындагы хыялыбызны гамәлләштерү мөмкинлеге туды.

Хәлбуки, бу мәсьәләдә йөрәк белән уйлап, эйфориягә бирелү куркынычы да бар. Эш шунда ки, Америка геостратегиясе бер милләткә дә ирек бирү максатын күздә тотмый, ул үз геосәяси ихтыяҗларыннан (глобаль өстенлекне саклау) чыгып эш итә. Без үзебезнең ике ут арасында икәнебезне онытмаска тиеш, юкса Косово албаннары яки Чечен халкы язмышына дучар булу ихтималы безгә дә яный. «Ут»ның берсе — АКШ, икенчесе Русия империясе икәнлеге аңлашыла булса кирәк. Әйе, татар язмышы якын киләчәктә менә шушы ике илнең геостратегик проектларына бәйле булачак. Шуңа күрә, кыскача гына булса да, аларга тукталып үтү урынлы булыр. Башта үзебез яшәгән Русиянекенә күз салыйк.

Урыс иҗтимагый аңында бүген ике идеологик караш, ике сәяси омтылыш өстенлек итә. Беренчесе Америка социаль-икътисадый үрнәгенең үзгәртелмәгән вариантын Русия җирлегенә күчерүне күздә тота. Бу — радикаль либераллар (халык телендә аларны «реформаторлар» диләр) карашы. Алар өчен милләт, дини һәм геосәяси ихтыяҗлар, тарихи традицияләр, социаль гаделлек кебек кыйммәтләр зур әһәмияткә ия түгел. Аларга иң мөһиме — икътисадый эффективлык, ирекле базар мөнәсәбәтләре, кеше хокуклары, үзләштерү-куллану, нәфесне канәгатьләндерү. Бу караш идеологик яктан Көнбатыш тәҗрибәсе үрнәгендә инде тәгәл формалашкан һәм аның тарафдарлары шактый оешкан. Икенчесе — идеологик яктан чуар (хәтта каршылыклы) булган державачы патриотлар карашы. Аларны «Бүленмәс һәм бердәм

Русия» идеясе, бөекдержавачылык, урыс шовинизмы, православиегә өстенелк бирү һәм уртак дошман итеп АКШны тану берләштерә. Алар бүген оппозициядә һәм шактый таркау.

Алар берсе дә урыс булмаган милләтләр язмышы турында кайгыртмый. Урыс мәдәни мохитендә яшәүче халыклар өчен алар юлы икесе дә яраксыз: беренчесе ихтыярый-мәҗбүри, икенчесе мәҗбүри рәвештә урыс булмаганнарның ассимиляцияләнүенә китерәчәк. Шуңа күрә, безгә өченче юл — мөстәкыйль татар юлы сайларга кирәк. Үз юлыбызны сайлаганда, югарыда китерелгән үзтиңләнү мантыйгыннан һәм, империя безнең генә дошманыбыз түгел, аның үзеннән дә көчлерәк дошманнары барлыгыннан чыгып эш итү зарур. Бу юл чагыштырмача зәгыйфь татар милли хәрәкәтенә үз алдына зур геосәяси максатлар кую һәм аларга ирешү мөмкинлеге бирә.

Андый мөмкинлек, әлеге дә баягы, яшәү җирлегебез һәм вакытыбыз белән гарантияләнә. Эш шунда ки, Америкага үз гегемонлыгын саклау өчен Ауразиядәге актив геостратегияле илләрнең берләшмәве турында даими кайгыртырга кирәк. Чөнки аларның җыелма потенциалы бүген үк Американыкыннан куәтлерәк булыр иде, алар арасында бердәмлек булмау гына АКШка өстенлек бирә. Атлантизм геостратегиясе аларның берләшү куркынычын инкарь итә алмый. Мәсәлән, кайбер Русия геосәясәтчеләре ике яклы: Русия-Алмания, Русия-Кытай, Русия-Япония, Русия-ислам дөньясы һәм хәтта өч яклы: Алмания-Русия-Япония кебек альянслар төзү проектлары тәкъдим итә. Алар урыс империясе дөнья гегемонлыгына ирешкәнче, димәк, АКШны юк иткәнче көрәшүне күздә тота. Американнар моңа каршы үз чараларын күрә. Әлеге актив илләрнең берләшүен булдырмас өчен, бер яктан, Урталык Җирләренең (Русиянең) бөтенлеге, икенче яктан монда талассократик тәртип (атлантизм) урнашуы кирәк. Империячел традицияле урыс халкы илнең бөтенлеген демократия аркылы саклауны күз алдына китерә алмый — аның табигате моны кабул итми. Ауразия кыйтгасында иминлек балансы саклау шарты буларак, Урталык Җирләренең бөтенлегенә милли һәм социаль каршылыксыз (мондиалистик) җәмгыять кенә хезмәт итә ала. Мондый җәмгыятьнең нигезе булырлык татардан башка бер генә халыкның да реаль мөмкинлеге юк бүген. Димәк, атлантизм үзенең Русиягә кагылышлы геостратегиясен гамәллештерү сөрешендә татар факторына мөрәҗәгать итәргә һәм аңа геосәяси үзәк ролен тапшырырга мәҗбүр булачак.

Һичшиксез, бу фикер бәхәссез кабул ителмәс. Шуңа күрә мәсьәләгә тәфсилләбрәк тукталыйк. Татар моңарчы үзен бәйсез сәя-

сәт үткәрерлек, мөстәкыйль планетар роль уйнарлык этнос, геосәясәт субъекты итеп күрсәтмәде. Мондый сәяси пассивлыкка чик куяр вакыт җитте. Бу — геосәяси вәзгыятькә бәйле заман таләбе. Аның сәбәбе шунда: АКШ геостратегиясе Русияне региональ держава буларак саклауны күздә тота (Аурәзиядә континенталь блоклар булдырмау максатында һәм, беренче чиратта, Кытай белән Иранга каршы). Әгәр үзебезне мөстәкыйль геосәяси көч итеп күрсәтә алмасак, халыкара сәясәт безне, иң күбендә, урыс региональ державасы иярчене буларак кына танычак. Бу, үз чиратында, бүгенге милли, дини, социаль гаделсезлекнең гомерен озынайтачак, ассимиляция шартларын тагын да кискенләштереп, милләтнең юк ителү куркынычын арттырачак. Милли иминлек күзлегеннән караганда, бер генә юл кала: татар үзенең планетар геосәяси проектларда катнашырга әзерлеген күрсәтергә тиеш.

Йөрәге белән милләтче бу фикерне кабул итәргә дә мөмкин, әмма үзеннән-үзе сорау туа: хыял түгелме ул? Аның реаль нигезе бармы һәм аңа ирешү юлы нинди? Әлеге фикернең мантыйкый нигезе төбәктәге ике геосәяси чынбарлыкка таяна. Бер яктан — АКШ геостратегиясе ихтыяҗына (Урталык Җирләренең бөтенлеген саклау), икенче яктан — урыс менталитетының талассократик региональ держава тотарга әзер булмавына. Соңгысын дәлилләү өчен ике чыганакка мөрәҗәгать итик. Русиягә карата Америка геостратегиясен билгеләп, З. Бжезинский болай яза: «...задача состоит в следующем: каким образом оказать поддержку демократическим преобразованиям в России и ее экономическому восстановлению, и в то же время не допустить возрождения вновь евразийской империи, которая способна помешать осуществлению американской геостратегической цели формирования более крупной евроатлантической системы, с которой в будущем Россия могла бы быть прочно и надежно связана»[19]. Русия геостратегиясенең асылын А. Дугин шундый шәкелдә бирә: «Существование русского народа как органической исторической общности немыслимо без имперостроительного, континентального созидания. Русские останутся народом только в рамках Новой Империи.

Эта империя, по геополитической логике, на этот раз должна стратегически и пространственно превосходить предшествующий вариант (СССР). Следовательно, Новая Империя должна быть евразийской, великоконтинентальной, а в перспективе — Мировой.

Битва за мировое господство русских не закончилась»[20].

Урталык Җирләренә карата менә шундый үзара сыешу мөмкинлеге калдырмаучы ике геосәяси проект. Табигый ки, яраклашу булмаганда көчлерәк як мәсьәләне үзенчә чишәргә тиеш була: дөнья гегемонында региональ держава тотучыны алмаштыру ихтыяҗы туа. Моңа кем әзер? Яһүдләр, диючеләр бар. Әйе, алар әзер. Тик бүген аларның миссиясе зуррак — Дөньяви Яңа Тәртип урнаштыру. Алардан башка моңа Даланың элекке хуҗасы татар гына әзер.

Урталык Җирләренең бербөтенлеген саклау өчен кирәк булган миссионерлык ике халыкта бар: урыста һәм татарда. Әмма алар миссионерлыгы аермалы, хәтта капма-каршы нигезле. Бу ике халык капма-каршы менталитетлы. Урыс белән татар менталитетлары аермасы, фикерләү инструменты буларак, телдә бик ачык чагыла. Әйтик, татар белән урыс үз юлында елга очратты, ди. Бу, әлбәттә, юлчы өчен (урысмы ул, татармы) — каршылык. Әмма аны кабул итү ике төрле. Татар каршылыкны дошман итеп кабул итә алмый. Ул, каршылыкны бер мәлдә «онытып» торып, анда да гармония эзли. Эзләгәч таба да: ул елганың күпере икән. Һәм «күпер аркылы чыгам», дигән фикергә килә. Аның фикерләвендә алдагы планда каршылык (елга) үзе түгел, ә өлеге каршылык белән фикерләүче арасында гармония урнаштыручы элемент — күпер. Урыс исә елганы күрү белән аны дошман итеп кабул итә. Аның белән килешү, уртак тел табу мөмкинлеге эзләми, башына килгән беренче фикере — елганы кичү, ягъни каршылыкны-дошманны җиңү, буйсындыру. Ә аннан соң гына ул моңа инди юл белән ирешергә кирәклеген уйлый. Һәм әйтә: «Чыгам аркылы күпер» («Перехожу через мост»).

Татар менталитетының төп сыйфаты, асылы — күптөрлелектә уртаклык табу (бездәге толерантлык шуннан). Урыста, киресенчә — аерма күрү. Шуннан — дошман эзләү, аерманы-үзгәлекне бетерергә, дошманны юк итәргә омтылу һәм көч куллану. Татар күңеленә арыш басуы уртасындагы чиста һәм тулган башаклы урыннарга караганда иген арасында ак, зәңгәр һәм башка күп төрле чәчәкләр дә булган кырый җирләр гүзәлрәк күренә. Урысның исә бер генә төрле булган иген кырларын күрәсе килә. Әйтик, бөтен Үзбәкстан җирләрендә мамык кына үссен, Казакъстан далаларында бодай гына шауласын һ.б. Без еш кына, милләтләр хокукын яклап, бер генә төрле үлән үскән кырдан күптөрле чәчәкләр үскән болынның гүзәлрәк булуы турында мисал китерәбез... Һәм урыслар тарафыннан аңлау тапмыйбыз. Чөнки урыс моны башкача кабул итә, аның өчен бу гүзәллек түгел. Шуңа күрә сәүит чорында күп кенә болыннар сукаланып, анда ти-

мофеевка үләне чәчелде. Урыс гармониясе — бертөрлелектә. Шунлыктан җәмгыяви тормышта аңа берфикерлелек, берпартиялелек, бер хакимгә буйсыну, бертеллелек, бердинлелек, кыскасы, империя тәртибе иң уңайлысы булып күренә. Татар фикерләве анализ аркылы синтезга юнәлтелгән. Җәмгыять төзелешендә бу күптөрлелекне, ягъни милләтләр яки социаль, профессиональ һ.б. төркемнәр үзенчәлеген тану һәм аларны өйрәнү аркылы алардагы уртаклыкны табу, шуның нигезендә аларны берләштерү юлын эзләүдә чагыла.

Урыс эшне дә «каршылык» («дошман») итеп күрә. Аны тизрәк башкарырга (юк итәргә) ашыга, гармония бирүче сыйфат аны бик кызыксындырмый. Урыс менталитетын күрсәтүче төп принцип — «цель оправдывает средства». Шуннан — технология үтәүдәге төгәлсезлек һәм житештерү процессының түбән сыйфатлы булуы. Хезмәттә гармония күрә алмау, аны «дошман» күрү сәбәпле, ул эш башкарудан ләззәт тапмый. Шуннан — ялкаулык [21]. Тормышта, гел каршылык кына күреп, дошманлык эзләү аның эчке кичерешендә рухи канәгатьсезлек тудыра. Аннан котылу теләге эчүчелеккә, кәеф-сафа корып яшәүгә китерә. Татарда (дөресрәге, аның рухы урыслашмаган катламында) боларның капма-каршысын күзәтәбез.

Урыс, үзенең менталитетына күрә, ят нәрсәнең үзеннән көчсезрәге белән дә, көчлерәге белән дә килешеп яши алмый. Көчсезрәген җиңеп юк итәргә тырышса, үзе җиңә алмаган көч белән очрашканда, «амбразурага ташланып», батырларча һәлак булу юлы белән аннан котылырга ашыга. Татар, мондый очракта, «иелгән башны кылыч кисми», дип фикерли. Бу менталитетларның берсен дә начар яки яхшы дип бәяләп булмый. Һәр икесе дә вакытына туры килгәндә яхшы, килмәгәндә — начар: империя чорында урыс менталитеты яхшы иде, хәзер — татарныкы. (Сүз уңаеннан әйтеп үтик, менә шундый капма-каршы менталитетлы булганнары өчен дә урыс-татар катнаш никахлары бәхетле була алмый).

Нигә урыста шундый менталитет га, татарда башкача, бергә яшибез бит, бу геосәясәт принципларына каршы килмиме, дигән табигый сорау туарга мөмкин. Урыстагы дошманлык эзләү эчке гармония булмаудан, аның психологиясе каршылыклы булудан килә. Бу инде аның психологиясе, үз җирләреннән аерылып, яулап алынган чит халыклар биләмәләрендә, ул ияләнмәгән, аны үги иткән һәм яратмаган ят климатик-географик шартларда формалашуына бәйле булса кирәк. (Американар характерындагы агрессивлыкны да шул сәбәп белән аңлатырга кирәктер, күрәсең).

Ә бу юлга беренче адым ясаулары сәбәбен ил башында һәрчак читтән килгәннәр торуында (башта варяг-рюриклар, соңрык нимес-романовлар...) эзләү хаклыдыр. Татарга килгәндә, ул гомер-гомергә борынгы бабаларыбызга Аллаһы билгеләгән кендек җирдә яши.

Урыс миссионерлыгы, аныңча булмаган һәр нәрсәне дошман күреп, аны буйсындыруга, юк итүгә, көч куллануга нигезләнгән. Татарныкы нигезендә исә, киресенчә: аның өчен ят булган һәрнәрсәдә уртаклык — гармония эзләү, хәтта үзенә каршы булган көчтә дә дошманлык күрә алмыйча, аның белән килешү чаралары табарга тырышу, толерантлык, акыл һәм гаделлек белән эш итү. Моны раслаучы тарихи мисаллар да күп. Мәсәлән, Казан ханлыгының күренекле шагыйре, югары катлам дин һәм хакимият әһеле Кол Шәриф болай язып калдырган: «Казанга һичбер җирдән ярдәм һәм таяныч ирешмәс, бары тик Тәңре якын һәм фәрештәләр ярдәмче. Шушы авыр сәбәптән Казан шәһәренең падишалары, кяфер иле (ягъни урыс дәүләте — Р. С.) белән килешүләре аркылы, мәмләкәтләренең җитешлеген тәэмин итәләр. Халкының рәхәте һәм яшәеше өчен Мәсәкү белән солых булып, ике арада илчеләр йөрешер, аңлашып һәм барышып-килешеп йөрмәктә иделәр» [22].

Урыс геосәясәтчесе — ауразиячесе Н. Трубецкой, төркиләр сәясәттә башлаган эшләрен ахырына җиткерә алмый, беркатлы, дип яза [23]. Әйе, урыс менталитеты күзлегеннән бу шулай. Чөнки төркиләргә, шул исәптән татарлар өчен дә, иң әһәмиятлесе - әлеге гармонияне табу. Татар шул гармония шартын тапканчы актив, инде ул табылып, каршы көч белән «килешү»гә ирешкәч, ул тынычлана, аны юк итәргә (бертөрлелеккә) омтылмый. Һәм бу урыс фикерләвендә беркатлылык булып күренә.

Континенталь Зур Пространстволар (империяләр) теллурократик көчләр гегемонлыгында оешты. Шуңа күрә, бу чорда теллурократик урыс менталитеты кулай иде, ул өстенлек алды һәм Урталык Җирләренең бербөтенлеген саклады. Планетар Зур Пространство геосәяси дуализмның талассократик көчләре җиңүе нәтиҗәсе буларак һәм алар сценариенда оешып килә. Хәзер урыс менталитеты әлеге миссиягә яраксыз гына түгел, үзенең атом-төш һ.б. массакүләм юк итү коралы белән, дөнья җәмәгатьчелеге өчен куркыныч та. Бүген Урталык Җирләрен татар гына җыя ала. Әлбәттә, бер генә милләтне дә, җөмләдән урысны да, үзенең дошманы итеп күрә алмавы һәм үзенең «беркатлылыгы» сәбәпле. Татар менталитетының империя чорында тискәре бәяләнгән сыйфаты киләчәктә, Дөньяви Яңа Тәртип чорында, юга-

ры бәяләнәчәк һәм ул милләтебезне кешелек цивилизациясенең иң биек баскычларына күтәрәчәк.

Шулаен-шулайдыр — чынлап та, алай фикерләү мантыйкый нигезгә корылган шикелле. Тик барыбер моны кабул итеп булырмы? Урыс моңа риза булып карап торырмы? Американың үзен юк итәргә хыялланучы халык татарның шундый ниятен белсә, аны бөтенләй сытып ташламасмы? Аннан соң, үзебезне мондый миссиягә идеологик-сәяси яктан әзерли алырбызмы? Халкыбыз, җиде кат — үлчә — бер кат кис, ди. Ялгышмас өчен мәсьәләне тагын бер тапкыр «үлчәп» карыйк әле. Беренче «үлчәү»дә без проблемага менталитет ягыннан караган идек. Бу — проблеманың объектив, җирлеккә (пространствога) бәйле ягы. Хәзер аның субъектив, үзтицләнү һәм иҗтимагый-сәяси аңга (вакытка) бәйле ягын «үлчәп» карыйк.

Урыста дәүләтчелек идеясе бик көчле сыман. Ләкин хәзерге заман өчен ул яраксыз. Эш шунда ки, урыс менталитеты дәүләтчелек идеясе үсешенә баштан ук ялгыш юнәлеш биргән, башка империяләрдән аермалы буларак, ул милләтнең эчке ресурсына нигезләнмәгән, ә башкаларны буйсындыру-талауга корылган. Региональ һәм континенталь Зур Пространстволар берләшүе чоры өчен ул яраган: яңа җирләр яулап алу, территориаль экспансия хисабына урыс дәүләте үскән. «Буш» җирләр бүленеп беткәннән соң, әлеге традицион принцип үзәкнең переферияне талау формасында дәвам иткән: хакимият, үз халкының җелеген суырып, империя ихтыяҗларын канәгатьләндерү юлына баскан, дәүләт куәтен үстерү өчен үз милләтенең эчке потенциалын күтәрү кирәклеген танымаган (Русия империясендә культура мәсьәләсе һәрчак соңгы планда булды). Шул сәбәпле урыс дәүләте интенсив үсеш юлына баса алмады. Бу исә тормыш сыйфатының түбәнәюе аркылы дәүләтчелек идеясенең дә үзгәрүенә китерде. Хәзер бу мәсьәләдә урыста өметсезлек көчәйде, анда үзенең геосәяси ихтыяҗларыннан чыгып эш итү юк дәрәҗәсендә. Эчке милли ресурсларны җигүгә корылмаган урыс менталитеты соңгы вакытта империячел риторика белән үз дәүләтен җимерүчеләрне яклый.

Русия империясен саклау кирәклеген дәлилләп, державачылар Аурупа берләшүе фактын китерәләр. Янәсе, дәүләтләрнең берләшү тенденциясе — глобаль сөреш һәм ул Русиядә дә чагылыш табарга тиеш. Бу җәһәттән, Русия империясе (РФ) белән Аурусоюз (АС) арасындагы мөһим аермалар инкарь ителә: АСда аерым бер генә илнең дә сәяси, икътисадый, этник-демографик һәм территориаль яктан башкалардан хәлиткеч өстенлеге юк.

Аннан соң, АС нинди дә булса империя дәвамчысы түгел — анда, әлеге берләшүнең, кемне дә булса буйсындыруга юнәлтелмәгәнлеге шик тудырмый. Русия чынбарлыгында болар барысы да — милләтара мөнәсәбәтләрдә үзара ышанычка урын калдырмый торган традицион күренеш. Тормыш сыйфаты, мәдәният, җәмгыяви тәртип мәсьәләләрендә дә Русия үрнәк була алмый, ә башкаларны көч белән «җыярга» хәле юк.

Хәзерге заманда үз тырышлыгы белән хөр һәм мул тормыш үрнәге күрсәтә алмаган халык Урталык Җирләрен җыючы була алмый. СССР җимерелүе күрсәткәнчә, геосәяси дуализмның кем файдасына хәл ителүендә бүген тормыш сыйфаты гаять мөһим фактор булып тора. Цивилизацияләр кокуренциясе турыдан-туры каршы тору аша чагылмый, «җиңү»гә үзенең өстенлеген күрсәтү белән ирешелә. Икенче Бөтендөнья сугышында җиңеп, СССР яртн дөньяны үз йогынтысына буйсындырган иде, әмма аларны контрольдә тота алмады, чөнки хәзер халыкларны көч белән тотып булмый, аларны яшәешнең югары сыйфаты үрнәге белән генә җыеп була.

Гәрчә империячел урыс геосәясәтчеләре төрле проектлар корып караса да, Америка геостратегиясе Урталык Җирләре өчен бердәнбер юл калдыра: халыкара сәхнәдә күпмедер реаль рольгә ия булу һәм җәмгыятьне реформалау Аурупа аркылы гына мөмкин. Һәм чиста Аурупа түгел, ә АС һәм НАТО киңәюе сәясәтен үткәрүче трансатлантик Аурупа аркылы. Русияне Госманлы Төркия сайлаган, ягъни, империячел амбицияләрдән баш тартып, аурупалашу һәм демократик-модернизацион вариант көтә.

Татарның Урталык Җирләрен җыю вазыйфасына әзерлегенә һәм бу миссиянең реальлегенә килгәндә, милләтебез үзенең иҗтимагый аңында да, гамәли сәясәтендә дә әби-бабаларыбыз тире вә каны тамган җирләргә тугрылык саклаган. Моның беренчесе халкыбыз психологиясенең асылын күрсәтүче мәкальләрдә (хосусан, «ана күңеле — балада, бала күңеле — далада» дигәнендә) чагылыш таба, икенчесен раслаучы классик мисал итеп XX гасыр башындагы милли хәрәкәт сәясәтен китерергә була. Октябрь инкыйлабы алдыннан бөтен төрки-мөселман халыклары (хәтта башкортлар да) җирле мөстәкыйльлеккә дәгъва кылганда, татар милли хәрәкәте Дала киңлегендәге (Русия составындагы) мәдәни мөхтәрият өчен көрәшүне күздә тоткан. Һәм андый юлның мантыйкый җирлеге дә булган: урыс галимнәре тануынча, татар буржуазиясе позициясе ныгуы шундый темпта барган ки, XX гасыр уртасына ул бөтен Русия киңлегендә өстенлек яулаячак булган. Русия киңлегендә өстенлеккә ирешү турыдан-туры халыкара сәя-

сәткә чыгу да булыр иде. Инглиз Э. Тори үзенең «Русия 1914 елда» дигән китабында, әгәр Көнбатыш илләре Русия үсешен тоткарламаса, 1930 елда аңа тиңнәр булмаячак, Аурупа һәм АКШ бу чимал гиганты алдында тезләнергә мәҗбүр булачак, дип язган. Димәк, татар милли хәрәкәтендә, киләчәктә үз буржуазиясенең Урталык Җирләрендәге өстенлегенә таянып, дөнья сәясәтендә актив һәм абруйлы көчләрнең берсенә әверелү нияте күздә тотылган булса, бу реаль җирлеккә нигезләнгән, дип әйтә алабыз. (Бу уңайдан, большевизмны урыс һәм татар капиталистларына каршы дөнья олигархлары көрәше дип бәяләргә була: башта национализация үткәреп, милекне алардан тартып алырга, аннан, әйтик, НЭП аркылы хосусыйлаштыру оештырып, аны үз кулларына төшерергә. Көнбатыш буржуазиясе, моны аңлап, пролетариат белән бераз байлык бүлеште. Шуның белән социалистик революциядән сакланып кала алды. Ә урыс һәм татар байлары моны аңламады һәм башларын җуйды).

XX гасыр азагында яңадан күтәрелгән милли хәрәкәттә дә татар язмышын сәяси күзаллау — Дала киңлегендә. Татар иҗтимагый үзәге 1989 елда кабул иткән Программаның милли дәүләтчелек мәсьәләсендәге төп таләбе: «Татарстанга — союздаш республика статусы!» [24] Дөрес, бу таләп империядә яклау тапмагач, соңрак дәүләтчелек киңлеген күзаллау «Татарстанга — тулы бәйсезлек!» шигаренә кадәр тарайды, әмма Татарстан Конституциясендәге милли дәүләтчелегебезнең империя белән «ассоциацияләнгән»леге аны яңадан Дала киңлегендә калдырды.

Хәзерге иҗтимагый сәяси фикерләүдә әлеге киңлек, яшәгән җирлегебездәге геосәяси дуализм, анда катнашучылар һәм татарның Урталык Җирләрен җыюга әзерлеге түбәндәгечә чагылыш таба. Милли хәрәкәт идеологы, этнограф һәм тарихчы галим Дамир Исхаков, татар киләчәген Урталык Җирләрендә дәүләт тотучы («урыс-татар империясе төзүче») [25] буларак күзаллый. Шагыйрь Равил Фәйзуллин «Хастаханәдә» дигән дүртьюллыгында:

«Ике халыкның баласы
Соңгы сулыш — җан авазы.
Һаваларда чәкәләшә
Азан белән чаң авазы», —

дип яза [26]. Галим-филолог Рифкать Әхмәтҗанов, «татар халкы, үзенең Идел-Чулман регионындагы тәүге төрки бабаларыннан алып, биредә иң мәдәни үзәк, берләштерүче этник элемент булып килгән», [27] икәнлеген дәлилли.

Күрәбез, татар иҗтимагый-сәяси аңында (һәрхәлдә, аның элитасында) Урталык Җирләренең бөтенлеген саклау идеясе, моның өчен дәүләт тоту вазыйфасын үз кулына алу кирәклеген һәм бу миссиягә үзенең әзерлеген тану ят әйбер дип булмый. Димәк, бу юнәлештә гамәлгә куучү өчен һәм объектив, һәм субъектив җирлек бар.

МИЛЛИ ҮЗТИҢЛӘНҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Дөнья үсеше тенденцияләре татарга киләчәктә геосәяси субъект булу форсаты бирә — милләткә мөстәкыйль геостратегик проект белән эш итү өчен потенциаль мөмкинлек ача. Аны гамәлләштерер өчен татарга, иң әүвәл, бүгенге психологик халәтеннән арынып, үзенең кем икәнен аңларга, җилкәсенә төшкән яңа тарихи рольгә «керергә» кирәк. Бу, иҗтимагый-сәяси аңдагы күп кенә идеяләргә һәм проблемаларга тәнкыйди анализ үткәреп, аларны яңача хәл кылуны таләп итә. Урталык Җирләрен җыю миссиясен үтәүдә татарга, беренче чиратта, эчке дошманы — таркаулык киртә булып тора. Бездәге таркаулыкның сәбәбе күптөрле, ә чыганагы бер — яшәгән җирлегебезгә һәм тарихыбызга бәйле формалашкан менталитетыбыз. Мисал өчен, югарыда китерелгәнчә, каршылыкка (әйтик, сәяси вазгыятькә) мөнәсәбәт билгеләү вакытында беренче чиратта гармония эзләү кайвакыт иҗтимагый фикерләүдә, максатны (елганы кичү) онытып, аңа ирешү юлы (күпер аркылы) турындагы бәхәснең төп объектка әверелүен китерергә була. Сәяси таркаулык сәбәбенең яшәү җирлегенә бәйлесе (урталыкта булу) татарга күрше культураларның тәэсире белән аңлатыла: берәүләр Көнчыгышка (төрле вакытта Кытай, Иран, Гарәбстан, Төркия), икенчеләре Көнбатышка (Рим-Византия, Көнбатыш Аурупа, АКШ) кыйбла тота. Аның тарихка бәйле ягын, Чыңгыз ханнан башлап, дәүләт башында башка кавем вәкилләре булуыннан эзләргә кирәктер. Ил башында ятлар тору хакимият белән гади халыкны бер-берсеннән аера. Ил эчендә хакимияткә каршы көрәш ихтыяҗы туа. Һәм бу көрәштә союзник итеп берәүләр Көнчыгышны, икенчеләр Көнбатышны, өченчеләр үз милләтеннән булган җирле түрәләрне (алар үзәк хакимияткә хезмәт итсә дә, аларда һәрчак күпмедер күләмдә мөстәкыйльлек ихтыяҗы да саклана) күрәләр. Соңгыларына тулы мөстәкыйльлек кирәк түгел, аның чагыштырмача зуррагы (аның зурлыгы үзәк хакимият ихтыяҗы белән чикләнә) да җитә дип уйлый. Шулай итеп, милли хәрәкәт өч юнәлешкә бүленә: Көн-

чыгыш, Көнбатыш һәм империя тарафдарлары һәм алар хаким милләттәге сәяси төркемнәргә иярә. Бу юнәлешләрнең берсе дә татар дәүләтенең тулы

Сәяси өметсезлек милләтнең иҗтимагый аңында үзенең дошманнарын тану һәм милли-сәяси егәрен аларга каршы юнәлтү сәләтен җуйдыра. Табигать законнары буенча, тышкы каршылык булмаганда көрәш энергиясе милләтнең эченә юнәлтелә, анда таркаулык хасил була һәм ул милләтне эчтән җимерә башлый. Милләт тәрәккыяте өчен аның иҗтимагый аңында эчке һәм тышкы геосәяси дошманнар, эчке һәм тышкы мәдәни чикләр ачык тәгаенләнгән булырга тиеш. Ул шушы ике чик арасында «әвәләнеп», «бәрелеп-сугылып», ягъни үзенең мәдәни-дәүләти чикләрен саклау өчен эчке һәм тышкы дошманнары белән көрәшеп кенә үсеш ала ала. Юкса ул, күнегүләрен туктату сәбәпле, мускуллары шәлберәйгән спортчы сыман, хәлсезләнә-көчсезләнә.

Милләт язмышы өчен хәлиткеч әһәмияткә ия булмаган вактөяк мәсьәләләрдәге гомумтаркаулыкны һәр халыкта һәм һәрчак була торган һәм булырга тиешле фикер төрлелеге дип карарга да ярар иде. Ә менә, татарга үз миссиясен үтәү өчен зур комачаулык итүче, дәүләтчелеккә бәйле һәм сәяси таркаулык тудыручы проблемаларга геосәяси анализ биреп, аларны хәл итү юлларын ачыклау кирәк булыр. Андыйларга болгарчылык-татарчылык, татар-башкорт проблемалары, Идел-Урал, гандизм, төркичелек һәм исламчылык идеяләре, евразиячелеккә мөнәсәбәт кебек мәсьәләләрне кертергә кирәк. Алар бер-берсенә бик бәйле, шуңа күрә, аларны бергә карау дөрес булыр.

Геосәясәт фәне раславынча, яшәү җирлегенең климаты, ландшафты, геологиясе, су юллары, тау тезмәләре этник һәм, киңрәк алганда, цивилизацион тип формалашуына актив тәэсир ясый. Шуңа нигезләнеп соңгы вакытта Аурупада глобаль геосәяси принципларны, аның аналитик ысуларын локаль проблемаларны тикшерүдә һәм хәл итүдә дә куллана башладылар. Геосәясәтнең бу тармагы (аңа нигез салучы — географ Ив Лакост) «эчке геосәясәт» яки «кулланма геосәясәт» дигән исем алды. Кулланма геосәясәт, җирле мәсьәләләрне тикшерүдә аналитик, политологик, социологик ысул буларак, татар проблемаларына карата да үзенең универсальлеген саклый. Чөнки аларның нигезендә дә беренчел сәбәп булып яшәү җирлеге тәэсире ята. Эш шунда ки, татар менталитеты бер генә төрле булып формалашып бетмәгән. «Татарлар Идел буенда XIII гасырдан соң бер халык буларак формалаша башлый. Алтын Урда чорында. Ул элекке мөселман болгарларны да, кыпчакларны да, фин-угырларны да эченә ала. XVI гасырда та-

тар милләт буларак формалашып җитә яза. Ләкин — җитеп үк бетми. Алтын Урда иртә таркалу аркасында»[28]. Бүгенге татар менталитетында без, асылда, ике төрле стихия чагылышы күзәтәбез: Идел (болгар) һәм Дала (кыпчак) йогынтысы. Далада яшәү җирлеге һәм күчмә тормыш шартлары шундый: дала киңлеге һәм хәрәкәт — даими күренеш, йорт — бөтен дала (үз йорт-җирең юк), үз дөньяң киңлеге — чиксез, башка дөньяны белмисең, билгесезлек (даими куркыныч тоеп яшәү), кавемдә бер-береңә бәйлелек. Шундый яшәү шартларында кыпчакта җәмгыяви аң да тәрбияләнә: күмәклек (күмәк хуҗалык, күмәк тормыш) — коллективизм; чыдамлылык, көч һәм батырлыкның югары бәяләнүе; бертөрлелеккә омтылу, күңел киңлеге, беркатлылык һәм хыялга бирелүчәнлек; башкаларга мөнәсәбәтнең (димәк, сәяси карашның да) кирәклеге юк — анысы хан («Бабай») эше; җир синеке дә, минеке дә түгел, ул — җәмгыяви байлык. Шуңа күрә, аның кыйммәтлеге дә йөрәк аркылы үтми, аны саклау минем генә эш түгел, бөтен кавемнеке (дөресрәге, патшаныкы).

Болгар утрак тормышта, башлыча, сәүдә белән тамак туйдыра. Аның үз йорт-җире, каралты-курасы бар. Аның өчен дөнья киңлеге чиксез (ул моны үзе сәүдә белән йөреп тә, читтән килгән сәүдәгәрләрне күреп тә белә), әмма үз дөньяң ишегалдың белән чикләнә. Дөнья бер төрле генә түгел — анда төрле тәртип, аларга төрле мөнәсәбәт таләп ителә. Юкса, кибетеңне яки остаханәңне ачу белән сине алдарга да мөмкиннәр. Яшәү шартларына җавап буларак болгар психологиясе формалаша: индивидуализм, хәйләкәрлек («хәйләсез сәүдә — файдасыз»), сәяси аң, күптөрлелекне тану — либерализм, конкрет фикерләү — рационализм, хосусый хуҗалыкка (милеккә, җиргә) омтылу.

Күрәбез, милләтебез формалашуында катнашкан ике төп кавемнең иҗтимагый аңы шактый каршылыклы булган. Дөрес, Алтын Урда шартларында уртак нигездә алар шактый тигезләнгән, ләкин гел бер генә шәкелгә килә алмаган. Һәм аның сәбәбе Алтын Урда җимерелүенә генә бәйле түгел — сибелгән милләтнең төрле климатик-географик һәм империянең төрле җәмгыяви-сәяси шартларында яшәве дә моңа өлеш керткән. Империя хакимиятенә якынрак торган югары катлам яки Идел-йорттан ераграк яшәгәннәр аңында Алтын Урда идеясе (татарчылык), Идел буенда милли мохиттә яшәүче гади халыкта Болгар һәм Казан ханлыкларын сагыну көчлерәк сакланган. Югары катлам Алтын Урда мирасы өчен көрәшкән, гади халык андый киң карашта булмаган, ул үз җирлеге белән чикләнгән.

Болгарчылык өчен, объектив яктан, эчке дошман (мәдәни һәм дәүләти чикләрне билгеләү өчен көрәш) — башкорт, тышкысы (бәйсезлек өчен көрәш) — урыс. Тик менә бүгенге шартларда, империянең идеологик-сәяси йогынтысы һәм үзендә империячел миссионерлык омтылышы булмау нәтиҗәсендә болгарчылык үзенең дошманы итеп татарчылыкны күрә (сәяси аң түбәнлеге сәбәпле дошманның эчкесе-тышкысы аның өчен бер, һәм ауразиячелек аны бик кызыксындырмый). Татарчылык өчен, объектив яктан, эчке геосәяси дошман (Урталык Җирләре хуҗасы булу өчен көрәш) — урыс, тышкысы (Урталык Җирләренең бөтенлеге һәм иминлеге — мөстәкыйльлеге өчен көрәш) — тирә-юньдәге теллурократик державалар. Вәләкин үзтицләнүдә үзен дөрес танымау нәтиҗәсендә татарчылык бүген үзенең эчке дошманы итеп болгарчылыкны, ә тышкысы итеп урысны таный. Ауразиячелекне ул урыс империясен торгызуга хезмәт итүче концепция дип бәяли.

Милләтнең геостратегик ихтыяҗлары (Урталык Җирләрен җыю) югарылыгыннан карaганда татарның эчке һәм тышкы объектив дошманнары татарчылыкның объектив дошманнарына туры килә, ә болгарчылык дошманнары тактик планда сәяси әһәмиятләрен саклаcа да, стратегик проектларда алар мәдәни каршылыкка кайтып кала. Башкорт мәсьәләсенә килгәндә, ул татарның геосәяси дошманы түгел, ә мәдәни көндәше булып тора. Аның белән көрәш максаты — мәдәни чикне билгеләү. Шулай итеп, татарчылык үз эченә болгарчылыкны да, татарчылыкны да алуы сәбәпле, татарның геосәяси дошманнары — урыс (эчкесе) һәм Ауразиянең теллурократик державалары (тышкылары); мәдәни көндәшләре (мәдәният өлкәсендә татар менталитеты дошманлыкны танымый — ул толерантлы) — башкорт (эчкесе) һәм урыс (тышкысы). Ауразиячелеккә мөнәсәбәт билгеләгәндә, татар аны үзенең эчке геосәяси дошманы һәм тышкы мәдәни көндәше булган урыс идеологиясе дип бәяләргә тиеш. Тактик мәсьәләләрдә андагы кайбер положениеләрдән (әйтик, урыс тарихында татар һәм Алтын Урда роле, татарны урысның дошманы итеп карамау һ. б.) файдаланырга була, ләкин аны стратегик концепция буларак кабул итеп, державачыларга иярү һич тә ярамый. Андый иярүнең нигә китергәнен тарихи сабак бик яхшы күрсәтә. Урыс ауразиячеләренең «Туран» идеясе дә төркиләрне һәм угро-финнарны яклау, аларга үзләренә тиң ирек бирүне күздә тотмый. Ул, бер яктан, Урталык Җирләрендә яшәүчеләрне Көнбатышка каршы куеп (тышкы дошман билгеләп), империядәге төрле этник һәм социаль төркемнәрне берләштерү, икенче яктан, урыс булмаганнарны ассимиляцияләүгә «легитим» төс бирү максатына хезмәт итә.

Татар тарихында төрле вакытта, сәяси вәзгыятькә һәм милли хәрәкәтнең башында кем торуына карап, болгарчылык яки татарчылык өстенлек алган. Әйтик, Пугачев восстаниесе вакытында татарчылык өстенлек итә (анда сәяси таләпләр — империя киңлегендә), чөнки ул морзалар җитәкчелегендә оеша. XX гасыр башында да шулай ук. Чөнки милли хәрәкәт башындагы буржуазия чыгышы белән асылда шул ук морзалардан. Ул чакта югары катлам күләме белән дә (1069071 ир-ат һәм 1085831 хатын-кыз, ягъни 2 миллионнан артык кеше тәшкил иткән) [29], империя икътисадындагы позициясе ягыннан да Урталык Җирләрендә өстенлек дәгъваларлык көчкә әверелә. Татар ареалы империянең Ерак Көнчыгышыннан Көнбатышына кадәр таралган, урыннарда югары шәһәр культурасы үсеп килә (КВЖД — Харбин, Троицки, Уфа, Ырынбур, Уральски, Казан, Санкт-Петербург һ.б.). Болар бөтенесе татар элитасына Алтын Урда варисы булып үзтиңләнүгә җирлек биргән һәм милли хәрәкәттә татарчылык өстенлек алган. Сәүит чорында милләтнең элитасы, кырылып яки чит илләргә куылып, юк ителгәннән соң, дәүләтчелек идеясендә болгарчылык җиңә. Дәүләтчелек күзлегеннән, XX гасырның беренче сәяси болгарчысы дип үзенең Идел-Урал штаты идеясен Милләт Мәҗлесендә күтәреп чыккан Галимҗан Шәрәфне, ә аның дәвамчысы дип соңрак, милли хәрәкәт тар-мар ителгәннән соң, мөһаҗирлыкта шушы идеягә кайткан Г.Исхакыйны атарга кирәктер. Бүгенге «Татарстан моделе» дә — болгарчылык чагылышы (аның тарайтылган варианты).

Бүген милли хәрәкәт проблемаларына кагылышлы язмаларда еш кына Һиндстан бәйсезлеге өчен көрәштә уңай нәтиҗә биргән гандизм ысулларын (беренче чиратта, аның империя органнары белән хезмәттәшлек итмәү принцибын) кулланырга чакырулар очрый. Бу да — асылда, болгарчылык карашы. Татарчылык моның белән килешә алмый һәм бу идея бездә яклау тапмады. Һинд азатлык милли хәрәкәте үз җирләреннән инглизләрне куу өчен көрәшкән. Һиндстан кайда да, Англия кайда? Алар дөньяның икесе ике читендә. Урыс империясе татар җирләрен били һәм татарчылык үз Даласы, аның иминлеге өчен җаваплылык тоюга нигезләнгән. Бу җирләрдән кемне дә булса куу нияте анда юк. Киресенчә, ул үз миссиясен монда яшәүче халыкларны җыюда күрә. Мондый миссияне дәүләт эшендә катнашмый гына үтәп булмый. Әйе, гандизмдагы аерым алымнарны (әйтик, империянең иңбашка яки күкрәккә тагылулы ялтыравыкларына, титулларына, дәрәҗәле исемнәренә сатылмау кебекләрне) кире кагарга кирәк түгел, әмма тулаем алганда, аның дини-фәлсәфи нигезе

дә, сәяси максаты да башка булуы сәбәпле, татар милли хәрәкәте гандизм идеясен кабул итә алмый.

Күрәбез, гасыр башындагы сәяси татарчылык та, бүгенге сәяси болгарчылык та татарга ни дәүләти, ни мәдәни үсеш мөмкинлеге бирмәде. Ни өчен? Чөнки аларның йә тегесенә, йә монысына гына өстенлек бирелде. Ә кирәк икесен бергә кушарга — алар бит бер-берсеннән аерылгысыз. Татар язмышын хәл иткәндә безгә, вак мәсьәләләрдәге эчке каршылыкларга игътибар итмичә, төп стратегик максатлардан чыгып эш итәргә кирәк. Шулай эшләгәндә татарчылык белән болгарчылык арасында каршылык калмый: татарчылык стратегик максатларга, болгарчылык тактик бурычларга хезмәт итә. Сәясәттә (дәүләтчелек мәсьәләсендә) соңгысы «кулдагы песнәк»кә өстенлек бирә, беренчесе «күктәге торна»ны тотарга тели. Милләтне саклау һәм үстерү өчен «песнәк»не ычкындырмаска, аны тәрбияләргә (Идел буенда татар дәүләтчелеген үстерергә һәм ныгытырга), шул ук вакытта «торна»ны тоту (башка милләтләр белән берлектә Даланы саклау җаваплылыгын таныган хуҗа булу) чарасын күрергә кирәк. Моның өчен милли аң шундый шәкелдә формалашырга тиеш: болгарчылык + татарчылык = татарлык.

Бу таләпне халкыбыз үзенең кыска, әмма бик тә мәгънәле мәкалендә васыять итеп яңа буыннарга тапшыра килгән: «Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада».

Бүгенге татарның анасы — Идел (Болгар дәүләте — болгарчылык), атасы — Дала (Алтын Урда — татарчылык). Бала чын кеше булып үссен һәм яшәсен өчен аңа хис һәм акыл тәрбиясе бирергә кирәк. Бала беренчесен — анадан, икенчесен атадан җиңелрәк һәм ышаныбрак кабул итә. Ул, ягымлы анасына охшыйсы килеп, хис нечкәлеген үзләштерә, атасы кебек көчле булырга теләп, акыл югарылыгына омтыла. Идел-ана баласын (газиз Татарын) тәрбияләү (татарлыкны саклап һәм аны үстереп, буыннан-буынга тапшыру) турында кайгырта, аңа үз миссиясен үтәү өчен бик кирәк булган гаделлек, шәфкатьлелек, табигатьне һәм кешеләрне ярату хисләре бирә. Анасы куеныннан чыгасы килмәгән, аның итәгеннән кулын ычкындырырга курыккан сабый сыман, татар да көчсез-аңсыз чагында, асылында курку яткан хисләргә өстенлек биреп, Идел «чабуы»на ябышып яши. Аяк-кулында бераз ныклык сизә башлауга, болай яши алмаячагын, аның дөньясы киңрәк икәнлеген аңлый. Инде буйга үсеп, акыл җыйгач, аңа кешечә яшәү өчен гаилә корырга һәм балаларга ата булырга (төбәктә яшәүче халыклар белән уртак дәүләт корырга), аларны үз канаты астына җыярга (Дала турында кайгыртырга) кирәклеген, шунсыз

нәселе корыячагын (үзе дә, Дала да һәлакәткә юлыгачагын) таный башлый.

Бездәге болгар компоненты (болгарчылык) динамизм-либерализм бирә, ә кыпчак компоненты (татарчылык), берләштерүче көч буларак, динамизм казанышларын таратырга омтыла. Без, болгарчылык психологиясенә таянып һәм аның дәүләтчелек идеясен гамәлләштереп, этник саклану һәм мәдәни тәрәккыять проблемаларын хәл итәргә, шул ук вакытта, татарчылык психологиясенә нигезләнеп, алга таба үсеш алырга һәм геотарихи вазыйфабызны үтәргә әзерләнергә тиеш. Ул чагында болгарчылык Иделйортта татарлыкны югарыга үстерергә, ә татарчылык аны Дала киңлегенә җәелдерергә ярдәм итәр. Моннан татарлыкның график формасын шулай күзалларга була.



Графиктан күренгәнчә, татарчылыкны саклау һәм үстерү өчен болгарчылык белән татарчылык икесе дә кирәк. Шулай булгач, аларны бер-берсенә дошман көч дип карамыйча, милләт исемен алыштыру дәрәҗәсендә вакланмыйча, аларның һәр икесен милләтебез үсеше векторына әверелдерергә кирәк. Исемебез татар булсын, җаныбызда болгар-татар рухы саклансын (алар икесе дә, тегe яки бу кимәлдә, һәрберебездә бар һәм аларның кемдә күпме икәнен милләт исемен ничек атау теләгенә генә бәйләп карау дөрес булмас). Болгарчылык безгә милләтне саклау, дәүләтчелегебезне һәм милләтебезне үстерүдә нигез булып тора, татарчылык империяне реформаларга ярдәм итә, шуның белән дөнья җәмгыятьчелегенә кирәгебезне тудыра. Икесен дә параллель үстереп, үз файдабызга җигә алган очракта алар татарны геосәяси субъект дәрәҗәсенә күтәрә.

Татарны аерым-аерым гына татарчылык та, болгарчылык та саклап кала алмаячак. Чөнки татарчылыкта континентализм миллилеккә караганда көчлерәк. Тарих сабаклары күрсәткәнчә, бер яктан, Урталык Җирләрен җыю, икенче яктан, милләтне (телне, мәдәниятне, динне) саклау ихтыяҗлары альтернативасы торганда, ул беренчесенә өстенлек бирә. Алтын Урда империясе таркалганда татарларның континенталь менталитетлы өлеше империячел сәясәтле урыслар ягына күчә. Моңа аларда ислам традицияләренең әле урнашып-ныгып җитмәве дә сәбәп булгандыр: алар милли аңында ислам кыйммәтләренең югарылыгына караганда империядәге киңлек артыграк бәяләнгән, күрәсең. Болгарчылык, әлбәттә, исламга нигезләнгән миллилекне өстенрәк күрә. Идел буендагы дәүләтчелегебезне тергезү мәсьәләсендә аның позициясе нык һәм эзлекле. Тик, шул ук тарихи сабаклар бу юлның да стратегик максатларда ышанычсыз һәм тотрыксыз икәнен күрсәтә: Урталык Җирләрен җыюны башка милләтләр-көчләр үз кулына ала һәм аның үзен дә буйсындыра. Шулай беренче болгарчылык дәүләте XIII гасырда (Чыңгыз хан явы) һәлакәткә юлыкты, шул ук язмышны XVI гасырда аның икенчесе (Явыз Иван явы) кабатлады.

Кешелек тарихына игътибар итсәк, шуны күрәбез: милләтләрнең теле һәм мәдәни үсеше, ягъни милләтне саклау һәм үстерү өчен дәүләтчелек кирәк. Әмма империя уртасындагы дәүләтчелекнең саклануы һәм үсеше гарантияле түгел: иртәме-соңмы, империя тотучы милләт вагракларын (дәүләтчелекләре, телләре, диннәре-мәдәниятләре белән, урыс әйтмешли, «с потрохами») йотачак. Урыс империясе сакланганда киләчәктә Татарстан мөстәкыйльлеге дә һәрчак куркыныч астында торачак — «держава» дигәндә урыс менталитеты өчен үзенә тиң союзник юк. Шуңа күрә, менталитетыбыздагы ике канатны милләт максатында кагындырырга кирәк: болгарчылык Идел-йортны башкаларга үрнәк булырлык ирекле һәм мул тормышлы гөлбакчага әверелдерергә хезмәт итсен, татарчылык мәдәниятебезне дөньяга танытуга, Урталык Җирләрендәге халыкларны «күптөрлелек бердәмлеге»нә берләштерүгә ярдәме аркылы дәүләтебезнең (димәк, милләтебезнең) өметле киләчәген гарантияле итсен.

Татарның болгар (Су, Елга) һәм кыпчак (Коры, Дала) компонентлары аның «Идел-йорт», «Идел-Урал» кебек идея-символларында да чагылыш тапкан. Теллурократик-континенталь Русия империясе үзенең эчке төп геосәяси дошманы булган татарны урыслаштыру өчен, беренче чиратта, аның менталитетындагы талассократик өлешен юк итү кирәклеген аңлап, аның яшәешен һәм

фикерләвен Иделдән аеру сәясәтен гамәлгә куя: Идел яр буйлары чиркәүләр белән тутырыла, татарлар аннан куыла, «Идел» символы рәсми рәвештә татардан тартып алына һәм урысныкы ителә («Великая русская река»). Вәләкин милләтебез хәтере аны онытмый, халык Иделкәен җырларда җырлый, үзенең иҗади игътибарын урыслар йогынтысы йомшаграк булган Агиделгә юнәлтә[30]. Бу — татар язмышының киләчәген күзаллау өчен гыйбрәтле күренеш: ул безнең эчке дөньябызның атлантизмга нигезләнгән Дөньяви Яңа Тәртип шартларына тәңгәл килүен һәм мәдәни үсеш векторы талассократик булырга тиешлеген күрсәтә.

Заманында инглизләр, үзтиңләнүдә Британия утравын океаннарда йөзүче кораб итеп күреп, аны Бөекбританиягә әвереләдерделәр. Бүген безгә дә, алар үрнәгендә «Идел-йорт» символындагы «йорт»ны (төп йортыбыз Татарстанны) Дала гизүче «кораб»ка тиңләп, Бөек Татарстан корырга мөмкинлек туа.

Бу идеяне гамәлләштерү берничә этаптан торырга тиеш. Бөек Татарстанның контурларын билгеләү бүген хыялыйлык булып кабул ителергә мөмкин. Шуңа күрә, бу эшне XXII гасыр буыннарына калдырып, әлеге идеянең XXI гасырда яшәүчеләр өчен якынрак һәм реаль булган беренче этабына — «Зур Татарстан моделе»нә кыскача тукталып үтик. Татар җәмәгатьчелегендә «Зур Татрстан» идеясе, Татарстан үзенең мөстәкыйльлеген игълан иткәннән соң барлыкка килде. Ул, милли аңыбыздагы татарчылык чагылышы буларак, милли хәрәкәт үзенең көрәш объектын Татарстан белән генә чикли алмавын, аның игътибарында бөтен татар дөньясы булырга тиешлеген күрсәтә. Ул татар дөньясын бербөтен итеп карый һәм шуңа ирешү өчен кирәк булган сәяси, икътисадый, дини-мәдәни багланышлар урнаштыруны, Татарстан суверенитетына таянып, милли яшәеш шартларын яхшыртуны күздә тота. Русия федераль округларга бүленгәннән соң әлеге идеяне гамәлләштерү өчен яңа потенциаль мөмкинлекләр туды. Хәзер Идел-йорт тулысынча бер административ берәмлеккә керә һәм бу Идел буе татарларын берләштерүне җиңеләйтергә тиеш.

Дөрес, Русияне федераль округларга бүлү «Зур Татарстан» идеясен гамәллшәтерүне җиңеләйтү өчен эшләнмәде, ул — Русияне Аурусоюзга кертү максатында әзерләү чарасы. Бу уңайдан, З. Бжезинский, XXI гасырның беренче ике дистә еллары дәвамында Русиянең Уралга кадәр булган өлеше Аурупага актив рәвештә интеграцияләнәчәге турында яза. Димәк, округларның чикләрен билгеләгәндә Русиянең якын киләчәге истә тотылган булырга тиеш. Моннан икеләнмичә әйтә алабыз: Идел буе федераль округы чикләрен билгеләү дә очраклы булмаган. Тагын бер өгер-

ме еллардан Идел буенда яшәүче төрки, угры-фин һәм урыс халыклары берлеге, ягъни Идел-йорт Аурусоюзга һәм НАТОга аерым бер дәүләт булып керү ихтималын фаразлау хыялга бирелү дип каралырга тиеш түгел. Әйе, монда урыс күпчелекне тәшкил итә, хакимият тә урысныкы, әмма, геосәяси күзлектән, Русиянең бүленүен һәм татар дөньясының укмашып яшәүче күпчелек өлеше Идел буе округына керүен уңай бәяләргә кирәк.

Дәүләтнең геосәяси урыны һәм торышы, биләмәләрен билгеләүче чикләре аның сәяси төзелешенә караганда күпкә мөһимрәк, дигән принцип геосәясәтнең төп постулатларыннан санала — сәясәт, культура, идеология, хакимиятнең нинди булуы, хәтта дин дә, геосәяси күзлектән, бик мөһим, әмма икенче дәрәҗәле факторлар буларак карала, ә беренче урын дәүләтнең территориаль киңлегенә бирелә. Мәдәни, социаль һ.б. тактик бурычлар югарылыгында фикерләүче милләтчеләр моның белән килешми. Ә менә стратегик максатлар, геотарихи вазыйфа югарылыгына күтәрелсәң, моны танымый булдыра алмыйсың. Моңа тарихи мисаллар да бик күп. Әйтик, Алтын Урда вилаятьләренең, Сарай сәясәте белән килешмичә, мөстәкыйль ханлыкларга бүленүе татар файдасына булмый. Шул ук вакытта урыс кенәзлекләренең, үз мөстәкыйльлекләрен җую хисабына булса да, Мәскәү тирәсендә берләшүе урыска Алтын Урда кысаларында көч-куәт җыярга мөмкинлек бирә, аның тулы бәйсезлеккә ирешүенә һәм мәдәни үсешенә юл ача.

Бу геосәяси закончалык халкыбыз мәкалендә дә урын тапкан — ул: «Аерылган ил азар, кушылган ил узар», — ди. Димәк, «узу» өчен туган шартлардан файдаланып, гамәлдәге милли үзбилгеләнү формаларының һәр икесен (ТР һәм милли-мәдәни мохтәриятләр) кулланып һәм бер ситсемага кертеп, Идел буенда яшәүче татарларны «кушарга» кирәк. Моңа ирешелсә, Идел-йортка таянып, Зур Татарстанның мәдәни-идеологик бердәмлеген тормышка ашыру да җиңелрәк булыр иде. Мәсьәлә җиңелләрдән түгел, әлбәттә. Шулай да, Дөньяви Яңа Тәртип авторларының, төбәктә яшәүче халыкларның һәм татарларның геосәяси ихтыяҗлары төңгәл килүе мәсьәләнең без теләгәнчә хәл ителүенә ышанычны арттыра. Мондый вәзгыятьтә бездән, беренчеләренә таянып, Русияне реформалау сөрешендә актив катнашу, безнең ярдәмгә мохтаҗ булган икенчеләренә, уртак мәнфәгатьләребезне канәгатьләндерүдә үрнәк күрсәтеп, этник-мәдәни үсештә ярдәмләшү системасы оештыру сорала. Моның өчен, милли республикаларның мөстәкыйльлеген саклаган һәм аларда титул халыкларның этник-мәдәни үзәге ролен үстергән хәлдә, күрше респуб-

ликалар-өлкәләрдәге милли-мәдәни мөхтәриятләр аркылы милли мәгариф һәм мәдәни хезмәт күрсәтү чараларын финанслау һәм оештыруны федераль округ кысаларында рәсмиләштерергә кирәк.

Соңгы фикерләрне дөрес аңламаска да мөмкиннәр, ачыклык кертик: сүз теләге булганнар турында гына бара. Ә менә башкорт милләтчеләрендә андый теләк күренми сыман. Һәм бу табигый. Башкорт белән татар — кардәш халыклар. Безнең культурабыз бик якын (уртак диючеләр дә күп), әмма холкыбыз, менталитетыбыз, дөньяга карашыбыз төрле. Борынгы бабаларыбыз бер булган, әмма төрле территориаль шартларда яшәү безне ике төрле һәм каршылыклы җәмгыяви төркемнәргә бүлгән. Татар белән башкортның, кем әйтмешли, ише килсә дә, төсе килми. Геосәясәт үзтиңләнүдә алар капма-каршы типтагы халыклар: татар — талассократия вәкиле (Су, Елга стихияле), башкорт исә — теллурократиянеке (Коры, Тау стихияле). Татарда — динамизм (Идел йогынтысы) һәм миссионерлык (Дала тәрбиясе), ә башкортта борынгылыкны саклау һәм кисәкләнүгә-аерымлыкка омтылу (Тау тәэсире). Татарның милли символы Идел-Агидел (Елга инешләрне җыя), башкортныкы — Урал (Тау — аеру символы). Безнең арада — геосәяси дуализм (Коры — Су каршылыгы). Шунлыктан мәдәни яктан без туганнар, ә дәүләтчелек мәсьәләсендә татар белән башкорт ирекле рәвештә (ә ирексезе безгә кирәкми) бергә була алмый. Моннан фаҗига ясарга ярамый, тик, ерактагы кояш җылырак була дигәндәй, ике туган гаиләсе арасында туганлык хисләре аерым яшәгәндә көчлерәк булганын истә тотып, безгә мәдәни чикләрне билгеләргә; туганлылык хисенә бирелеп, Идел-Урал идеясе кебек реальләшә алмаслык (ут белән суны кушып булмаган кебек елга белән тауны берләштереп булмый) геосәяси проектлар кормаска гына кирәк. Шуны танымасак, дәүләтчелек мәсьәләсендә дә (Татар-Башкорт Республикасы язмышы шикелле), мәдәният өлкәсендә дә (татар шагыйре М. Гафурины татар-башкорт шагыйре иткән кебек) без югалтуларга гына дучар булырбыз. Башкорт үзенчә, татар үзе теләгәнчә яшәсен. Безгә башкортныкы кирәк түгел, әмма үзебезнекен дә аңа бирмәскә тиеш. Без — туганнар, әмма үзбәяләнүгә, үз мирасыбызга үзебез хуҗа булырга хокуклы һәм тиешле туганнар. Юкса, туганлыкны саклыйбыз дип, озакламый Тукаебызны да башкорт шагыйр

Күрәбез ки, татарчылык-болгарчылык һәм татар-башкорт проблемаларының тамыры бер. Ул яшәү җирлегенә һәм дәүләтенә мөнәсәбәт (сәяси үзтиңләнү) буларак формалашкан милли аңга бәйле: татарчылыкның тарихи хәтерендә Далада дәүләт тотучы

булуы, Дала иминлеге өчен җаваплылык тойгысы, ягъни Дала хуҗасы икәнлеге сакланган. Болгарчылык һәм башкорт хәтерендә андый сәяси-мираси «йөк» юк. Киресенчә, алар хәтере Дала хуҗасына (татарга һәм урыска) буйсынган булуларын — димәк, аларга карата дошманлык тойгысы саклаган. Шуңа күрә аларның сәяси үзтиңләнүе таррак һәм үзләре яшәгән төбәк (болгарчылар — Идел буе, башкортлар — Урал) мөстәкыйльлегенә ирешү теләге белән чикләнә.

Әлеге проблемаларны чишү юлы да бар: аларның һәркайсына үзләренең сәяси, икътисадый вә мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлекләрен бирергә кирәк. Алар үз максатларынаирешсен өчен бер генә юл бар. Ул — мәдәни уртаклыкка нигезләнгән союз һәм, бер-берсен танып, үзләрен бер-берсенә каршы куймыйча, үзара ярдәмләшү (идеалда — бер зур сәяси көчнең аерым тармаклары шәкелендә эш итү). Юкса алар, урыс культурасындамы, читтән килгән башка культурадамы, йотылачаклар.

Геосәясәттә төп әһәмият этник якынлыкка яки дини кардәшлеккә түгел, ә географик язмыш уртаклыгына бирелә. Бу җәһәттән, бүгенге төркичелек һәм исламчылык идеяләренә дә тәнкыйди карап таләп ителә. Географик картага күз төшерик. Без төрки дөньяның да, ислам дөньясының да үзәгендә түгел, без аларның читендә яшибез. Димәк, икесендә дә төп рольне уйный алмыйбыз. Татар менталитеты моның белән килешергә теләми, чөнки ул акыл асты дәрәҗәсендә булса да, үзен пәйгамбәр сыйфатлы милләт дип таный (акыл белән танучылар да бар)[31]. Бу мәсьәләләрдә татарның амбициясе зурдан, әмма төркичелектәге безнең өстенлек белән Төркия, исламчылыктагы татар лидерлыгы белән үзләрен ислам дөньясы үзәге дип күрүче илләр килешә алмас иде. Шулай булгач, һәм төркичелек, һәм исламчылык безгә империягә каршы көрәштә ярдәмче тактик фактор гына була ала. Ни әйтсәң дә, татар либераль характерлы: ул үз өстенлеген дә көчләп тага алмый, башкаларныкын да кабул итәргә теләми. Ул — тигезлек һәм толерантлык яклаучы. Геостратегик проект турында сүз алып барганда яшәү җирлегебезнең урыны һәм милләтнең геотарихи вазыйфасы беренче игътибарга лаек, ә төркичелек һәм исламчылык безгә каршы көрәш сәхнәсенә әверелергә дә мөмкин. Милләтнең тарихи сабаклары да моны раслый. Милли идеяне тәгаенләгәндә моны истә тотарга кирәк. Инде килеп, төркичелеккә һәм исламчылыкка карата югарыда китерелгән фикер белән килешүчеләргә караганда аны кире кагучылар күбрәк булачагын да исәпкә алсаң, проблемага тәфсилләбрәк тукталу артык булмастыр.

Милләт тарихы белән кызыксынучыларга бер вакыйга тынгылык бирми: татар язмышы өчен хәлиткеч көннәрдә Төркия Казан ханлыгына ярдәм кулы сузмаган. Алай гынамы, Казан хансыз калгач казанлыларның хан җибәрү үтенече дә кире кагылган. Ни өчен? Канкардәшлек һәм динкардәшлек, ягъни төркичелек һәм исламчылык мантыйгыннан бу сорауга җавап юк [32]. Ә менә геосәясәт мантыйгы моңа җавап бирә. Әйе, җавап бар: ул — геосәясәт мантыйгы. Төркия, Византияне буйсындырып, Икенче Римның империячел сәясәтен дә кабул итә — чын теллурократик империя булып формалаша. Моңа госманлылар белән килешүгә килгән православие дине руханилары йогынтысы да үз өлешен керткәндер (православие һәрчак, һәр илдә континенталь империя идеологиясе булды һәм шулай булып кала). Алтын Урда Төркиянең төп геосәяси дошманнарыннан була. Ике тәкә башы бер табакка сыймый, диләр бит — бер үк диндәге ике кардәш халык империяләре арасында мәдәни, дини һәм территориаль өстенлек өчен геосәяси каршылык урнаша. Алтын Урданың таркалуы Төркия өчен отышлы була. Урталык Җирләренең яңадан җыелуы (әйтик, Казан тирәсендә) игътибарын Аурупага юнәлткән Төркиянең геосәяси ихтыяҗларына туры килми. Ул чактагы Төркия солтаны Сөләйман Кануни геосәяси ихтыяҗларга каршы килә алмый — аның өчен тылда берләшкән көч оешуына караганда үзара сугышып ятучы Алтын Урда кисәкләре саклануы кулайрак була. Ә Мәскәү киләчәктә көчәеп, Русия империясе корылу ихтималы һәм аның геостратегик максат итеп Төркияне юк итү идеясен кабул итәчәге ул чордагы вәзгыять югарылыгыннан күренми әле.

Бүгенге төркичелектә дә бу тарихи сабакны истә тотарга кирәк. Башында Төркия торган һәм кемализмга нигезләнгән төркичелек асылда империячел-шовинистик тәсмерле. Чөнки Төркия бүген ТАКО составында булса да һәм Аурусоюзга керергә омтылса да, бу — элитаның көчле союзник канаты астына керү нияте генә. Халыкның күпчелеге барыбер теллурократик-державачыл менталитетлы булып кала. Бүгенге Төркиядә өч төп көч көрәше бара: модернистлар (Көнбатыш тарафдарлары) аның Аурупа дәүләте булуын тели, исламчылар Якын Көнчыгыш белән бергә булуга омтыла, тарихи нигезләрен барлаучы милләтчеләр Каспий бассейнында һәм Урта Азиядә яшәүче төрки халыкларны җыюга йөз тота. Бу төркичелек тигезлеккә нигезләнмәгән, анда Төркия өстенлеге күздә тотыла. Мәсәлән, алар дөньяда иң камил ундүрт телнең берсе һәм төрки телләрдән бердәнбере булган татар телен төрек теленең диалекты итеп күрә карый.

Бездәге башында Төркия торган төркичелек һәм гарәби-төрки исламчылык, алар — тар җирчелек (болгарчылык) чагылышы. Чөнки болгарчылыкта геосәяси амбицияләр, әйдәүче булу омтылышы юк, ул — иярүче. Ул бөтен төрки дөнья киңлегендә фикерләми — үзе яшәгән җиргә нык береккән. Ул утрак тормыш холыклы. Татарчылык исә, Дала холыклы, ул үзен бөтен Урталык Җирләре өчен җаваплы сизә һәм шушы киңлектә фикерли. Анда Дала иминлеген саклау омтылышы аркылы геосәяси амбицияләр дә туа — ул ияреpгә теләми, үзен әйдәүче итеп бәяли. Һәм бу — бүгенге төркичелектәге татар-төрек каршылыгының асылын тәшкил итүче төп фактор. Әлбәттә, аның объектив нигезе дә бар: интеллектуаль потенциалының югарылыгы ягыннан да, мәгълүмати аралашу чараларының техник җиһазланышы мәсьәләсендә дә татар төректән калышмый. Татарчылык өчен Төркия мәдәни көндәш һәм геосәяси «дошман»: аның сәяси хәтерендә Алтын Урда карашы сакланган. Шуңа күрә, ул кемализм төркичелеген кабул итә алмый, ул төркичелек башында үзен күрә. Бу безнең иҗтимагый тормышта да чагылыш таба. Әйтик, латин графикасына күчү бәхәсендә катнашучы яңалифчеләрне — татарчылык, әлфабечеләрне (Төркия алфавитын яклаучыларны) болгарчылык чагылышы дип бәяләргә кирәк. Исламчылыкта төрки-гарәби исламны яклаучылар (таррак алганда, кадимчеләр) — болгарчылар, татар исламы яклылар (җәдитчеләр) — татарчылар.

Әйтеп үтәргә кирәк, татарчылыкның төркичелеккә һәм исламчылыкка менә шундый мөнәсәбәте татарның канкардәшлеккә һәм динкардәшлекә каршы булуын күрсәтми. Бу — тарихи-сәяси хәтер мәсьәләсе, ягъни дәүләтчелек варислыгына мөнәсәбәтне күрсәтүче фактор. Татар иҗтимагый хәтере үзенең Алтын Урда варисы икәнлеген бер вакытта да онытмады. Болгарчылар моны танырга теләми[33]. Бүгенге күчеш чорында, ягъни империя таркалуы һәм Урталык Җирләренең яңа нигездә оешуына бәйле рәвештә Алтын Урда варислыгы өчен сәяси көрәш барган вакытта, моның зыяны милли хәрәкәткә таркаулык кертү белән генә чикләнмәскә мөмкин. Бу — татарның геосәяси субъект булып танылуына һәм халыкара сәхнәгә чыгуына киртә куярга да мөмкин, чөнки безнең үзебезне Алтын Урда варислары итеп тану татарны Урталык Җирләрен җыючы итеп күрергә теләгән дөнья җәмәгатьчелеге өчен дә кирәк. Әйе, татарлар — Алтын Урда варислары. Шул исәптән, үзләрен «болгар» дип танучылары да. Чөнки бит Болгар ханлыгының дәүләти, мәдәни һәм этник мирасы үзе дә Алтын Урдага тоташкан. Һәм бүгенге буынга «Болгар ханлыгы — Алтын Урда — Казан ханлыгы — Казан губер-

насы — ТАССР — ТР» чылбыры аркылы килеп җиткән. Шәһәр культуралы болгар халкының күчмә кардәш кабиләләргә йогынтысы зур булган, мәҗүси Алтын Урда, кайбер башка факторларын исәпкә алмаганда, болгар культурасы йогынтысында ислам кабул иткән. Болгар вилаяте Сарайның сәяси һәм икътисадый яктан да төп таянычы булган, дияргә урын бар. Бу турыда Аксак Тимернең Болгар шәһәрен җир белән тигезләве дә сөйли. Әгәр Болгар Сарайга каршы булса, ул аны җимермәс иде, киресенчә, союзник итәргә тырышыр иде. Ул Болгар-Алтын Урданың сәяси вә икътисадый мөһим үзәге булуын һәм Алтын Урданы җимерү өчен Болгарны бетерергә кирәклеген аңлаган.

Болгар вилаятенең яңа башкаласы Казан да Олуг Урдага (Большая Орда) каршы көрәшмәгән. Олуг Урдага каршы Кырым белән Мәскәү көрәшкән. Беренчесе — Төркия йогынтысында, икенчесе — тәре йөртүчеләр ярдәмендә. Олуг Урда хәлсезләнгәннән соң аның үзәге Сарайдан Казанга күчкән, дип әйтү дөрес булыр. Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәт Сарайдан куылгач, юкка гына Казанга юл тотмагандыр — Сарайның дошманы булган Кырымга юнәлмәгән бит. Ул Кырымнан (Төркиядән) читтәрәк һәм Алтын Урданың дәүләти ышанычлы төбәге булган Болгар җирләренә өмет баглаган булыр. Башта, күрәсең, ул үз кулы белән кенәзлеккә ярлык биргән Василий II ягыннан яклау табуына ышаныптыр, урыс җирләренә (Белев шәһәре) юл тота. Тегесе моны куарга гаскәр җибәргәч, аны тарихка кереп калган батырлык һәм хәрби осталык күрсәтеп тар-мар иткәннән соң, Казанга юнәлә. Алтын Урда ханының килүе белән Болгар вилаяте Казан ханлыгы булып яши башлый.

Татар милли идеясен эзләгәндә күпләр, бигрәк тә соңгы вакытта, исламчылыкка мөрәҗәгать итә. Бу татарның бүгенгесе һәм якын киләчәктәге язмышына гына түгел, аның өченче меңъеллыктагы һәм тагын да ераграк киләчәгенә кагылышлы идея. Шуңа күрә, аңа тирәнтенрәк тукталу кирәк булыр.

Хәзерге ислам дөньясы бер генә төрле түгел, ул бүлгәләнгән. Анда — төрле идеологик, сәяси тенденцияләр, бер-беренә каршы геосәяси проектлар гадәти күренеш. А. Дугин язганча, төп идеологик агымнар түбәндәгеләр:

1) Иран фундаментализмы (континенталь типтагы, Америкага һәм атлантизмга каршы, геосәяси актив агым);

2) Төркиянең рәсми идеологиясе (атлантистик типтагы, пантюркизмга йөз тотучы агым);

3) Сүрия, Ирак, Ливия, [illegible]дан, күпмедер дәрәҗәдә Мисыр һәм Согуд Гарәбстанында өстенлек алган панарабизм идеясе

(төрле һәм шактый каршылыклы проектларны күздә тотучы агым);

4) Согуд Гарәбстанындагы ваһһабчылык тибындагы фундаментализм (атлантизмны яклаучы агым);

5) Ливия, Ирак, Сүрия кебек илләрдәге «ислам социализмы» тарафдарлары (бу агымны панарабизмның сул канаты дияргә була).

Ислам геосәясәтенә килгәндә, анда да уртак караш юклыгын искәртергә кирәк. Иран, Ирак, Сүрия, Ливия, Судан, Йемен Русиягә йөз тота һәм православие белән бергә католицизмга каршы сәясәт алып бара. Марокко, Алжир, Тунис, Мисыр, Төркия, Согуд Гарәбстаны, Берләшкән Гарәп Эмиратлары, Пакыстан Көнбатышка йөз тота. Әфганстан, Ливанның ачык геосәяси кыйблалары юк.

Атлантистлар, тулаем алганда, ислам дөньясын үзләренең геосәяси дошманы дип саный. Русия геосәясәтендә Иран төп союзниклар, Төркия дошманнар рәтендә санала, калганнары потенциаль союзниклар итеп карала.

Бездә нинди караш булырга тиеш соң, кемгә иярергә, кайсы агымда агарга тиеш татар? Һәм тиешме, безнең юлмы ул исламчылык? Исламчылык юлына бассак атеистлар һәм керәшеннәр урыны кайда булыр? Аннан соң, ислам дөньясы үзе безгә нинди карашта һәм татарга нинди урын бирә? Милли хәрәкәт исламчылык мәсьәләсендә үз юлын билгеләгәндә боларның барысын да истә тотарга бурычлы.

Татарның күпчелеге православие дөньясында һәм аның цивилизацион йогынтысында яшәргә мәҗбүр, чөнки Русиядә ул — рәсми дин. Православиенең үз геосәясәте бар һәм ул империя геосәясәтенә тәңгәл — моны чиркәү дә, дәүләт тә яшерми. Ул мөселман-татарларга мөнәсәбәтен бервакытта да яшермәде: ирекле рәвештәме, алдапмы, көчләпме — чукындырырга һәм урыслаштырырга тырышты. Рухи яктан бирешми икән, физик яктан юк итәргә[34]. Аның ягъни православие-империя геосәясәтенең, католицизмга (Көнбатышка) мөнәсәбәте дә ачык: аларның бер-берсенә каршы икәнен һәр ике як таный һәм моны аларның конкрет гамәлләре дә раслый.

Югарыда китерелгән конфессиональ геостратегик карашларны бергә җыеп, татар мәнфәгате күзлегеннән геосәяси анализ үткәрсәң, ике әйбергә игътибар итәсең: беренчедән, диннәр һәм аларның юнәлешләре арасында да геосәяси дуализм чагылышы бар, икенчедән, татарга беркемгә дә иярмәскә кирәк, чөнки аның үз исламы булырга тиеш. Моның соңгысы җәмгатьчелек тарафын-

нан бик тискәре кабул ителә. «Татар исламы» дип сүз чыгарсаң, һәр милләтнең үз исламы буламыни, ислам — ислам инде ул, ислам юлы бер инде, дип авызны ябарга ашыгалар. Әйе, исламны йолалар, ритуал дәрәҗәсендә генә кабул итсәк, чынлап та, шулай сыман, гәрчә, бу мәсьәләдә дә әледән-әле каршылыклы сораулар туып торса да (мәсәлән, Мурманскида яшәп ураза тотучы мөселманнар өчен кышын өч ай кояш чыкмый, җәен өч ай батмый торган шартларда сәхәр ашау һәм авыз ачу вакытын билгеләүдә). Әгәр инде үзебезне мәдәниятле халык итеп күрәсебез, ислам цивилизациясе вәкиле итеп таныйсыбыз һәм танытасыбыз килсә, ритуал үтәү генә җитми. Ул чагында әлеге цивилизациягә, аның аркылы гомумкешелек цивилизациясенә керткән өлешебез турында уйланырга кирәк була да. Шунсыз дөнья сәхнәсендә безгә урын юк, шунсыз урыслашуны гарәпләшүгә алыштыру гына көтә безне (бүген мәдрәсәләрдә укучы кызларыбызның бездәге географик-климатик һәм яшәү шартларына яраксыз вә исламга бернинди катнашы булмаган гарәп киемнәренә төренеп йөрүендә дә чагыла).

Монысы — милләтнең «тышкы сәясәте»нә кагылышлы мәсьәлә. Эчке проблемаларга килгәндә, үзебезнең милли яшәеш тәҗрибәсе тудырган һәртөрле сорауларга җавап бирерлек милли фәлсәфәбезне булдыру шарт. Шунсыз, милләтнең күпчелеге кешелек казанышларыннан хәбәрдар булган хәзерге заманда, иман яңарту мөмкин булмаячак — зыялылар исламны ритуал-йола дәрәҗәсендә генә кабул итә алмый. Димәк, шунсыз татар бербөтен милләт булып формалаша һәм үзен саклый да алмаячак. Узган гасырларда халкыбызның мөшкел хәлгә төшүе сәбәпләре рәтендә «кара халык» белән «аксөякләр» арасында уртак тел булмавын да танырга кирәк: зыялылар гарәби телле һәм фәлсәфәле, гади халык татар телле булган. Җәдитчеләр, проблеманы аңлап, исламны «татарлаштыру» эшен оештырганнар, бу өлкәдә шактый уңышка ирешкәннәр. Бәхетсезлегебезгә, сәүит чорында җәдитчеләр мирасын үзләштерү һәм үстерү мөмкинлегеннән мәхрүм ителдек. Бүген иҗтимагый фикерләүдә ислами татар фәлсәфәсе юк дәрәҗәсендә, гәрчә аны тудырган татар укымышлылары мирасының югарылыгы дөньякүләм танылган факт булса да.

Геосәяси адымнарны билгеләгәндә канкардәшлектән яки динкардәшлектән чыгып түгел, геосәяси ихтыяҗларга, җирлек-күршелеккә һәм шуңа бәйле рәвештә формалашкан менталитетка (теллурократия яки талассократия вәкиле булуга) карап эш итәргә кирәк. Ислам, цивилизация буларак, Тигр-Ефрат буйларында формалашкан, Нил һәм Урта диңгез буйларында чәчәк аткан. Ислам — rimlandлылар дине. Ул талассократиягә тартымрак. Шуңа

күрә талассократик менталитетлы Идел буе болгар бабаларыбыз күңеленә ул хуш килгән һәм алар аны үз теләкләре белән кабул иткән. Ә теллурократик табигатьле урысларның бабалары аны кабул итә алмаган (моны исламда хәмер тыелу белән генә аңлату аның субъектив ягын гына чагылдыра), континенталь-империячел православиене якынрак күргән. Шул сәбәпле, ислам теллурократик культуралы фарсыларга, төрекләргә, Урта Азия төркиләренә, Дала халыкларына дәүләтчелек үсешен континенталь империягә җиткерерлек ярдәм итә алмаган.

Алай гына да түгел, үзәге Багдадта булган вакытта ислам цивилизациясе чәчәк аткан, кешелек цивилизациясенең үзенә кадәр булган бөтен казанышларын үзләштереп, аны яңа югарылыкка күтәргән. Ул чагында инсаният Акылының төп йорты Багдадта булган. Ә менә ислам цивилизациясе үзәге континенталь психологияле Төркиягә күчкәч, ул сүлпәнәю кичергән. Чөнки теллурократиянең омтылышы — пространство киңәйтү, империя төзү һәм моңа ирешүдә төп чыганак һәм таяныч — көч. Ислам исә дөньяви гамәл-мәшәкатьләрдә бернинди көчне дә танымый — мөселман өчен Аллаһыдан башка буйсынырдай бер генә зат яки көч тә юк, христиан динендәге кебек, Аллаһы белән кеше арасында арадашчы да юк. Ислам — иң демократик дин: ул, кешенең рухын түрәләргә яки башка затларга (әйтик, руханиларга) буйсынудан арындырып, аңа үз акылы белән яшәргә тулы «хокук» бирә (мөэмин мөселман Аллаһыдан башка беркем алдында да җаваплы түгел). Кыскасы, теллурократиянең асылында — тупас көч, ислам тәгълиматында — Акыл. Беренчесендә шәхесне җәмгыятькә, дәүләткә, патшаларга, чиновникларга буйсындыру (шунсыз империя яши алмый), икенчесендә — шәхес иреге, табигыйлыкка нигезләнгән җәмгыяви тәртип, либерализм. Беренчесендә җәмгыятьне (дәүләтне, милләтне, сыйныфны) оештыру һәм тоту формасы — империалистик тәртип, икенчесендә — ирекле (бер-береңә кирәклекне акыл белән аңлап) берләшү, ягъни демократия.

Шуңа күрә кайбер урыс державачыларының исламны «җигеп» империяне торгызу планы (КОБР «Мертвая вода» программасы) нигезсез — ислам империячел көчләргә «хезмәт итми» (моны Госманлы Төркия язмышында да күрәбез). Үзбәк хан Алтын Урдада ислам динен керткәннән соң күп кенә теллурократик холыклы татар морзаларының Мәскәүгә качуы тикмәгә түгел. Исламның Көньяк-Көнчыгыш Азия яр буйларында таралуы да юкка түгел. Болар барысы да — исламның талассократик-rimland/лы булуына бәйле. Бу җәһәттән, АКШ белән талассократик мөселман илләре союзы да табигый. Күпләрне гаҗәпләндергән факт — Америка-

ның берничә тапкыр талпынып та Багдад «режим»ын тар-мар итмәве дә аңлашыла: АКШ-Ирак каршылыгы Җир-Су дәрәҗәсендәге каршылык түгел. Шуңа күрә АКШ С. Хәсәенне юк итми, аны теллурократик Иранга каршы тота.

Исламчылык мәсьәләсендә Коры (Чүл) стихиясе йогынтысында формалашкан хәзерге гарәби ислам талассократик Планетар Зур Пространствода киң җәелә алмаячак. Монда rimland калыпларында формалашкан, нигезендә җәдитчелек яткан татар исламы өстенлек алачак. Американың төрки халыкларга кагылышлы геостратегиясе төркичелек һәм исламчылык мәсьәләсендә әйдәп баручы көч итеп бүген Төркияне күрә. Әмма бу да озакка бармас. Чөнки, югарыда әйтелгәнчә, талассократик караш анда элита арасында гына таралган, киң катлам гавәм халкы исә, теллурократик-державачыл карашлы булып кала. Иртәме-соңмы, төркичелек һәм исламчылык башына чын rimland психологияле Зур Татарстан басарга тиеш була.

Татар исламы гомуми исламнан нәрсә белән аерыла? Мондый сорау, илаһи тәгълимат өчен бик урынлы булмаса да, «татар исламы» диюгә, аның тууы табигый. Берни белән дә аерылмый. Тик гомуми ислам дигәнебез — ул, Ф. Әмирхан әйтмешли, гарәпләшкән ислам. Татар исламы дигәнебез — исламның үз асылына кайтуы дигән сүз. Көнчыгыш исламы теллурократик сәяси көчләр тарафыннан үз файдаларына «каралтылган», җәдитчеләр аны «агарткан» — үзенең талассократик асылына кайтарган. Гарәби-төрки ислам традициясе кеше рухының илаһи көчкә буйсынуын мотлаклаштырып (абсолютлаштырып) кәндәлек вак-төяккә кадәр җиткерә, борынгы патшаларны (хәтта Искәндәр Македонияләне) пәйгамбәрләр дәрәҗәсенә күтәреп, бүгенге түрәләргә мөнәсәбәтле рәвештә, алар хакимияткә Аллаһы кодрәте белән килгән, дигән принциптан чыгып эш итә, аларга сүзсез буйсынырга куша. Татар исламы, Коръәнне сәясәттән аерып, аның асылын аңлап яшәүне күздә тота. Ягъни Аллаһы Глобаль Кануннар урнаштыра, шулар аркылы Галәм белән идарә итә, ә җирдәге тормышны Кешегә тапшыра. Ул дөрес эш итсен өчен аңа Аллаһы Акыл биргән һәм Коръән иңдергән. Кеше ирексез түгел. Кеше Җирдә тулы ирекле. Аны чикләүче ике генә көч бар: Аллаһы билгеләгән вә аңа Коръән белән җиткерелгән табигать законнары һәм Аллаһы биргән үзенең акылы. Коръән бөтен нәрсәне тыймый бит, кешегә үзенә уйларга, яшәү тәртибен сайларга ирек бирә, тик табигать законнары кысасыннан гына чыкма.

Бездә исламга рациональ һәм иррациональ караш бар. Х гасыр башында татар иҗтимагый аңында җәдитчелек җиңеп, рациональ

караш хөкем сөргән. Ләкин ул сәүит чорында юкка чыккан. Бүген ислам безгә тормыш өчен бик авыр, җәмгыяви идеаллар җимерелгән-кырылган, материализмга нигезләнгән марксистик фәлсәфә җимерелгән заманда кайта. Тарих күрсәткәнчә, мондый кризис шартларында җәмгыять мистикага бирелүчән була. Шул сәбәпле безгә иррациональ ислам кайта. Монда безнең аңга православиедәге мистик дини тәгълиматларга нигезләнгән урыс культурасы йогынтысын да танырга кирәктер. Иман яңартабыз, шуның белән милләтнең рухын ныгытабыз, дибез, һәм моның белән барыбыз да килешәбез сыман. Хәлбүки, бу гына җитми. Чөнки дингә иррациональ караш ислам кысаларына сыймый. Ислам фәлсәфәсе акылга нигезләнгән. Бабаларыбызның традицион хәнәфи мәзһәбендә рух төшенчәсенә рациональ караш булган. Андый караш рухны билгеләүче факторлар буларак гыйлемлеккә, акылга, фикерләүгә нигезләнгән инануны (аңны, ихтыярны, хисне) күрә.

Исламчылык — милләт язмышы өчен хәлиткеч проблема. Алга таба аңа кагылышлы мәсьәләләрнең башка якларына да тукталырбыз. Хәзергә аның үзтиңләнүгә кагылышлы ягын йомгаклап шуны кисәтик: ислам цивилизациясе вәкиле булган өчен генә мөселман илләренә йөз тоту безнең өчен сәяси хата булыр иде (бу Чечня мисалында ачык чагылды). Мөселман илләренең геосәяси ориентацияләрен белеп эш итәргә кирәк. Гомумән, мөселман илләре татар өчен төп союзниклар була алмый, бу безне «ярдәмче» вазыйфасын үтәргә, икенче-өченче сортлы милләт булып калырга мәҗбүр итә. Геосәясәттә мөстәкыйль роль уйныйк дисәк (шунсыз татарның саклану шансы бик түбән), дөнья сәясәтендә мөселман илләренең безгә карата арадашчы вазыйфасын гына үтәвен (берәүләр атлантизм ягында, икенчеләре аңа каршы) истә тотып, элемтәне турыдан-туры АКШ-Израиль белән ялгарга кирәк. Без — ислам дөньясының интеллектуаль үзәгенә әверелеп, ислам тәгълиматына нигезләнгән заманча яшәү тәртибе үрнәген (ул бездә җәдитчелек, Көнбатышта Ауруислам дип атала) Аурузия киңлегендә күрсәтеп, Дөньяви Яңа Тәртип урнаштыруда актив мөстәкыйль роль башкарырга лаеклы милләт.

МИЛЛИ ИДЕЯ

Татар милли хәрәкәте тар кысадагы формаль мөстәкыйльлеккә ирешсә дә, гамәлдә империя богавыннан арына алмады. Халык аңында яңа идея юк, алга таба нишләргә, дигән сорауга җавапны белмибез — хакимият, зыялыларыбыз җәмгыятькә аны бир-

мәде. Халык нишләсен, ул яңасы булмаганда искене ямап кия — иҗтимагый аңда искелекнең яманнарын онытырга тырышып, аның уңай якларын искә төшерә — шулай социализмны сагынып сөйли башладык. Алда маяк күренмәсә, халык артка карый. Милли сәяси аң, акыл киләчәкнең җәмгыяви образын күзалламаса, яшәү үрнәген милләткә хәтер күрсәтә. Шуның белән йә нарсицизмга (ерак үткәне искә төшкәндә), йә мескенлеккә (үткәненең якынрагын искә алганда) бирелеп яши, алга омтылмый. Прогресс булмаган хәрәкәт, агымсыз су шикелле, «сазлык»ка әйләнә. Милләттә алга омтылыш тудыру һәм тәрбияләү өчен яңа, аның мөстәкыйльлекларга юнәлгән үсеш юлын билгеләүче милли идея кирәк.

Күпчелек тарафыннан үзләштерелгән уртак милли идеология булмавы милли аңның түбәнлегенә китерә, аның социаль ихтыяҗларга (ашау кайгысына) бәйлелеген көчәйтә. Бу очракта һәркем үз ихтыяҗы белән яши. Шунлыктан бердәмлек какшый, таркаулык үсә, милли ихтыяҗлар үз әһәмиятлелеген җуя һәм иҗтимагый аңдагы кыйммәтләр иерархиясендә түбән дәрәҗәле булып кала. Алай булмасын өчен милләтнең саклану, яшәеш һәм үсеш юлларын билгели торган иерархияле кыйммәтләр системасы — милли идеология һәм аның асылын чагылдыручы милли идея булырга тиеш. Менә шундый яшәеш кыйммәтләре системасын формалаштыруны татар милли хәрәкәте үз бурычларының нәүбәттәгесе икәнен аңларга тиеш. Юкса... Әгәр гаиләдә уртак кыйммәтләр, уртак максат-ниятләр һәм омтылышлар булмаса, һәркем юрганны үзенә тартып яши, бердәмлек булмый. Ахыр чиктә гаилә таркала. Мондый күренеш милләтләргә дә хас.

Без Көнчыгыш һәм Көнбатыш цивилизацияләре арасында — урталык җирләрендә яшибез. Шунлыктан менталитет та һәм матди (Көнбатыш), һәм рухи (Көнчыгыш) кыйммәтләрнең берсен дә кире какмый торган урталыкны яклаучы булырга тиеш. Мәдәнияттә һәм диндә шундый милли аң тәрбияләүне җәдитчеләр башлаган, әмма сәясәттә (дәүләтчелеккә карашта) бу мәсьәлә моңарчы идея дәрәҗәсендә дә хәл ителмәгән. Монда төп каршылык — татарның ике төрле менталитетлы булуында. Болгарчылар күңеленә Идел буе хуш килә, татарчыларга исә Дала киңлеге кирәк. Милләткә дәүләтчелек мәсьәләсендә дә уртак карашка килү вакыты җитте. Һәм моны безнең буын эшләргә тиеш.

Хәлбуки, милли идея билгеләгәндә безнең буын өчен авыр булган тагын бер фактор бар — без цивилизацион кыйммәтләр алмашынуын исәпкә алырга тиеш. Эш шунда ки, бүгенге глобальләштерү матди кыйммәтләргә өстенлек бирүче иске цивили-

зацияон традицияләргә нигезләнгән. Бу цивилизация кешелек тарихының индустриаль чорында позитив ролен уйнады: ул яңа ачышлар бирде, планетар акыл үсешенә китерде. Ләкин хәзер ул инкарьне инкарь итү законы нигезендә чынбарлык белән глобаль каршылыкка керә. Бүгенге дөньяның глобаль каршылыгын аңлау һәм аны чишү юлын табу — кешелек алдында торган төп проблема менә шунда, ди Шмитт. Аныңча, техниканың алга таба үсеше кешегә яңа пространстволар ача алмый, ә, киресенчә, аны чикли. Хәзерге техника кирәк һәм файдалы, әмма аның үсеше әлеге глобаль каршылыкны хәл итә алмый. Яңадан-яңа проблемалар гына тудыра, глобаль кризисны кискенләштерә. Мондый вәзгыятьтән чыгу юлын, космик ачышларда түгел, бәйдән ычкынган техниканы йөгәнләүдә эзләргә кирәк. Кем беренче булып шуңа ирешсә, шул кешелекнең бүгенге глобаль кризисы сәбәбе булган каршылыкны аңлар, «нишләргә?» дигән сорауга җавап табар, һәм бу яңа Геракл каһарманлыгы булыр, дип яза Шмитт. Яңа Геракл каһарманлыгын татар күрсәтергә тиеш. Әлеге каһарманлык чыганагы — татар исламында.

Мондиализм фикерләве һәм тәртибе урнашуы белән тарих бетмәячәк (геосәяси дуаилзм юкка чыкмаячак), тик кешелек үз цивилизациясе үсешендә яңа эпохага гына күсәчәк. Моңарчы геосәяси дуализм кешелек тарихында пространстволар өчен көрәш буларак чагылыш тапты. Пространстволар бүленеп бетте, яңадан бүлү өчен көрәш Кешенең үзен һәм бөтен биосфераны һәлакәткә китерәчәк. Планетар Акыл моны тану дәрәҗәсенә үсеп җитте. Әмма алга таба үсеш кайсы юнәлештә барачагы турында уртак фикергә киленмәгән. Моңа хәтле тарих үсеше Коры һәм Су көрәше сәхнәсенең катыдан йомшагракка күчү юнәлешендә барды (Җирдән-Диңгезгә). Мантыйк буенча алга таба үсеш Судан сыеграк булган Һавага (авиация), аннан Эфирга (космонавтика) күчәргә тиеш кебек иде. Шулай дип фаразлаучылар да булды. Әмма, Шмитт белән килешергә кирәк, үсеш бу юлдан китә алмый. Күрәсең, моның өчен кешелеккә тагын бер этап үтәргә — Планетар Акылга югарырак дәрәҗәгә үсеп, илаһи тагълиматның адәми затларга тиешле өлешен үзләштерү чорын узарга кирәктер. Һәм бу — кешелек алдында соңгы вакытта туган глобаль тарихи проблема («вызов»).

Бүгенге тарихи чакырыш («вызов») кеше санының чамасыз үсүенә һәм кешелек цивилизациясе векторы шушы чиксез үрчүче кавемнең туймас нәфесен канәгатьләндерүгә юнәлтелгән булуына бәйле. Кешелек яшәеше өчен хәзерге иң зур әһәмияткә ия булган планетар проблема — ул чамасыз матди ихтыяҗларны

максимум канәгатьләндерү максатындагы техник прогресс белән биосфера арасындагы каршылык. Кешелек бүген үзе утырган ботакны кисүче Ахмакны хәтерләтә. Ул никадәр тизрәк кисә, шул кадәр матди яктан мулрак яши. Шуңа күрә кисүне тизләтү өчен ул яңадан-яңа техник прогресс ысулларын куллана. Ботак юан (биосфера потенциалы зур), әмма чиксез түгел. Мул тормышта Ахмак үзе дә симерә, авырая (халык саны арта), ботакның киселмәгән өлеше дә күзгә күренеп кими — менә-менә өзелеп төшәр. Ботак (биосфера) бөтенләй киселеп бетеп, Ахмак белән бергә галәми упкынга төшеп һәлак булмасын өчен нәрсә эшләргә — инсаният алдындагы бүгенге чакырыш менә шундый. Ә җавабы нинди? Анысын ислам бирә: «Исраф-әл-хәрам».

«Исраф-әл-хәрәм», ягъни Ходай биргән һәр нигъмәтне кирәгеннән артык куллану, исраф итү — Аллаһы яратмаган, гөнаһ гамәл икәнен тану татар культурасының асылын тәшкил итә. Әгәр милләт язмышын кешелек үсеше тенденцияләре аркылы карый башласаң, мондый культураның башкаларга да үрнәк булырлыгын, «Исраф-әл-хәрәм»ның инсаният үзенә яшәү принцибы итеп алырга тиешле кагыйдә икәненә инанасың. Әлбәттә, үзе генә түгел, ә акылга нигезләнгән ислам тәгълиматының төп кагыйдәсе буларак һәм, техник прогрессны кире какмыйча, аны иң әүвәл табигатьне саклауга юнәлтүче (бүгенге кебек куллану ихтыяҗын канәгатьләндерүгә генә түгел) татар исламы белән берлектә. Менә нәрсәгә бәйләнгән татарның ерак киләчәге! Менә нәрсә белән билгеләнә аның өченче меңъеллыктагы миссиясе!

Зур Пространстволар үсеше чорындагы үзенең тарихи юлын кешелек геосәяси дуализм принцибы аркылы гомумиләштерде. Бу үсеш Глобаль Зур Простанство дәрәҗәсенә җиткәч, киләчәкне әлеге принцип белән аңлату кыенлашты. Әмма моның сәбәбен әлеге дуализм бетүе белән түгел, ә аны пространство белән генә бәйләп карауда эзләргә кирәк. Коры — Су каршылыгы — ул бит цивилизацияләр каршылыгы. Бу җәһәттән Һантингтон концепциясе чынбарлыкка якынрак. Алга таба геосәяси дуализм цивилизацияләрнең илаһи тәгълиматка якынрак һәм ераграк булганнары арасындагы көрәш формасында чагылыш табачак. Шуна күрә, кешелек алдындагы глобаль проблеманы чишү юлын һәм шулай ук милләтебезнең киләчәк юлын да ШГИТ — шактый гомуми идарәчелек теориясе (ДОТУ — довольно общая теория управления) ярдәмендә эзләү хаклы булыр.

ШГИТ, дөнья төзелешендәге теләсә нинди вакыйга идарә итү яки идарә ителү сәреше буларак карала ала, дигән тезиска нигезләнә. Әлеге вакыйгалар никадәр генә төрле булмасын, аларны ида-

рә итү яки идарә ителү процесслары дип караганда, аларның барысына да хас булган уртаклык күрергә була. ШГИТ менә шушы уртаклыкны чагылдыра да инде. Җәмгыятьтә (җөмләдән милләттә) һәрчак ниндидер кимәлдә идарә итү (ителү) сәрешләре бара. Аларның тасвирламасы милләтнең культурасында урын ала. Димәк, идарәчелек теориясе күзлегеннән, культура — ул идарә итү (ителү) концепциясе. Социология күзлегеннән исә, идарә итү концепциясе иделогия дип атала. Бу уңайдан әйтергә кирәк, идеологиясез җәмгыять була алмый, чөнки идарә итү (хакимият) культураның бер өлеше булып тора һәм җәмгыять һәрвакыт идарә ителә.

ШГИТ нигезендә милләт язмышына карата ике генә бурыч куела ала: идарә итү (әгәр идарә итүче көч милләт яшәеше белән турыдан-туры идарә итәргә теләсә) һәм үзидарә (әгәр милләт үз вазыйфасын тиешле юнәлештә һәм дәрәҗәдә үтәүдә ят көчләр тыкшынуын теләмәсә). Ягъни йә милләт белән ятлар идарә итә, йә ул үзе белән үзе идарә итә. Моның беренчесенә мисал итеп Русия империясендәге халыклар яшәешен китерергә була. Анда православиегә нигезләнгән яшәү культурасы тулысынча империягә хезмәт итә: бөтен күпмилләтле ил үзәктән идарә ителә. Икенчесенең үрнәген яһүдләр системасында күрәбез. Алар, төрле илләрдә, төрле юридик һәм мәдәни мохиттә гомер кичерсәләр дә, үзләренчә яшиләр, шуның белән милләт бөтенлеген саклыйлар. Урыс культурасын үзләштергәнче татар да үзенчә яшәгән, ислам культурасы белән үзидарә ителгән. Тормышыбызда урыс культурасы өстенлек алганнан соң без хәзер империя тарафыннан идарә ителәбез. Һәм бу — милләтнең ассимиляцияләнүен котылгысыз итүче фактор. Глобальләштерү чорында үзидарә системасы булмаган милләтләрнең үз культурасын саклау ихтималы юк дәрәҗәсендә. Мәдәни хезмәттәшлек аркылы уздырыла торган агрессиягә, ягъни идарә итүче көчләрнең үз идеологияләрен тагуына (әйтик, чукындыру, сыйфый көрәш яки авразиячелек идеяләре аша) каршы тору бик авыр. Хәзер агрессор (идарә итүче көч) элеккегә караганда отышлырак ысуллар белән эш итә: буйсынган халык культурасын үз максатларына яраклы итеп бозып (формасы белән күпмедер кимәлдә милли, эчтәлеге белән тулысынча идарә итүче көчләрнеке булган мәдәният тагып), аны тарихи-мәдәни тамырларыннан аера. Нәтиҗәдә, яңа буыннар үз җирлекләренә һәм генетик хәләтләренә ят булган яшәеш кагыйдәләрен кабул итә, ялган прогресс юлына баса. Һәм тарих күкесе милләтнең яшәү көннәрен саный башлый.

Бүгенге милли аң, иҗтимагый фикерләү, милләт яшәешенә һәм үсешенә кагылышлы бәхәс-дискуссияләр, иң югары дәрәҗә-

дә дигәннәре дә, төрле тармактагы сәяси, икътисадый, хокукый, экологик һ.б.ш. фәнни белемнәргә нигезләнгән. ШГИТ буенча бу — өченче һәм түбәнрәк өстенлекләр (приоритетлар). Ә бит милләт язмышын үзидарә (үзеңчә идарә ителү) максатларын истә тотып тикшергәндә яки киләчәкне билгеләгәндә беренче өстенлектән башлау зарур. Өстенлекләр тартибен ШГИТ түбәндәгечә бирә:

1) методологик өстенлекләр (галәми караш, ягъни акыл һәм фикерләү табигать кануннарына, илаһи тагълиматкә нигезләнсен);

2) хронологик өстенлекләр (җәмгыяви сөрешләр агымы юнәлеше, кешелек цивилизациясе үсеше тенденцияләре);

3) фактологик өстенлекләр (аерым сөрешләрне һәм аларның үзара бәйләнешләрен аңлау, төрле фәннәр, технологияләр буенча гыйлем, ягъни, материалистларча әйтсәк, фәнни караш);

4) экономик өстенлекләр (финанслар, матди байлык туплау һәм аларны үз файдаңа куллану ысуллары);

5) физик, биологик һәм милли-мәдәни геноцидка каршы тору (сугышларга, АЭС төзүгә, наркоманиягә, эчүчелеккә, экологик пычраклыкка, тәмәке тартуга каршы һ.б.ш. чаралар, милли мәдәният, мәгариф һәм дин системаларының мөстәкыйльлегенә ирешү);

6) милләткә тискәре йогынты ясаучы башка гамәлләргә каршы тору (хәрби хезмәттә милли подразделениеләр булмау, административ берлекләрнең чикләрен милләтне бүлгәләү максатында билгеләү, талантлы яшь белгечләрне читкә җибәреп милләттән элитасын аеру, белгечләрне читтән китереп татар мохитен бозу, сыйфатсыз ризык тарату, чамасыз дару куллану, катнаш никахлар, буйдаклык һ.б.ш. булдырмау өчен тырышу).

Милләтнең саклануы һәм үсеше гарантияле булсын дисәк, ике шартны үтәү зарур: беренчедән, үзидарә системасы булсын, икенчедән, бу система ШГИТ өстенлекләре иерархиясенә нигезләнсен. Үзидарә системасының максатчан һәм нәтиҗәле эшләве өчен аның даими рәвештә өч төрле мәгълүмат тупланмасыннан файдалануы кирәк:

а) милли максатлар векторы (идеаль идарә ителүне күздә тотып, өстенлекләр иерархиясе нигезендә төзелгән аерым максатлар җыелмасы);

б) ирешелгән милли максатлар векторы (беренчесенә кергән максатларның тормышка ашырылганнары җыелмасы);

в) идарә ителү ялгышлары векторы (беренче һәм икенче векторларның аермасы).

Табигый ки, моны кем эшләргә тиеш, дигән сорау туа. Дәүләт дияр идек, татар үз дәүләтендә генә яшәми, ул таралган-сибел-

гән. Алайса кем соң? Җавап табу өчен идарәчелек өстенлекләре иерархиясенә игътибар итик. Анда беренче урында галәми караш, илаһи тагълимат. Ә ул Коръәндә бирелә. Моннан ике нәтиҗә ясау сорала: беренчедән, милли идеология Коръәнгә нигезләнергә тиеш, икенчедән, милләтнең үзидарә системасы башында Коръәнгә нигезләнеп фикерләүче милли идеологлар торырга тиеш. Димәк ки, милли үзидарә системабызны оештыру вазыйфасын руханилар үз җилкәләренә алырга тиеш булып чыга түгелме? Хәер, бу яңалык түгел, һәрчак һәм һәр милләттә дә милли идарә (үзидарә) башында жрецлар торган. Һәм бу табигый хәл, чөнки дин бит — ул милләтнең үзидарә системасы. Милләткә изгелек белән яманлык исемлекләрен төзеп, гөнаһ төшенчәсен аңына сеңдерсәң һәм һәр кешегә изгелекне вә яманлыкны язып бару өчен ике фәрештә билгеләсәң, ул үзе идарә итела. Ул булмаса, Һитлер яки Сталин режимнарындагы шикелле һәр кешегә шымчы билгеләргә һәм шымчыларның үзләрен күзәтүчеләр армиясе тотарга кирәк була. Җәмгыять алай озак яши алмый (фашизмның әлеге ике төре дә озын гомерле булмады). Колониаль режимда безне дин саклады диюебездә хаклык зур. Икенче төрле әйтсәк, безне хуҗа халыкныкыннан аермалы үзидарә системабыз булуы саклады. Диннәр бетерелеп, бар халыклар өчен гомуми идеология (эчке үзидарә системасы) урнашкач, милләт мәкерле ният белән билгеләнгән кәкре упкын юлы финишының туры сызыгына чыккан иде. Бар ул Ходай Тәгалә, бетерми Ул яраткан милләтен! Ул безгә яңадан иманга кайту мөмкинлеге тудырды!

ШГИТ буенча беренче өстенлек нигезендә менә шундый нәтиҗәгә киләбез. Язмышыбызны икенче өстенлек аркылы тикшерү нинди нәтиҗә бирер икән соң?

Галәмдә планеталар бик күп. Алар арасында Җир шуның белән аерыла: ул тереклек дөньясы, йорты (оясы) буларак яралтылган. Кешелекнең галәми вазыйфасы — шушы тереклек йортын саклау. Әлеге йортның төрле почмакларын саклау вазыйфасы аерым халыкларга-милләтләргә йөкләнгән. Татарның да Аллаһы йөкләгән үз геотарихи вазыйфасы бар. Аны дөрес аңлау өчен, бер яктан, милләтебез тарихына — язмышына игътибар итәргә, икенче яктан, дөнья үсеше тенденцияләрен истә тотарга кирәк. Татар тарихы — ул аның үз тирәсендәге кавемнәрне җыю һәм саклау тарихы. Ул — бер генә түгел, күп дәүләт төзегән һәм тоткан халык: Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы һ.б. ханлыклар, Татарстан Республикасы. Шунысын да искәртү зарур, татар бер вакытта да дәүләтчелеген югалтмаган (хәтта Русия империясе составында да Казан губернасы, ТАССР, ТР шәкелләрен-

дә дәүләти үзбилгеләнүен саклаган), дәүләтчелеге формаларының күчүчәнлеген (преемственность) тәэмин иткән.

Татар тарихының шундый үзенчәлекле булуы аның Елга (Тугай) стихиясендә формалашуы белән аңлатылырга тиештер. Татар гына түгел, Коры һәм Су чикләре зонасында яшәүче күп кенә башка халыклар да, тарихның географик заряды «авырлыгын» тартудан (континенталь Зур Пространство яулаудан) «азат» буларак, үз энергиясен мәдәни-интеллектуаль сферага юнәлтә. Менә шушы «җиңел» геосәяси потенциалны үз файдаңа «җигә» белү каршы көчләр белән көрәштә сәяси стратегия сәнгате югарылыгын күрсәтә. Татарның геотарихи вазыйфасы менә шушы геосәяси положение белән билгеләнә дә. Һәм бу, бүгенге күчеш чорында талассократик көчләр ихтыяҗына тәңгәллеге белән, Зур Татарстанның XXI гасырдагы юлын билгели. Ул — Көнбатыш белән союзда Урталык Җирләрен реформалау юлы. Безнең геотарихи вазыйфабыз һәр ике стихия (Су һәм Коры) өчен дә уртак булырлык, аларны бер-берсен «юк иткәнче көрәшү» геосәяси омтылышыннан арындыра алырлык (бу — Җир шарын һәлакәттән коткарып калу шарты), «Исраф-әл-хәрәм» принцибына нигезләнгән * идеологияле (татар исламы) яшәү үрнәге («Зур Татарстан моделе») бирү.

Татар-миссионер халык. Ул гомер — бакый миссионерлык белән шөгыльләнде. Нинди генә тарихи-сәяси күчешләр булуына карамастан, төрле культуралар, сәяси стройлар, җәмгыяви формацияләр өчен ул үзенең универсальлеген күрсәтеп килде. Һәрвакыт аны үз язмышы гына түгел, якын һәм ерак күршеләренеке, бөтен кешелекнеке дә кызыксындырды. Урталык Җирләрендәге бөтен сәяси катаклизмнарда да ул, актив катнашып, гаделлек яклады, тарихи әһәмияткә ия сәяси субъект булды. Бүгенге күчеш чорында да Урталык Җирләре язмышы татарның үз геотарихи вазыйфасын дөрес аңлавына вә үтәүенә бәйле.Бу татарның үз язмышы өчен дә хәлиткеч әһәмияткә ия, чөнки ул үзенең галәми вазыйфасын үтәгәндә генә яшәвен дәвам итәчәк. Дөньяви яңа тәртип чорында Урталык Җирләрендә төп җирле геосәяси субъектның ул үзе икәнен татар аңларга вә танырга тиеш! Милләт язмышына ШГИТ буенча икенче өстенлек югарылыгыннан карау менә шундый нәтиҗә бирә.

Милләтнең бүгенге миссионерлык вазыйфасы — үзебез аралашып яши торган күрше халыкларны дөньяви яңа тәртипкә

---

* Бусы исә, кешелек үзенең сан ягыннан үсешен ресурслар мөмкинлеге белән тәңгәл рәвештә көйләргә өйрәнгәнче, сыйнфый һәм милли каршылыкларның глобаль конфликтларга китерүеннән саклау өчен кирәк.

әзерләү. Әлеге тәртип — ул нәфесне тыярга өйрәнү, үзеңнән башка җәмгыяви төркемнәргә (җөмләдән милләтләргә, сыйныфларга) толерантлы мөнәсәбәт тәрбияләү, биосфераны саклау тәҗрибәсе белән уртаклашу һ.б. Бу вазыйфаны үтәү ике төп максатка хезмәт итәргә тиеш: 1) «Алтын миллиард» өчен көрәш глобаль катастрофага китермәсен; 2) «Күптөрлелек Бердәмлеге» урнашсын. Аларның һәр икесенә ирешү өчен ике юл бар: берсе — көч куллану (каршы якларның массакүләм юк итү коралларын да кертеп) һәм канлы сугышлар аша, икенчесе — акыл аркылы. Беренчесе — кешелек цивилизациясе өчен куркыныч юл, икенчесе — оптималь юл. Урталык Җирләрендә бүген урыс культурасы өстенлек итә. Шуңа күрә, империя геостратегиясе беренче юлны сайлый (моның теориясен Мәскәү мәктәбе евразиячелегендә, гамәлиятен империя хакимияте сәясәтендә күрәбез). Татар менталитеты (миссионерлык, җәдиди ислам культуралылык, ярдәмлелек-шәфкатьлелек, толерантлык, гаделлек сөю һ.б.) һәм аның географик таралганлыгы-сибелгәнлеге проблеманы икенче юл белән хәл итәргә мөмкинлек бирә. Менә нидән гыйбарәт татар юлы якын киләчәктә!

Югарыда әйтелгәнчә, татар милли идеясен билгеләгәндә дә киләчәгебезне ике этапка бүлеп карау дөрес булыр: якын киләчәк (XXI гасыр) һәм ераграк киләчәк (өченче меңъеллык). XXI гасырда да, өченче меңъеллыкта да милли идея югары милли культурабызны саклауга һәм үстерүгә бәйле. Ул милләтнең менталитетына тәңгәл килергә, аның асылын чагылдырырга тиеш. Менталитет исә яшәү җирлегенә бәйле рәвештә формалаша дидек. Шулай булгач, милли идея — ул милли аңдагы шушы җирлек шартларында формалашкан яшәү мәгънәсенең дәүләтчелеккә мөнәсәбәтен билгеләүче төп фикер, дип әйтә алабыз. Бармы татарның милли аңында нинди дә булса шәкелдә чагылыш тапкан шундый фикер? Әйе, бар, ул борынгы төрки бабаларыбыздан килгән халык мәкальләрендә гәүдәләндерелә. Инде әйтелгәнчә, бу — гыйбрәтле мәкаль: «Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада». Дөрес, борынгы бабаларыбыз Урталык Җирләрендә (Далада) дәүләт тоткан, аның хуҗасы булган заманнарда халык аның мәгънәсе хәзергегә караганда башкачарак аңлаган булырга кирәк: хәзерге күк Корының бер төре булган дала түгел, ә аларның дәүләте урнашкан геосәяси җирлек — Дала дип, ягъни бу мәкальнең мәгънәсе шундый булган: ана бала турында кайгыртырга тиеш, ә бала — дәүләт турында. Әлеге мәкальдә татарның милли аңы борынгы бабаларыбыз васыятенең кинаяле чагылышын саклаган һәм безнең буынга да җиткергән: миллитне саклауда һәм аның

үсешендә төп рольне милли тәрбия һәм милли культура уйный («Ана күңеле — балада»), ә аның имзынлеген гарантияләү исә — Аллаһы яшәү урыны итеп билгеләгән Дала хуҗасына йөкләнә («Бала күңеле — Далада»). Димәк, элекке төркиләрнең Даладагы варислары буларак, якын киләчәк өчен милли идеяне дә шундый мәгънәдә кабул итәргә тиешбез.

Зур Пространстволар үсеше глобальләштерү белән тәмамланганнан соң инсаният тәрәккыяте цивилизацияләр көрәше аркылы дәвам итәчәк. Бу милли идеядә дә чагылыш табарга тиеш булыр. Җиһандагы глобаль кризис сәбәпләрен өйрәнүчеләр кешелек язмышын галәми кануннарга бәйләп карау кирәклеген әйтә. Шуңа күрә, милли идеяне дә, ШГИТ өстенлекләренең беренчесеннән чыгып, Аллаһы тәгълиматы югарылыгында билгеләү дөрес булыр. Шушы югарылыктан караганда, милләтнең төп максаты — Аллаһы йөкләгән геотарихи вазыйфаны үтәү. Бу — якын киләчәктә, Дала биосферасын саклау, еррак киләчәктә — татар исламы ярдәмендә кешелеккә пәйгамбәрлек хезмәте күрсәтү.

Күрәбез ки, милли идеянең конкрет шигарен илаһи кануннарга һәм планетар геосәяси ихтыяҗлар таләбенә туры китереп һәм милли аңга нигезләнеп кабул итү мәслихәт. Моңа XXI гасыр өчен — «Татар күңеле — Далада», алдагы меңъеллык юлыбыз өчен «Татар исламы» шәкелендәге милли идеяләр тулысынча җавап бирә. Милли хәрәкәт хәзер аларның беренчесен гамәлләштерергә, икенчесенә нигез салырга тиеш.

ТАТАР КҮҢЕЛЕ — ДАЛАДА

Милләт язмышы өчен милли идеянең үзен генә түгел, аны гамәлләштерү юлларын да дөрес билгеләү хәлиткеч әһәмияткә ия. Әлеге юллар милли ихтыяҗларны канәгатьләндергән очракта гына, алар милли хәрәкәтне көткән уңышка китерәчәк. Ләкин татар яшәгән бүгенге шартларда бу җиңел эш түгел. Эш шунда ки, милли ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен халыкара сәясәттә танылган төп ысуллар (милли дәүләт һәм демократик хокук тәртибе) безнең әлегә ирешелмәгән көрәш максаты гына булып тора. Дәүләт тотучы милләтнең мәрхәмәтлелегенә дә өмет баглап булмый бу мәсьәләдә.

Ул урыс булган өчен генә дә түгел. Милли аңы югары булган бер генә милләт тә үзенең милли ихтыяҗларыннан ирекле рәвештә баш тартмый — монда гуманизмга, әхлаклылыкка, башка милләтләрнең ихтыяжын да исәпкә алырга чакырулар нәтиҗә

бирми. Хәзерге кебек милләтара мөнәсәбәтләрнең кискенләшкән чагында көчлерәк милләт экспансиягә омтыла, үзенең өстенлеген көчсезрәкләр хисабына ныгытырга тырыша. Бу бигрәк тә теллурократик менталитетлы милләтләргә хас. Хәзерге халыкара сәясәттә, моңа альтернатива буларак, региональ һәм планетар тынычлыкны саклау ихтыяҗы гына каршы куела. Димәк, милли хәрәкәт тә шушы ике альтернатива арасында эш итәргә тиеш була: бер яктан, милли ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерү өчен компромиссыз көрәшне дәвам иттерү, икенче яктан, аның региональ һәм глобаль конфликтларга китерми торган юлларын табу.

Татар бөтен Далага сибелгән. Күпчелек очракта ул, бергә яшәүче күрше халыклар арасында азчылык тәшкил итеп, ят мохиттә гомер кичерә. Мондый шартларда ничек итеп милләтнең бөтенлеген сакларга һәм үсешен тәэмин итәргә, нинди юл белән үзенең геотарихи вазыйфаларын үтәү шартлары тудырырга? Безнең милли аңда моңа уртак җавап әле формалашмаган. Моның өчен милли ихтыяҗларны барлау һәм аларны дөнья җәмәгатьчелегенә җиткерү зарур. Еламаган балага имчәк бирмиләр дигәндәй, шунсыз дөньяның геосәяси сәхнәсендә үз куышыңны табу мөмкин түгел. Без социаль һәм сәяси трансформацияләр чорында яшибез. Мондый чакта милли ихтыяҗлар бигрәк тә сәяси сферада каршылыкка дучар була, хәтта каршы көчләр белән бәрелешкә дә китерергә мөмкин. Шуңа күрә, төрле милләтләрнең вә дәүләтләрнең милли ихтыяҗларын исәпкә алу һәм аларның үзара бәйләнешләрен-багланышларын күрә һәм таный белү региональ һәм планетар иминлек саклауга хезмәт итүче факторга әверелә. Шулай итеп, әгәр без үз милли ихтыяҗларыбызны вә аларны гамәлләштерү юлларын дөрес итеп билгеләсәк һәм ниятләребезгә ирешүдә сәяси ихтыяр күрсәтсәк, ул, бер яктан, аерым шәхесләрнең һәм бөтен милләтнең үсешкә омтылышында этәргеч көчкә әверелер, икенче яктан, дөнья җәмәгатьчелеге тарафыннан аларны исәпкә алып эш итүгә сәбәп булыр иде.

Милли хәрәкәтнең бүгенге халәтен истә тотып, милли ихтыяҗлар һәм аларны канәгатьләндерү юлларын билгеләүдәге тагын бер мәсьәләгә игътибарны юнәлтү зарур. Сүз телдә даими кабатлана торган, ләкин гамәлдә һаман кире кагылып килүче мәсьәлә: ниятләребез һәм тактик адымнарыбызның геосәяси вәзгыятькә тәңгәл булырга тиешлеге турында бара. Күп кенә милләтчеләр бәяләвенчә, XXI гасыр бусагасында милли хәрәкәт тирән кризис кичерә. Мондый бәянең нигезендә дәүләт суверенитеты үсешендә перспектива күренмәү ята. Хәлбуки, моны милли хәрәкәт кризисы дип атау бик үк дөрес булмас; милли ихтыяҗлар-

га карата милли хәрәкәттәге фикер кризисы дисәк, дөреслеккә якынрак булыр. Ягъни, әлеге бәя объективлыкка нигезләнмәгән, ә субъективлыкны чагылдыра. Аның сәбәбе — яңа вәзгыятьтә искечә фикерләүдә. Бу — милли сәяси аңдагы фикер инерциясе йогынтысы. Вәзгыять яңа — фикерләү дә шуңа тәңгәл булырга тиеш. 1990 нчы еллар башында милли хәрәкәт шактый гына уңышка иреште. Бу аның Татарстан кысаларындагы дәүләтчелекне үстерүгә юнәлтелгән идеологиясе дә ул чактагы вәзгыятькә тәңгәл булуын раслый. Әмма ул инде яңа вәзгыятькә туры килми. Бүген ул фикерләү — тарлык билгесе. Бу — милли сәясәтне менталитетыбыздагы болгарчылык белән чикләү галәмәте, «сәяси болгарчылык» чагылышы. Ә бит XXI гасыр «сәяси татарчылык» заманы булачак.

Хәзерге вәзгыятьтә төбәктәге башка халыкларның һәм үзебезнең милли ихтыяҗларны канәгатьләндерә алырлык идеология нинди булырга мөмкин? Ул төп өч факторны истә тотып билгеләнергә тиеш:

1) дөнья үсеше тенденцияләре;

2) без яшәгән җирләрнең дөньяви сәрешләрдә тоткан роле;

3) монда дәүләт тотуга амбицияле милләтләрнең менталитеты.

Алар нидән гыйбарәт соң? Бу сорауга җавап төрле бүлекләрдә инде бирелгән иде, аларны хәзер беркадәр конкретлаштырыйк. Беренчесен Америка сценариендагы дөньяви яңа тәртип урнаштыру яки глобальләштерү дип атыйлар. Аның төп билгесе — «күптөрлелек бердәмлеге» (ягъни төрле цивилизацион-мәдәни җәмгыятьләрнең сәяси-икътисадый берлеге) булыр дип фаразлана. Бу, халыкара хокук өлкәсендәге бер-берсенә каршы булган ике әйберне: халыкларның үзбилгеләнү хокукын һәм дәүләтләрнең территориаль бөтенлеге принцибын үзара килештереп, милләтара проблемаларны конфликтсыз хәл итү мөмкинлеге бирә.

Икенче факторны ачыклап шуны әйтергә тиешбез: Корының 1/6 өлешен тәшкил иткән Урталык Җирләрендәге (постсовет пространствосындагы) тотрыклылык дөнья иминлеге шарты булып тора. Шуңа күрә, бу территориянең бөтенлеге һәм мондагы тәртипнең АКШ геосәяси ихтыяҗларына туры килүе дөнья җәмәгатьчелеге мәнфәгате дәрәҗәсенә күтәрелә.

Өченче факторга килгәндә, аның эчке һәм тышкы аспектлары бар. Эчкесе, империядәге кризисның төп сәбәбе булып тора. Эш шуда ки, монда дәүләт тотучы милләт әлеге тәртипне урнаштырырга да, сакларга да әзер түгел һәм теләми дә. Урыс менталитеты, бер яктан, атлантизмны кабул итә алмаса, икенче яктан, Урталык Җирләренең территориаль бөтенлеген саклау мөмкин-

леген дә бирми (чөнки ул башка халыклар мәнфәгатен инкарь итү, аларны ассимиляцияләү сәясәтеннән, бөекдержавачыл шовинизмнан арына алмый). Мондый хәл Русиянең СССР язмышын кабатлавы ихтималын арттыра. Бу, Аллаһы кушуы белән, әлбәттә, шулай булачак, тик вакыты әлегә хәзер түгел. Юкса, глобальләштерү сөрешенең идарә ителеше бозылырга мөмкин. Монысы инде хәзерге шартларда дөньякүләм катастрофага да китерә ала. Димәк, дөнья җәмәгатьчелегендә яңа геосәяси ихтыяҗ туа: Русиянең эчендә атлантизмга яраклы тәртип тота алырлык көчләр табарга (яки оештырырга)...

Урталык җирләренә куелган геосәяси таләпләргә нәкъ менә татар менталитеты тулысынча җавап бирә. Атлантизмның нигезен тәшкил иткән либерализм һәм толерантлык - татарның борынгыдан килгән сыйфаты. Аның милли аңында урталык җирләре иминлеге өчен җаваплылык тойгысы сакланган. Монда яшәүче башка халыкларда югарыда китерелгән дала турындагы мәкал булмавын һәм Дала татарларның кендек каны тамган урын [35] икәнен искә алсак, аның икенче өлеше болай укылырга тиеш була: «Татар күңеле — Далада». Һәм ул шулай да: аның моңа тарихи хәтере һәм тәҗрибәсе дә (ул монда дәүләт тоткан), сәяси хокукы да (ул — Алтын Урда варисы), милли амбициясе дә (дәүләтчелеген торгызу омтылышы) бар. Шул ук вакытта ул, биш гасыр дәвамында кыйналып, халыкара мөнәсәбәттә милләтләр тигезлегенең иң кыйммәтле фактор икәнен аңлаган һәм менталитетындагы башкаларга буйсынып яки аларны буйсындырып яшәүне кабул итә алмаучан сыйфатын милли-сәяси аң дәрәҗәсенә үстергән [36]. Сан ягыннан ул Русиядә өченче урында, аның төрле почмакларында, борынгы төрки бабалары мирас итеп калдырган тарихи җирләрендә яши. Кыскасы, Дала иминлеген саклау — татарның Аллаһы йөкләгән геотарихи вазыйфасы. Бу монда яшәүче барлык халыкларның да (шул исәптән татарның һәм урысның да), дөнья җәмәгатьчелегенең дә геосәяси ихтыяҗларына тәңгәл килә.

Өченче факторның тышкы аспекты «Көнчыгыш аждаһасы»ның үзен ничек тотуына бәйле. Урыс Урталык Җирләренә хуҗа булган гасырларда ул йоклый иде, әмма соңгы вакытта уянды. Алай гынамы, СССР таркалганнан соң, үзенең икътисадый үсеше темпы, экспансив амбициясе һәм халык саны белән Кытай АКШның төп геостратегик көндәшенә әверелеп килә дияргә була. Әгәр аны атлантизм юлына бастырып булмаса, Урталык Җирләрен аңа каршы әзерләү ихтыяҗы туачак. Тик монда дәүләт тотучы милләт мондый рольгә яраклымы? XX гасыр тәҗрибәсе күрсәт-

кәнчә, моңа уңай җавап биреп булмый. Урыс неоаураэиячеләре дә, Кытай континенталь империя булып калган очракта, Мәскәү-Пекин күчәре төзеп, атлантизмга каршы чыгу идеясен алга сөрә. Шулай итеп, бу мәсьәләдә дә борынгы бабалары аждаһаны Бөек Кытай дивары артында тоткан тәрки-татар кавеменең тарихи тәҗрибәсен искә төшерү зарурияты туарга мөмкин...

Үзенең геотарихи вазифасын үтәргә әзерлеген соңгы унъеллык үсеш дәверендә татар гамәлдә дә раслады. Татар милли хәрәкәте бу елларда ике этап үтте: беренчесендә (Декларация, Референдум, Конситуция) ирекккә, хөрлеккә, дәүләти мөстәкыйльлеккә омтылу ихтыяры күрсәтте; икенчесендә («Татарстан модело») үзенең киң карашлы, либераль холыклы, толерантлы булуын, башка халыклар үсешен үз үсеше шарты да итеп каравын, милли максатына ирешүдә тыныч юл сайлавын, канлы конфликтлар юлына басмаячагын күрсәтте. Боларны дөнья җәмәгатьчелеге дә таныды һәм югары бәяләде. Әлеге ике этапның нәтиҗәсе буларак, өченче этапка керергә юл ачылды. Хәзер, үзенең сәяси ихтыярын һәм көрәш ысулының акылга нигезләнгәнлеген күрсәткәннән соң, татарга һәм Татарстанга тарих тарафыннан элекке СССР биләмәләрен реформалау һәм Аурусоюзга әзерләү буенча аураэиячелек үзәге һәм үрнәге булу вазыйфасы йөкләнә.

Сүз урыс аураэиячелегенә ияру турында бармый - ул уңышка ирешә алмаячак. Чөнки тышкы сәясәттә аның максаты глобальләштерүгә каршы юнәлтелгән, эчкесендә, мондагы милләтләрне урыслаштыруны һәм православиегә кертүне күздә тота (бу Мәскәү геосәясәтчеләренең георияеендә һәм империя хакимиятенең гамәли сәясәтендә ачык күренә). Татар аураэиячелеге исә, тышкы сәясәттә дөньяда бара торган глобаль сөрешнең мөһим бер өлеше булырга, эчкесендә, монда яшәүче милләтләрнең (әлбәттә, урыс белән татарны да кертеп) ирекле берләшүен һәм аларның тигез шартларда үсешен гамәлгә куярга тиеш.

Болар барысы да милли хәрәкәтнең стратегик юлы нинди булырга тиешлеген күрсәтә: татар юлы Татарстан киңлеге белән генә чикләнми, аның юлы — Дала киңлегендә. Тактик яктан да Дала кинлдегенә чыгу вакыты җитте — моңа империядәге федерализм үсентеләрен юк итүгә юнәлтелгән соңгы сәяси вакыйгалар этәрә. Аларны милли хәрәкәткә сабак бирү өчен җибәрелгән гыйбрәтле хәбәр дип кабул итәргә кирәк. Аларның гыйбрәтлелеге менә нәрсәдә: беренчедән, моңарчы без күзаллаган суверенитет Татарстанның мөстәкыйльлеген дә, татар милләте ирекен дә гарантияләми — империя исән чакта милли максатыбызга ирешү хыял гына булып калачак (большевиклар тәҗрибәсе дә, «де-

мократлар»ныкы да шуны күрсәтте); икенчедән, Татарстан кысаларындагы дәүләти мөстәкыйльлек милләтебез берләшүен һәм үсешен тәэмин итә алмый; өченчедән, дин, мәдәният һәм мәгариф системаларының мөсткыйльлегенә ирешми торып, югары милли культураны саклап һәм үстереп булмаячак, ә шунсыз киләчәгебез күге дә болытлы булыр; дүртенчедән, татар үзе өчен генә кайгыртып бәхеткә ирешә алмаячак — аның вөҗданы (менталитеты) Дала иминлеге, мондагы халыклар язмышы турында кайгыртуны таләп итә. Бу — татардагы пәйгамбәрлек сыйфаты чагылышы. Ул аңа Дала хуҗасы булу өчен бирелгән...

Алга таба милли хәрәкәт ориентирын Татарстан статусы белән генә чикләү татарның яңа социаль халәте ягыннан да акланмый. Бу җәһәттән, хәзерге вәзгыять моннан дистә ел элгәргесеннән бик нык аерыла. Элек җәмгыятьтәге төп каршылык канәгатьләндерелмәгән милли ихтыяҗларга нигезләнгән иде, хәзер исә социаль гаделсезлек тудырган сыйнфый каршылык беренче планга чыга. Элек социаль яктан җәмгыять чагыштырмача бертөрле иде. Шуңа күрә, татарларның аңлы өлеше үз омтылышында бердәм хәрәкәт итте, милли ихтыяҗларны канәгатьләндерү юлын Татарстан мөстәкыйльлеген үстерү аркылы күрде. Хәзер исә милләт өч социаль катламга бүленә: буржуазия, зыялылар һәм гавәм. Аларның ихтыяҗлары да — һәркайсының үзенеке: буржуазиягә икътисадый-хокукый кырның киңлеге һәм бөтенлеге кирәк, зыялыларда һәм гавәмдә хәзергә, башлыча, җан асрау кайгысы. Шуңа өстәү, Татарстан суверенитетының «милли йөзе» булмау һәм дәүләтчелегебез үсешендә миллилеккә игътибар җитенкерәмәү сәбәпле аның хәтта Татарстан кысаларында да милли ихтыяҗларны кирәгенчә канәгатьләндерә алмавын искә алсак, иске ориентирның халыкка маяк була алуына өмет калмый.

Инде килеп, милли хәрәкәт геостратегиясен гамәлләштерү агымдагы сәясәттә нинди чагылыш табарга тиешлегенә тукталып үтик. Бу уңайдан, иң әүвәл, ирешелгәнен сакларга кирәклеген күрсәтергә кирәктер. Икенче төрле әйтсәк, Татартан суверенитетын сакларга һәм аның миллилеген үстерергә. Бу безгә мәдәниятебезне үстерү һәм Дала халыкларына җәмгыяви куркынычсызлык үрнәге күрсәтеп (ягъни икътисадый муллык, социаль гаделлек, тирә-юнь мохитне саклау, идарә итүдә демократик тәртипләр һәм законнар хакимлеге кебек җәмгыять тотрыклыгы шартлары тудырып), сәяси татарчылык вазифасын үтәүне җиңеләйтү өчен кирәк. Милли хәрәкәт моның өчен тырышлыгын киметмәскә тиеш. Шул ук вакытта сәяси татарчылык алгы сафка чыгарга тиеш. Моның беренче адымы буларак, якын киләчәктә

татарлар укмашып яшәгән Идел буе округында милли консолидация шартларын тудыруны милли хәрәкатнең төп бурычы итеп алырга һәм милли ихтыяҗларны канәгатьләндерү буенча Татарстанның Зур Татарстанга ярдәмен арттыру турында даими кайгыртырга.

Бер яктан, Дала бөтенлеген саклау ихтыяҗы, икенче яктан, геосәяси көрәштә каршы якның безгә караганда күпкә көчлелеге империяне реформалауда бер генә юл калдыра — кеше хокукларын яклау көрәше аркылы. Империя тотучы милләтнең державачылык милли аңы хөкем сөргәндә милли азатлык көрәше кеше хокукларына таянып алып барыла ала. Бу — халыкара сәясәттә танылган һәм яклана торган ысул. Милли хокукларны кеше хокукларын яклау аркылы дәгъваларга кирәк. Бу юл халыкта да (милләтенә карамастан) яклау таба, дөнья җәмәгатьчелеге ярдәменә таянырга да мөмкинлек бирә. Әлеге мәсьәләдә бөтен Русия һәм БДБ киңлегендә татар алгы сафларда булырга тиеш. Татар милли хәрәкәте өченче этапта үз миссиясен кеше хокуклары өчен көрәш башында торып үти ала. Бу урыска шовинистик-империячел, татарга мескенлек психологиясеннән арынырга ярдәм итәр. Башка халыкларга да үрнәк булыр.

Шулай итеп, социаль, милли, дини хокукларыбызны яклау кеше хокукларын яклау байрагы астында барса, дәүләтчелегебезне саклау һәм ныгыту татар ауруазиячелегенә таянып башкарылсын. Һәм «Кеше хокуклары өчен!» вә «Күптөрлелек бердәмлеге өчен!» лозунглары шәхесләрнең вә милләтләрнең азатлык көрәше девизына әверелү кирәк.

Хәлбуки, моның өчен татар бүгенге таркаулыгыннан арынырга тиеш. Милләт үз миссиясен бердәм үтәсен өчен милли аңыбыздагы татарчылык һәм болгарчылык энергиясен дөрес куллану гына җитми, социаль каршылыкларны киметеп, сыйнфый хезмәттәшлек чараларын да күрергә кирәк. Әгәр социаль катламнар үзләренең милли вазыйфаларын үтәсәләр, бу мөмкин һәм күп кенә милләтләр, мәсәлән, яһүдләр, шулай яши дә. Әлеге катламнарның милли вазифалары нидән гыйбарәт соң? Алар милли хәрәкәт максатыннан чыгып һәм катламнарның социаль вә милли ихтыяҗларына нигезләнеп билгеләнә.

Сүзне милли хәрәкәтнең гегемоны ролен үтәргә тиеш булган милли буржуазиядән башлыйк. Аның милли вазыйфалары түбәндәгеләр: милли капитал туплау, милли мәгариф вә мәдәният системаларын урнаштыру һәм тоту, милли зыялыларга вә гавәмгә үз вазифаларын үтәү шартларын тудыру, һәр өч катламның ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә үзара бәйлелеккә һәм ярдәмгә

нигезләнгән милли яшәеш системасы (яһүдләр үрнәгендә) оештыру, шуның аркылы милли бердәмлеккә ирешү, милләт мәнфәгатен кайгыртуга сәләтле зыялыларны хакимияткә үткәрү.

Милләтнең «мие» булырга тиешле зыялыларныкы: милли идеология булдыру һәм милли аң тәрбияләү, милли буржуазиягә үз вазифасын үтәү өчен «акыл биреп» тору, халыкның милли ихтыяҗларын канәгатьләндерү, милләтнең иманлы, югары культуралы һәм әхлаклы булуы турында даими кайгырту, милләт формалашуын дәвам иттерү чараларын күрү, милли яшәеш системасында төп башкаручы ролен уйнау.

Милләтнең күпчелеген һәм сәяси көчен тәшкил иткән гавәм җилкәсенә вазыйфаларның гадирәк, әмма авыррак булганнары йөкләнә: милләтне үрчетү һәм аны физик үлемнән саклау, милли мохит тоту (ягъни милли гореф-гадәтләрне тотып вә дини йолаларны үтәп, татарча сөйләшеп вә моңланып яшәү) һәм шуның белән милләтне рухи үлемнән саклау, милли хәрәкәттә төп сәяси таяныч булу (кирәк чакта урам-мәйданга чыгып та, башка ысуллар кулланып та милли мәнфәгатьләрне якларга әзер тору), тормышта милли-социаль база ролен үтәү (ягъни сайлауларда үз милләте вәкилләрен, милләт җанлы кандидатларны яклау, мөмкинлек булганда, тауарны татардан гына алу һ.б.).

Милләт мәнфәгате күзлегеннән, милли буржуазиянең төп дошманы — «алтын бозау»га табыну куркынычы, милли зыялылар өчен — тамак кайгысына бирелү, гади халык өчен — татар булуы белән горурлана алмау. Бөтенесе өчен — иман сату. Татар милли яшәеш системасы менә шушы куркынычларга каршы торырлык булырга тиеш. Иман сатуны (димәк, иман яңартуны да) төрле кеше төрлечә аңлый. Геосәясәт күзлегеннән исә, ул — үзеңнең тиабигый асылыңа хыянәт. Татарның геосәяси асылын илаһи тәгълиматка (төрки-ислами цивилизация кыйммәтләренә) корылган һәм табигый географик-климатик шартларда формалашкан татарлык (болгарчылык + татарчылык) тәшкил итә. Димәк, иман яңарту, менә шушы асылыбызга кайтып, Аллаһы йөкләгән геотарихи вазыйфабызны үтәүне яшәү максаты һәм мәгънәсе дип тану була.

Милли бердәмлек һәм дәүләтчелек мәсьәләләренә дә кыскача тукталып үтик — алар да геосәяси ихтыяҗлар рәтенә керә бит. Монда проблемага аек акыл белән реаль карау сорала. Һичшиксез, милләтне бердәмлеккә өндәргә, аның өчен тырышырга кирәк. Ләкин шул ук вакытта бердәмлекнең идеализм икәнен һәм беркайчан да тулы бердәмлек була алмаячагын да истә тоту дөрес булыр. Татарның, төрле фиркаләрдә торып, төрле хәрәкәтләрдә

катнашуын табигый хәл икәнен тану зарур. Алай гына да түгел, Урталык Җирләрен җыючы буларак, бу безгә кирәк тә. Бу мәсьәләдә милләт эчендәге каршылык сыйнфый көрәш хәленә җитмәсә, шуңа канәгать булырга кирәк. Ә инде милләтнең нормаль яшәешен, үсешен һәм геотарихи вазыйфасын үтәүне тәэмин итү өчен әләге фирка-төркемнәр башында торучы лидерлар аша, аларның гамәлен милләт максатында хезмәт итүгә юнәлтергә кирәк. Моның өчен, әлбәттә, башта милли яшәеш системасын оештыру зарур.

Дәүләтчелек мәсьәләсенә килгәндә, тулы дәүләти бәйсезлек беркемгә дә бирелмәячәк. Русия аерым дәүләтләргә таркалмаячак, ә, административ бердәмлекләргә бүленеп, планетар берлек составына керәчәк — гасырларга сузылган Зур Пространстволар үсеше тенденциясе шуны күрсәтә.

Моңарчы татар иҗтимагый аңында яшәп килгән геостратегия башкалардан калышмауга, алга киткән милләтләрдән үрнәк алып, аларны куып җитүгә юнәлтелгән иде. Мондый караш ерак киләчәктә туачак таләпләргә тулысынча җавап бирмәсә дә (чөнки алар барган юл глобаль кризиска китерә, дидек бит), якын киләчәк өчен тактик бурычларга һәм вәзгыятькә туры килә сыман. Ни өчен дисәң, хәзергә чорда милләт өчен төп проблема — ул әле исән калуны гарантияләүче юл табу. Тарихыбыз күрсәткәнчә, милләт бүгенгедәй авыр хәләтеннән күп тапкырлар үзенең менталитетындагы сәүдәгә хирыслыгы ярдәмендә чыга алган. Бу — бүген дә актуальлеген җуймаган милли потенциалыбыз.

Мәсәлән, Мэхэн фикеренчә, милләт һәм дәүләт үсешенә динамизм бирүче төп фактор — ул сәүдә. Бу фикернең дөреслеген Америка үсешендәге динамизм раслады — ул, шушы идеяне кулланып, ярты гасыр эчендә икенче сортлы державадан супердержавага әверелде һәм дөньяга хуҗа булды. Әлеге фикернең милләтләргә карата да дөреслеген яһүдләр мисалында күрәбез. Сәүдә өчен пространство киңлеге кирәк. XX гасыр башында татар милли лидерлары буржуазия йогынтысы белән шушы юлны сайлаган (төрки-мөселман халыклары арасында татарлар милли мөстәкыйльлекне Русия составында күрүче бердәнбер милләт булганнар, дигән идек). Алар монда, хәзергечә әйтсәк, чын атлантистлар буларак эш иткәннәр. Ә башка төрки халыклар континенталистларча фикер йөрткәннәр.

Хәзер дә Татартан һәм Зур Татарстан, иң әүвәл, урталык җирләре һәм бөтен дөнья киңлегендә сәүдә оештыру турында кайгыртырга тиеш. Ә милләтнең сәяси һәм хокукый бәйсезлегенә килгәндә, татар дәүләтенең суверенлыгы әлеге сәүдәне мөстә-

кыйль рәвештә оештырырлык дәрәҗәдә булсын. Шулай итеп, татар милли хәрәкәте өчен изоляциягә китерергә мөмкин булган «тулы бәйсезлек» идеясе кабул ителә алмый. Зур Татарстан һәм милләтнең яшәү системасы татар сәүдәсен оештыруга хезмәт итәргә тиеш. Бу үсеп килүче һәм милли хәрәкәт башына басарга тиешле булган татар буржуазиясе мәнфәгатенә дә туры килә.

Дәүләти мөстәкыйльлекне кире кагучылар белән дә килешеп булмый. Ул чагында мөстәкыйль милли финанс системасын да, мәгариф һәм мәдәният системаларын да оештырып булмаячак. Ә аларсыз әлеге сәүдәне җайга салу һәм милләтнең милли йөзен саклап калу күп тапкырлар авырлашачак.

Сәүдә һәм үзара аралашу - менә иң кирәге нәрсә бүген татарга. Моның өчен иң әүвәл Зур Татарстан кысаларында аралашу мөмкинлекләрен (һава, су, тимер юл, автомобиль һ.б. транспорт чаралары, масс-медиа) үстерү турында кайгыртырга, төбәкләр белән горизонталь договорлар төзүне дәвам итәргә кирәк. Безнең диңгез юлларыбыз юк. Шулай булгач, дөнья халыклары белән сәүдә итү өчен һава юлы гына кала. Шул сәбәпле, безнең производство да сатып алучыга тауарны һава юлы белән җиткерүне күздә тотарга тиеш (авиатөзелеш, приборлар ясау, электроника һ.б.ш. авыр булмаган, фәнсыешлы, югары бәяле продукция).

Зур Татарстан идеясе эшләсен өчен Русиядә аның хокукый базасын булдыру зарур. Моңа бәйле рәвештә Дәүләт Думасы, дәүләти хакимият структуралары эшендә һәм Русиянең сәяси тормышында актив катнашу бурычы туа. Бу җәһәттән әйтеп үтик, абсентизм (катнашмау) — безнең өчен яраксыз идея. Тик шунысы хак, империя хакимиятендә өстенлек иткән унитарлык тарафдарлары чын демократик көчләргә каршы киртәне алдан ук корып куя. Бу уңайдан Русиянең сәяси-дәүләти эшләрендә катнашканда бер хакыйкатьне истән чыгармаска кирәк: идеологик мөстәкыйльлеккә ирешмәгән милләтләр һәм стратегик суверенитеттан мәхрүм булган республикалар, ничек кенә тырышсалар да, мәрхүм Әбрар ага Кәримуллин әйтмешли (урыны оҗмахта булсын), империя арбасына тагылган дегет чиләге роленнән арына алмаслар. Идеологик мөстәкыйльлек турында югарыда сүз булды, стратегик суверенитет исә — ул хәрби мөстәкыйльлек. Ул булмаганда Татарстан (һәм Зур Татарстан) империягә буйсынган булып кала. Андый буйсынганлык атлантик культуралы татарны объектив рәвештә (геосәясәт закончалыклары нигезендә) континенталь характердагы урыс культурасында эретеп бетерәчәк. Моңа телебезне, мәдәниятебезне, динебезне сакларга тырышуыбыз да ярдәм итә алмаячак. Моннан котылу өчен бер

генә чара кала сыман — тулы дәүләти бәйсезлеккә ирешү. Ләкин, инде әйтелгәнчә, хәзерге заманда бу мөмкин түгел (монысы да геосәясәт законы нигезендә). Нишләргә? Альтернатива аңлашыла булса кирәк — реформаланган Даланың ТАКО–НАТО составына керү идеясен якларга. Хәрби төзелешкә килгәндә, профессиональ армиягә күчүне тизләтергә. Аңа ирешкәнче, альтернатив хезмәтне якларга.

Милләтебез үзенә йөкләнгән геотарихи вазыйфаны үтәрлек булсын өчен һәр татар сабый чактан лидерлыкка әзерләнергә тиеш. Моңа кайчан ирешеп була? Әгәр кешелек казанышларының бөтен тармакларында милләт вәкилләре булса һәм аларның (зыялыларның) белемнәрен үстерүдә түбәндәге әһәмияти нисбәт сакланса: иң әүвәл һәм иң югары дәрәҗәдә илаһи тәгълиматны үзләштерергә (ягъни Коръәнне һәм Ислам фәлсәфәсен заман дөрес аңларга һәм аңлата белергә), икенчесе — гомумфәлсәфә, өченчесе — сәясәт гыйлеме (әлбәттә, геосәясәт югарылыгында), аннан соң — профессиональ белем, ул чагында без, чын мәгънәсендә, «татар көче — акылда» мәсләгендә эш итеп, Аллаһы тәкъдирен үтәргә әзер һәм урталык җирләрен җыючы роленә лаек булырбыз.

ТАТАР ИСЛАМЫ

Татар дөньясы үзенең цивилизацион универсальлеге, географик уникальлеге, этник үзгәлеге белән күчеш чорында зур геосәяси мәгънәгә ия. Безнең универсальлек — бөек ислам цивилизациясе вәкиле булуыбызда, географик уникальлек — империянең уртасында укмашып һәм эчендә сибелеп яшәвебездә, этник үзгәлегебез — геосәяси яктан, урыска капма-каршы миссионерлыгыбызда (урыс — яулаучы, татар — җыючы), мәдәни яктан, заман таләпләрен иң дөрес аңлый торган җәдитчелек традицияләрен дәвам итүебездә. Болар безне планетар кысалардагы геосәяси субъектка әверелдерә. Ләкин ул факторларның берсе генә булмаса да, татар үзенең геосәяси әһәмиятен җуячак. Милли хәрәкәт моны һәрчак истә тотарга тиеш.

Географик урыныбыз, объектив чынбарлык буларак, бәхәс тудырмый. Калганнары исә, субъектив факторлар булганлыктан, бәхәссез генә кабул ителми. Урыс һәм татар менталитетларының капма-каршылыгы турында алдагы бүлекләрдә җитәрлек әйтелде кебек. Моны һәркем тормыш тәҗрибәсеннән чыгып та раслый алыр иде. Ә менә исламга кагылышлы фикерләр бер генә төрле

түгел. Татар иҗтимагый аңына бигрәк тә «татар исламы» гыйбарәсен кабул итү авыр тоела. Шуңа күрә, бу мәсьәләгә геосәясәт күзлегеннән дә тукталып китү урынсыз булмас.

Иң әүвәл шуны искәртик: «Татар исламы» дигәнебез дини яки цивилизацияон төшенчә түгел. Бу яктан ислам — ислам инде ул, татарныкы да түел, гарәп яки төрекнеке дә түгел. Ул — интернациональ дин һәм универсаль цивилизация. «Татар исламы» термины татар милли хәрәкәтенең глобальләштерү чорындагы геостретигик юлын билгеләү һәм бүгенге вәзгыятьтә, геосәяси субъект буларак, мөстәкыйль роль уйнарга тиешлеген күрсәтү өчен кулланыла. Ягъни бу — сәяси термин. Әлбәттә инде, бу ислам дөньясында татарның үзенә генә хас үзенчәлекләре булуына нигезләнә. Әлеге терминны куллануның методологик, цивилизацион, геосәяси һәм милли-мәдәни аспектлары бар. Милләт язмышы өчен аларның барысы да бик мөһим. Аларны ачыклап үтик.

«Татар исламы» сүз тезмәсе бигрәк тә атеистлар һәм исламчылар тарафыннан тәнкыйтькә тотыла. Беренчеләре төп дәлил итеп ислам дөньясында бер генә «алга киткән» һәм «заманча культуралы» милләт яки дәүләтнең булмавын китерсә, икенчеләре исламның бөтен халыклар өчен дә уртак дин икәнен искәртә һәм исламда милләт төшенчәсенә урын юклыгын алга сөрә. Әмма, болар икесе дә — исламның методологик асылын аңламыйча, гамәли ислам тәҗрибәсенә таянып кына фикерләү нәтиҗәсе. Әйе, кешелекнең бүгенге казанышлары күзлегеннән әлеге дәлилләрнең икесе дә нигезле сыман күренә. Ләкин андый фикерләүнең асылы комга корылган, чөнки ислам дөньясындагы бүгенге чынбарлык — ул бары тик ислам тәгълиматын дөрес кулланмау нәтиҗәсе генә. «Татар исламы» диюбез, ә исламны милли куышларга бүлүне алга сөрү түгел, ул исламны дөрес аңлау кирәклеген күрсәтү.

Коръәндә адәми затларның, бер яктан, Аллаһ колы, икенче яктан, Җиргә хуҗа булып иңдерелүе турында әйтелә. Кешелек, шул исәптән мөселманнар да, моны дөрес аңлыймы? Коллык белән Хуҗа булу нисбәтен алар дөрес билгелиме? Кешелек язмышы менә шуңа бәйле. Димәк, бу аерым милләтләргә дә кагыла.

Аллаһы Кешене җир йөзенә хуҗа итеп яралткан. Хуҗа булу — ул идарә итү, ягъни гамәл кылу дигән сүз. Аның өчен ирек кирәк. Ходай Тәгалә Кешегә ирек тә биргән. Иректән дөрес файдаланып, дөрес гамәл кылу өчен Кешегә Ул Акыл биргән. Әлеге ирек табигать кануннары белән чикләнә. Аның чикләрен дөрес аңлау өчен Аллаһы Тәгалә Коръән иңдергән. Гамәл кылучы ял-

гышырга да мөмкин. Ялгышудан куркып, акылын томалап һәм гамәлдән тыелып тормасын өчен Аллаһ үзенең ярлыкаучы икәнен әйткән. Алай гына да түгел, ялгышучыны (акылы белән ялгышуын таный һәм иманга кайта белсә) артыграк сөйгәнен дә җиткергән. Чагыштырмача ирекле, Җиргә Хуҗа һәм ялгышучан Адәм Галиәссәләмне ул кушканны гына башкаручы (димәк, ялгыш гамәлләрдән азат булган) фәрештәләрдән өстенрәк күргән — фәрештәләрдән аңа сәҗдә кылдырган (буйсынырга кушкан).

Кеше табигате шундый: әлеге ирекне танып һәм чикләрен аңлап озак яши алмый. Вакыты-вакыты белән ул йә үзенә Аллаһы биргән ирекне күрми-танымый, бөтен язмышын Аллага тапшырдым дип (бу татарга да хас), акылын параличландырып, үзен саклау һәм Аллаһы йөкләгән вазыйфалар үтәү гамәленнән туктый; йә булмаса, әлеге ирекне чиксез дип, үзен Кеше-Алла и күрә башлый. Аерым шәхесләрнең андый ялгышлары кавемнең (милләтнең)тулаем адашуына китергән вакытта Аллаһы Тәгалә халыкларны туры юлга чыгару өчен пәйгамбәрләр җибәргән. Планетар Акыл әле берләшеп җитмәгән һәм һәр кавем үз акылы белән яшәгән чакларда пәйгамбәрләр аларның һәркайсына аерым һәм ешрак килгәннәр. Кешелек дөньясында коммуникацион мөмкинлкләр үсеп, Планетар Акыл оешканнан соң пәйгамбәрләр җиббәрелүе туктатылган. Мөхәммәд (с.г.с.) Аллыһының соңгы һәм бөтен адәми затлар өчен җибәрелгән рәсүле булган. Шуның белән Аллаһы Кешегә Үзе биргән Акылга таянып, Коръәнне дөрес аңлап һәм үзенең Җир хуҗасы (ягъни биосфера сакчысы) вазыйфасын үтәп яшәүне иминлек шарты итеп билгеләгән.

Коръәндәге Кешенең Алла колы икәнен күрсәтү — илаһи тәгълиматка нигезләнеп яшә дигән сүз. Ягъни моны, Аллаһының кешегә ШГИТ буенча беренче өстенлек югарылыгында фикер йөртергә кушуы, шунсыз Җирдә хуҗа булу, аның иминлеген саклау мөмкин түгеллеген искәртү, дип аңларга кирәк. Үзләрен мөселман дип йөрүчеләрнең күпләре моны аңламаган. Алар коллык сүзен мотлаклаштырып, Хуҗа икәннәрен оңытканнар, кирәгеннән артык тыйнакланып вә ихтыярны богаулап, фанатизмга бирелгәннәр, акылсыз-ихтыярсыз биороботларга әверелгәннәр. Аллаһы аларның яргышлыкларын искәртеп Җазасын да иңдергән — менә ни өчен мөселман илләре мөшкел хәлгә төшкән. Көнбатыш культуралы халыклар Хуҗа булуны мотлаклаштырганнар, илаһи тәгълиматны танымау юлына басканнар. Аллаһы аларны да кисәтә — асылда атеизмга нигезләнгән Көнбатыш культурасы өстенлек иткән кешелек цивилизациясе бүген глобаль кризис кичерә. Җирдә Хуҗа булу һәм шул ук вакытта

Алла колы икәнен дә онытмау, аларның дөрес нисбәтен билгели белү татарга хас. Татар Аллаһы колы булуны Аның барлыгына, берлегенә һәм Мөхәммәд (с.г.с.)нең Аның рәсүле булуына инану дип аңлый. Димәк, Кеше өчен башка бер генә көчкә, затка, җәмгыяви төркемгә яки органга ул кол була алмый. Ул — Аллаһының гына колы, Аның алдында гына җаваплы. Бу адәми затларга үз ихтыярларын коллык психологиясеннән тулысынча арындыру, Кешегә Аллаһы алдында гына җаваплы Хуҗа булу, Аллаһы нигъмәтенең иң олысы булган хөрлек юлында Коръәнгә вә акылга таянып кыю вә тәвәккәл гамәл кылу өчен бирелгән. «Татар исламы» терминын куллануның методологик аспекты менә шуннан гыйбарәт.

Адәм балалары ике ялгыш юлдан киткән. Көнчыгышта рухи ихтыяҗны абсолют кыйммәт итеп танып, матди вә хисси ихтыяҗларны инкарь итү юлына басканнар. Шул сәбәпле Көнчыгыш цивилизациясе аскетизмга өстенлек бирә. Көнбатыш цивилизациясендә киресенчә, анда — «алтын бозау»га табыну хөкем итә. Көнчыгыш һәм Көнбатыш цивилизацияләре йогынтысында формалашкан татар культурасы рухи һәм матди ихтыяҗларның берсен дә кире какмый, аларның һәр икесенең Аллаһы тарафыннан бирелгәнлеген таный, тик аларның нисбәтен генә дөрес билгеләргә кирәк дип саный. Татарга әлеге нисбәтне билгеләү культурасын җәдитлчелек бирде. Аның асылы — «Исраф-әл-хәрам», ягъни матди ихтыяҗны канәгатьләндерү кешенең табигый яшәү рәвеше, ә менә аның исраф өлеше-хәрам. Бу — Көнчыгышны бүгенге мөшкеллектән, Көнбатышны (аның белән кешелекне), глобаль кризистан чыгара алырлык уникаль принцип. Бүген ул башлыча татар культурасы нигезе булганлыктан, «татар исламы» төшенчәсен куллануга цивилизацион дәрәҗәдәге җирлек бирә.

Инде килеп, әлеге җирлекнең геосәяси аспектына да игътибар итик. Даланың, Урталык Җирләре дип аталуы, аның Аура-зия кыйтгасының уртасында урнашкан булуы өчен генә түгел. Геосәяси баланс тотуда да ул урталык ролен уйный һәм бу мәсьәләдә региональ һәм планетар әһәмияткә ия. Моңарчы да шулай булды, киләчәктә дә шулай булачак. Геосәяси күзлектән карaганда, Далага тарих сәхнәсендә үзара даими көрәштә торган өч бөек цивилизация арасында (көнчыгышта — Кытай, көнбатышта — носари Аурупа, көньякта ислам дөньясы) буфер ролен үтәү вазыйфасы тапшырылган. Бу вазыйфаны үтәү Урталык Җирләре мәдәнияте әлеге һәр өч цивилизациядән дә аермалы булганда гына мөмкин. Юкса, әлеге цивилизацияләргә нигезләнгән сәяси, икътисадый, хәрби көчләрнең балансы бозыла һәм плане-

тар иминлек сагында торучы геосәяси ихтыяҗ Далада кризис тудыра. Шулай булды Алтын Урдада ислам кабул ителгәч, шулай булды СССР белән Кытайда уртак идеология — марксизм-ленинизм урашкач, шулай булды СССР үзснең хәрби көче белән Көнбатышка яный башлагач. Димәк, Урталык Җирләрендә христианлык үзгә булган кебек (православие), ислам да үзенчәлекле булырга тиеш (татар исламы).

Беренче карашка, «Татар исламы» геотарихи вазыйфабыздан чыгып билгеләнгән милли максатны (Дала иминлеген саклау)чагылдыручы милли идея була алмый, ә аңа ирешү юлы гына сыман күренергә мөмкин. Әмма ШГИТ буенча аның идарә итү сөрешендә беренче приоритетлы илһи идея икәнен истә тотсак, милли максатка ирешүнең гамәли ягын Аллаһы ярдәме белән Татар менталитеты үзеннән-үзе башкарачагына икеләнү калмас. «Татар исламы» идеясе ике өлештән тора: «татар» (татарлык) һәм «ислам». «Татарлык», «татарчылык» + «болгарчылык» буларак, ничек эшләргә тиешлеге турында сүз булды инде. Ә «Ислам»га килгәндә, ул үзенең «исраф-әл-хәрам»ы белән бүген бөтен кешелек алдында торган глобаль проблеманы хәл итүдә бердәнбер юл булуы сәбәпле, «татар исламы» идеясенең дөнья җәмәгатьчелеге тарафыннан да кабул ителәчәге шик тудырмый.

Һәм, ниһаять, әлеге идеянең милли-мәдәни аспектлары турында берничә сүз. Кабатланып булса да, янә бер искәртик: татар исламы — ул исламның татар менталитенына «яраклашкан» варианты. Татар үзенең менталитеты белән җиһад-газаватны кабул итә алмый. Ул кемне дә булса буйсындыру, юк итү өчен яралтылмаган. Аның миссионерлык вазыйфасы толерантлык һәм үрнәк күрсәтү аркылы гына үтәлә ала — көч куллануга аның «җаны тартмый», андый көче дә юк. Татар үз геотарихи вазыйфасын уңышлы үтәсен өчен аңа яһүдләр үрнәгендә милли культуралы (милли үзидарә системалы) булу кирәк. Шундый югары культураның нигезен милли дин тәшкил итә ала. Хәлбуки, ислам милли дин түгел, ул — интернациональ дин. Димәк, татар исламы кирәк. Ягъни татар исламы кирәклеге татарның үз геотарихи вазыйфасын тануына бәйле, ә монысы — аның яшәү теләге булуына: үләсе килмәсә, Уртаклык Җирләрен җыючы һәм Көнчыгыш белән Көнбатыш цивилизацияләре арасында күпер вазыйфасын үтәргә тиеш. Димәк ки, без милли дин (татар исламын) «кабул итәргә» мәҗбүр булабыз. Шунсыз безгә дөньяның геосәяси сәхнәсендә урын юк. Андыйларның тарихи язмышы билгеле: иртәме-соңмы алар актив халыкларны тукландыручы туфракка әйләнә

Сүз уңаеннан мәсьәләнең тагын бер ягына тукталып үтү артык булмастыр. Якын киләчәк өчен милли идеябез «Татар күңеле — Далада» шәкелендә булырга тиеш, дидек. Моны гамәлләштерүдә бүрәнәнең авыр башы менталитетыбыздагы «татарчылык»ка төшә, ә аның механизмы ят мохиттә азчылык булып яшәүче сибелгән милләттәшләребез аркылы эшләргә тиеш була. Бу исә хәзерге вакытта халкыбызның ассимиляциягә иң каты бирелгән өлеше. Русиядә хакимият тарафыннан православие дефакто дәүләт дине итеп танылды һәм гражданнарга укыту-тәрбия учреждениеләрендә, дәүләт органнарында ихтыярый-мәҗбүри рәвештә тагыла. Мондый шартларда сәүит чорында ислам традицияләреннән аерылган татарлар арасында чукыну очраклары да аз түгел. Моңа каршы нәрсә куя алабыз? Тик исламны гына. Әмма монда проблема туа, чөнки ислам бер генә төрле түгел. Дөньяның империячел көчләре безгә, бер яктан, исламның татар традицияләренә ят булган мәзһәбләрен тагарга тырыша, икенче яктан, моның өчен безне гаепләп, милли хәрәкәтне богаулау чараларын күрмәкче. «Татар исламы» төшенчәсен кабул итү безгә каршы көчләрнең кара ниятләренә каршы тору коралы да ул.

Татар исламы, традицион (төрки-гарәби) исламны төрек, гарәп, фарсы империячел көчләре буйсындырылган халыклар белән идарә итү өчен таккан, ШГИТ буенча өченче дәрәҗәле сәяси (әйтик, газават кебек бүгенге планетар акыл кабул итә алмаган) категорияләрдән арындырып, аның илаһи-тәгълимати ягын (Коръән) истә тота. Татар исламы атлантизмның либеральлеген һәм кеше хокукларын да, халыклар хокукларын да, марксизмның интернационализмын һәм социаль гаделлеген дә, аларның табигый нисбәтләрен саклап, үз эченә сыйдыра һәм Фукуяма вариантындагы мондиализмның идеологик нигезе була ала.

Татар менталитетындагы болгарчылыкка «татар исламы» идеясен өстәсәк, ул мең елдан артыграк дәвердә тупланган милли мәдәни хәзинәбезне барлау, аны үстерү, милли иммунитетны ныгыту булыр. Менталитетыбыздагы бүгенге ассимиляция сәбәпләренең берсе булган татарчылык, татар исламына нигезләнсә, ул, мәдәниятебезнең кыйммәти югарылыгын күрсәтеп, Ходай йөкләгән геотарихи вазыйфабызны үтәүгә этәрүче рухи-ихтыярый көч бирәчәк. Иншалла, шулай булыр!

«Татар исламы» терминын куллануның хаклыгына һәм урынлылыгына дәлилләрне күпләп китерергә булыр иде. Әмма, темабыз геосәясәт турында икәнен истә тотып, фикер сөрешен артык чуарландырмау максатында әйтелгәннәр белән чикләндек.

МИЛЛИ ХӘРӘКӘТНЕҢ ТАРИХЫ САБАКЛАРЫ

Югарыда язганнар глобаль сөреш тенденциясенә нигезләнде. Ә бит тарих кешелек цивилизациясе үсешенең киң һәм туры юлында кайбер халыклар язмышы гел уңышлы юлдан гына бармавын, вакытлы борылышлар, хәтта чигенешләр булуын да белә. Алар планетар масштабта глобаль сөреш кысаларыннан чыкмасалар да, тарих агымы чоңгылына эләккән милләтләрне батырып калдырырга да мөмкин. Әйтик, Русиядәге бүгенге сөрешләр әле генә башланмады бит. Гумилев империя кризисы башын XIX гасырның уртасы белән билгели. Ә шулай да, үз векторын саклаган хәлдә империя үсеше һәм аның белән татар юлы да нинди борылыш ясап алды. 70 еллык сәүиг чорында татарның элитасы кырылып, үзе дә юкка чыгу куркынычы астында калды. Алда да андый борылышлар булмас дип кем әйтә ала? Русиянең сәяси тормышындагы соңгы вакыйгалар күрсәткәнчә, моның ихтималы зур. Хакимияткә мондиалистларның үзенчәлекле төркеме килде. Тышкы сәясәттә алар-атлантизм тарафдарлары, Көнбатышка йөз тотучылар, эчке сәясәттә исә — централизм ягында. Алар фикеренчә, Русияне реформалауны тизләтергә кирәк һәм монда төбәкләрне Мәскәүнең рәхимсез сәясәтенә каты буйсындырып кына ирешеп була. Алар регионализациягә каршы, чөнки, алар уйлавынча, төбәкләргә ирек бирү, аларның сепаратизмына юл кую урыннарда хакимияткә либераль реформаларны (базар системы урнаштыруны) тоткарларга омтылучы көчләрнең килү куркынычын тудыра.

Аларның сәясәте халыкара капиталның икътисадый ихтыяҗларына нигезләнгән. Постсовет пространствосы халыкара капитал өчен мондагы искитмәле уңай шартлары белән дөньяви олигархларны инде күптән кызыксындыра. Ләкин алар бу төбәккә акчаларын кертергә куркалар: монда коррупция, законнар төрлелеге, җинаятьчелек — андый шартларда акчаңнан колак кагу гына түгел, башыңны да җуярга мөмкин. Һәм алар ашыктыра: тәртип урнаштыруны тизләтергә — коррупцияне бетерү өчен төбәкләр хакимнәрен алмаштырырга, ә яңаларының хакимлек вакытын чикләргә, бөтен пространствода бер төрле хокукый кыр урнаштырырга, җинаятьчелекнең бугазына басарга...

Боларны башкару каты куллы түрәләргә тапшырыла. Соңгылары үз карьералары һәм шәхси ихтыяҗлары турында кайгыртып, глобаль сөрешкә каршы чыгарга да мөмкин (тарихта андый очраклар еш кабатлана). Дөрес, әгәр ул юлга бассалар, алар һәлакәткә дучар булачак (троцкийчылар, зиновьевчылар һәм буха-

ринчылар кебек). Әмма татарга да алар китергән зарардан арыну авыр булачак.

Кыскасы, Җиһанда бара торган глобаль сәрешләр татар өчен эшләми һәм автоматик рәвештә безгә хөрлек тә китерә алмый. Милли хәрәкәт, әлеге сәрешләрнең безгә кулай якларыннан файдаланып, милләт мәнфәгатен даими кайгырткан һәм милли көрәш инициативасын кулында тоткан очракта гына көтелгән нәтиҗәгә ирешә ала. Бу җәһәттән бездән милли хәрәкәтебезнең тарихи сабакларын истә тотып эш итү сорала. Нинди соң ул сабаклар? Моңа җавап эзләү йөзеннән милли хәрәкәтнең характерлы өч чорын алыйк: XYI гасырның уртасы, XX гасырның башы һәм азагы. Алар шуның белән үзенчәлекле: язмышыбыз өчен хәлиткеч әһәмиятле борылыш елларында милли хәрәкәт каршы көчләр белән торышырлык куәтле булып та татарны җиңүгә китерә алмаган. Аларда вәзгыять тә, максат-бурычлар да, көрәш ысуллары да төрле, ә нәтиҗәсе уртак — урыс белән татар көрәшендә гел беренчесе өстенлеккә ирешеп килгән. Ни өчен шулай?

Милли сыйфатларыбыз гаепле диючеләр бар. Алайса ни өчен борынгы бабаларыбыз заманында гайрәтле була алганбыз — ул чакта да шул ук сыйфатлар булган түгелме? Инде әгәр үзгәрә төшкәнбез икән, аның да сәбәбен ачыкларга кирәктер. Фикеребезчә: сәбәп милли сыйфатта түгел. Анысы икенчел, ул — милли аңдагы психологик куелыш нәтиҗәсе генә. Бәс, сәбәп менә шушы куелыштамы?! Милли хәрәкәт моңарчы һәрчак бер әйбергә барып тәртәлә килде, үзен бер нәрсә белән чикләде. Ул — тарихи хәтер мәсъәләсе. Тарихи хәтер һәм шуңа тәңгәл геосәяси куелыш — менә нәрсә җитмәде моңарчы милли хәрәкәткә: татар төрки бабаларыбызның васыятен үтәмәде, үзен Дала хуҗасы буларак тотмады. Шуңа күрә һәрчак җиңелә килде.

Моны дәлилләүче мисаллар бихисап. Мәсәлән, халык иҗатында чагылыш тапкан татарның сәяси беркатлылыгын һәм олкән абзыйга ышанучанлыгын алыйк. Моның классик мисаллары итеп 1551 елны Сөембикәне Мәскәүгә озатуны, 1918 елны «Идел-Урал» штатын Татар-Башкорт Республикасына алмашуны һәм Референдумда расланган Декларацияне 1994 елда Шартнамәгә алмашуны китерергә була. Болар барысы да — милли хәрәкәтнең инициативаны Мәскәүгә бирүе, шуның белән алдануы мисаллары. Бу юл милли хәрәкәтне әлек тә уңышка китерә алмады, хәзер дә китерә алмый. Шуңа да карамастан ни өчен татар һаман да бер ялгышны кабатлый, ни сәбәпле башкача хәрәкәт итәргә башы җитми? Чөнки аның күңелендә «Мин — Дала хуҗасы» дигән тарихи хәтер җуелган. Казан ханлыгы варислары

гынамы без, әллә Алтын Урданыкыдамы — бу мәсьәләдә татар башында дөрес фикер куелышы юк.

Урыс геосәясәтчеләре моннан оста файдалана — алар үз империяләрен Алтын Урданың дәвамчысы буларак күрсәтеп, шуның белән аның тарихи легитимлыгын расларга тырыша. Шушы «фәнни» карашка ияреп, кайбер татар галимнәре дә, XYI гасырдагы Мәскәү-Казан көрәше Алтын Урда мирасы өчен барган, дигән фикерне алга сөрә. Бу дөрес фикер, тик Казан өчен генә. Мәскәү исә Алтын Урданы җимерү һәм аның җирләрендә башка динле вә культуралы, капма-каршы менталитетлы Өченче Рим төзү өчен көрәшкән. Бу җәһәттән РФА президенты Г.В.Осипов болай яза: «После разгрома монголо-татарских завоевателей была выдвинута известная теория «Москва, Московская Русь — Третий Рим»... Она лежала в основе образования русского централизованного государства на огромных пространствах»[37]. Күрәбез, урыслар Алтын Урда варислыгына дәгъвә белдерергә хаксыз. Димәк, татарлар һәм алар гына Алтын Урда варислары булып санала ала[38].

«Кем Дала хуҗасы?» мәсьәләсенең дөрес хәл ителмәве милли хәрәкәтнең башка эшчәнлегендә дә чагыла. Әйтик, XX гасырның башында да, хәзер дә татар буржуазиясенең активлыгы, кыюлыгы һәм тәвәккәллеге җитми. Бу милли буржуазиядә (гомумән татар милли аңында) Дала хуҗасы дигән үзтиңләнү булмаудан килә. Монысы исә үз чиратында мәдәни һәм сәяси карашларда буталчык сакланудан, мәдәниятнең үз закончалыклары, сәясәтнеке үзенеке икәнен аңламаудан һәм шуның аркасында мәдәни болгарчылык белән сәяси болгарчылык арасындагы аерманы күрмәүдән килә. Мәдәни болгарчылык безнең милләтнең культурасын үстерә, ә сәяси болгарчылык аның инициативасын чикли, сәяси татарчылык канатын кисеп, милләткә югары культуралы һәм беренче сортлы халыклар рәтенә күтәрелү мөмкинлекләрен киметә. Татар милли хәрәкәте мәдәни болгарчылык һәм сәяси татарчылык мәсләгендә эш иткәндә генә тиешле уңышка ирешә алачак. Ягъни азатлык вә хөрлек юлында татарның мәдәни йөген менталитебыздагы болгарчылык, ә сәяси йөген татарчылык тартырга тиеш.

Мәдәният белән сәясәт чикләрен күрә белмәү галәмәте төркичелек һәм исламчылык мәсъәләләрендә дә ачык чагыла. Әлеге һәр өч чорда да татар төркичелек һәм исламчылык мәсләген мәдәниятгә генә түгел, сәясәттә дә кулланган. Һәм ялгышкан. Геосәясәт фәне дәүләтчелек мәсъәләсендә яшәү җирлегеннән чыгып һәм милләтләрнең үзтиңләнүен исәпкә алып эш итәргә куша.

Канкардәшлек һәм динкардәшлек мәсьәләләре исә мәдәни хезмәттәшлек, культура өлкәсендә генә уңай нәтиҗәгә китерә ала. Шул ук мәсләкләрне сәясәткә күчерергә теләсәң, иң әүвәл карарга кирәк, пространствога бәйле ихтыяҗлар кисешмиме. Сәясәт белән мәдәнияттә бер үк мәсләк эшли алмый, чөнки беренчесе — ихтыяҗлар көрәше, икенчесе ихтыяҗлар хезмәттәшлеге. Димәк, культура уртаклыгына нигезләнгән сәяси якынлык ихтыяҗлар кисешмәгәндә һәм бер-берсенә каршы килмәгәндә генә мөмкин. Икенче төрле әйтсәк, мәдәни союзник гел сәяси союзник та була алмый. Әгәр ихтыяҗлар каршы килсә, мәдәни союзник (канкардәш һәм динкардәш) сәяси дошман булырга да мөмкин. Моны XV–XVI гасырлардагы төрекләр сәясәтендә яки XX гасырда туган татар-башкорт проблемасында ачык күрәбез [39]. Сәяси ихтыяҗлар тәңгәл килүенә-килмәвенә карап, канкардәш вә динкардәш төрекләр һәм башкортлар сәяси көрәштә йә безнең белән, йә безгә каршы булган.

Азатлык көрәше тарихыбыздагы тагын бик гыйбрәтле сабак һәм «кем-кемне?» дигән сорау кабыргасы белән куелган чакларда хәлиткеч роль уйнаган фактор — ул сыйнфый антогонизм. Сыйнфый көрәш аркасында татар борылыш елларында туган мөмкинлекләрдән файдалана алмады. Үз-үзен һәлакәткә дучар итеп килде. Бу проблема бөтен милләтләргә дә хас, чөнки аның тамыры ихтыяҗларга барып тоташа. Ихтыяҗларга кагылышлы проблемаларны, бездә күпләр күзаллаганча, милли аң тәрбияләү белән генә тулысынча хәл итеп булмый. Ихтыяҗлар канәгатьләндерелмәсә, һәрчак сыйнфый каршылыкка урын кала һәм, шулай булгач, антогонизм чыганагы да саклана. Димәк ки, проблеманы хәл итү юлы бер генә — сыйнфый ихтыяҗларны канәгатьләндерү. Мөмкинме бу? Кешелек тарихы монда ике юл белә. (Марксизм тәкъдим иткән өченче юл — сыйныфларны бетерү тормышта раслану тапмады). Беренчесе — Көнбатыш Аурупа илләре юлы (дәүләти система). Анда милләтләр үз мөстәкыйль дәүләтләрендә яши һәм дәүләт институтлары аша законнар тәртибендә (салым, социаль ярдәм, эш белән тәэмин итү һ.б. системалар ярдәмендә) сыйнфый ихтыяҗларны канәгатьләндерү чарасын күрә. Икенчесе — яһүдләр юлы. Алар үз дәүләтләрендә генә яшәми, бөтен дөньяга сибелгән. Аларда — эчке үзидарә (милли үзидарә системасы). Аның асылын социаль катламнарның ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә үзара милли бәйлелек тәшкил итә. Ягъни ул милләткә нигезләнә һәм һәр социаль катламның үз милли вазифаларын үтәп вә үзара ярдәмләшеп яшәвен күздә тота. Безгә шушы соңгы принциптагы милли яшәеш системасын булдыру зарур.

XX гасыр башында бездә дә исламга нигезләнгән милли үзидарә системасы булган булуын. Ләкин ул сәяси мөстәкыйльлеккә ия булмаган — аның башында империя мәнфәгатьләрен яклаучы һәм аның дәүләти структураларына кергән мөфтият торган. Андый система (ул бүген дә гамәлдә бит) милләтне саклауга ярдәм итә, әмма аның энергиясен мөстәкыйльлеккә вә тәрәккыятькә юнәлтми, киресенчә, геосәяси мөстәкыйльлеккә омтылыш тудырмауны күздә тота. Бәйсез дәүләтебез булмаган шартларда исән калу һәм үсеш алу өчен безгә дини, мәдәни, мәгариф, сәяси, икътисадый-социаль мәсъәләләрнең барысында да мөстәкыйль булган милли үзидарә (милли яшәеш) системасы кирәк. Ул булса, бүгенге таркаулык, уртак кыйбла билгели алмау, киләчәккә юлыбызны күзаллаудагы чуарлык, милли оешмаларның үзара көрәше, «өлкән абзый» мәрхәмәтлегенә өметләнеп ят көчләргә иярү яки аннан куркып сәяси битарафлыкка бирелү кебек күңелсез күренешләргә урын калмас иде.

Татарның милли яшәеш системасы яһүдләр үрнәгендә булсын иде дисәк тә, ул беркемнекен дә кабатламаска тиеш. Чөнки безнең үз яшәү җирлегебез, үзгәле менталитетыбыз һәм милли сыйфатларыбыз бар. Әйтик, безгә теге яки бу мәсьәләне хәл итү сөрешендә каршы көч белән килешү тапканнан соң сүлпәнәю һәм мәсьәләгә карата игътибар кимүе хас. Бу менталитебыздагы толерантлык, каршы көчне дә дошман күрә белмәү, каршылыкта гармония эзләү һәм тапкач тынычлану хасиятенә бәйле. Татарның сәяси баркатлылыгын күрсәтүче югарыда китерелгән классик мисаллар сәбәбе дә, төптән карасаң, менә шундый үзгәле милли сыйфатыбызга барып тоташа. Моны истә тотып, милли яшәеш системасы идеологиясе һәм аның стратегиясе шундый булырга тиеш ки, анда милләт максаты бөтен кешелек мәнфәгате югарылыгына күтәрелсен, аңа ирешү вакыты гасырларга сузылсын. Ул чагында милләт алдында шундый зур стратегик план кысаларында булган тактик бурычларның һәрдаим яңаларын куеп торып, аңа «тынычланырга» ирек бирмәскә дә булыр иде. Милли үзидарә системасы, татар исламына нигезләнеп, милләт үзенең яшәү максаты итеп үзен саклауны генә түгел, ә Дөнья имин-леген кайгырту һәм кешелеккә глобаль кризистан чыгу юлын күрсәтү миссиясен дә таныса һәм дә ки аларга ирешү өчен милли хәрәкәт, үз алдына вәзгыятькә тәңгәл яңадан-яңа бурычлар куеп, милләтне «тыңгысызлап» торса, гафләттән бер арынган халкыбыз үзенең тарихи юлында яңадан йокымсырап-сөйрәлеп бармас иде.

Милли сыйфатларга килгәндә, гомумән, башкаларга ияреп, аларны «төзәтергә», «яхшыртырга» тырышу табигатькә каршы

көрәшүгә тиң. Чөнки милләт үзенең асыл сыйфатлары белән табигать кочагында формалаша һәм үзе дә табигатьнең аерылмас бер кисәге булып тора. Милли сыйфатларны үзгәртергә тырышканчы (сүз асыл сыйфатларыбыз турында бара, әхлаксызлык, эчүчелек, наркомания һ.б.ш. хәзерге ямьсез бозыклыклар алар рәтенә керми), аларны үз файдабызга куллану юлларын эзләсәк, отышлырак булыр. Моның өчен иң әүвәл геосәяси офыгыбызны киңәйтү зарур. Мәсәлән, болгарчылар бөтен фаҗиганы татарчылыкта күрә, аларга шуннан арынсак һәм исемне алыштырсак, милләтебез ал да гөл яшәячәк күк тия. Әгәр бу мөмкин булса, милләтпәрвәр татарның кайсы гына риза булмас иде микән моңа? Әмма бу мөмкин түгел. Һәм кирәк тә түгел. Чөнки милләтебезнең татарчылыгы бетсә дә, болгарчылыгы юкка чыкса да, ул инде без булмыйбыз. Ул чагында исеме татар буламы яки болгармы, ә җисеме белән башка милләт туа. Бу исә башка җирлектә һәм башка тарихи шартларда гына мөмкин булыр иде. Монысы инде Аллаһы кодрәте белән генә эшләнә ала. Дөньяга карашны, бүгенгедәй империя каккан чикләр тарлыгында (Татарстан суверенитеты) калдырсаң, чынлап та татарчылык тискәре сыйфат булып каралырга тиеш. Әгәр инде сәяси фикерләү вакытында, күцел кошын империя читлегеннән чыгарып һәм дөньяга карашны дөнья киңлегендә, үз мәгънәсендә Аллаһы биргән пространствога җәелдерсәң, бүген Даланың нинди авыр хәлдә булуын һәм аны ятлар кочагына ташлаганы өчен татарга рәнҗүен күрәсең, аның Тәңре билгеләгән үз хуҗасыннан ярдәм сорап ыңгырашуын, империя богауларыннан арындыруын сорап ялваруын ишетәсең... Ул чагында татарчылык милләтнең күркәм сыйфатына әверелә.

Саный башласаң, тарихи юлыбыз сабаклары бихисап. Аларның бөтесе өчен бер уртаклык бар: аларның асылында мирасиварисы үзтиңләнү ята. Үзеңнең кем варисы һәм нинди мираска хуҗа икәнеңне белмәгәндә — танымаганда ул шулай булырга тиеш тә: сәяси ихтыяр вә инициатива да кирәк түгел, бердәмлек тә зур кыйммәткә ия булмый, битарафлык вә сүлпәнлек тә табигый. Яшәгән җире өчен үзенең җаваплылыгын таныган хуҗа исә каршы көчләргә иярми, ә ияртә, инициативаны үз кулында тота, үз язмышын үзе хәл итә. Милләт алдында торган бүгенге төп геосәяси комачау — ул Алтын Урда варислыгына уңай мөнәсәбәт җитмәүдә. Андый үзтиңләнүгә ирешү һәм шуңа милләткүләм тугрылык саклау — милли идеологиянең сәяси векторы менә шундый булырга тиеш.

Әгәр милли идеологиябезнең төбе Далага нигезләнгән, ә күге татар исламына терәлгән булса, милләтебез җирдән куәт алып

торган Ахиллес һәм күктән изге киңәшләр иңдерелеп торган Геракл-Геркулес сыман, җиңелмәс көчкә әверелер.

Милли хәрәкәтнең геосәяси кыйбласын билгеләгәндә Русиядәге соңгы сәяси сөрешләрнең тенденциясен дә исәпкә алу кирәк булыр. Анда хакимлек итүче мондиалистлар өчен милли мәнфәгатьләр юк, алар өчен төп кыйммәт-либеральлек. Әйтергә кирәк, бу АКШ һәм Көнбатыш тарафыннан да яклау таба. Безнең өчен дә алар варианты державачыларга караганда кулайрак — ул дәүләтчелек үсешен чикләсә дә, мәдәният үсешендә мөстәкыйльлек бирә, милли буржуазиягә аякка басу мөмкинлеге калдыра. Ә бу тора-бара барыбер милли үзбилгеләнү максатында милли хәрәкәтнең яңа күтәрелешенә китерәчәк. Хәлбуки, бу вариантның куркыныч ягы да бар — большевикларга ияреп ялгышкан кебек тагын алданмабызмы? Эш шунда ки, мондиалистлар бер вариантта гына эшләми: сәяси классификациядә беренчеләр — уңнар, икенчеләр — уртада, өченчеләр — сулда. Барысының да ахыр максаты бер — империяне реформалау. Соңгы вакыйгалар тенденциясе күрсәткәнчә, алар альтернатива булганда һәрчак унъяк максималистларга өстенлек биреп килде (Горбачев түгел — Ельцин, Примаков түгел — Путин).

Күрәбез ки, алар мәнфәгате милли һәм социаль мәсьәләләрдә безнекенә гел үк тәңгәл килми. Шуңа күрә, хәзерге шартларда милли хәрәкәт мөслеге шундый булырга тиеш: милләтне һәләкәткә дучар итмәслек формада мондиалистларны яклау. Ягъни мондиалистлар Русия атын дагалаганда татар ботын кыстырмый гына (бер якка да идеологик дәрәҗәдә иярми генә) үз мәнфәгатебезне яклау турында кайгыртырга тиеш (дәүләтчелекне ныгыту һәм киңәйтү, мәдәниятебезне үстерүдә кыюлык вә тәвәккәллек күрсәтү, ләкин көч куллануда нейтральлек саклау аркылы).

Атлантизмның икътисадый-сәяси ихтыяҗларына нигезләнгән глобальләштерү социаль тормышта инглиз телле Көнбатыш культурасын (таррак алсак, Американыкын) тагу юлы белән алып барыла. Бу уңайдан милли хәрәкәт үсешенең соңгы дистә ел сабагын да исәпкә алу зарур. Әлеге сабак шуны күрсәтә: милли аңыбызда татар культурасының югарылыгын-өстенлеген тану җитеп бетми (монда аның сәбәпләрен аныклауны күздә тотмыйбыз алар күптәрле). Шул сәбәпле культурологик кыйбла алмашуда урыс мәдәниятеннән үзебезнекенә күчүгә караганда Америка суррогатына мөкиббән китү көчлерәк сизелә. Бу — милләтне саклау мәсьәләсендә бер куркынычны икенчесенә алмаштыру дигән сүз. Моңа каршы чара бармы? Бар, ул — милли яшәеш системасын оештыру. Шунсыз бүгенге яшәү шартларында татар-

ның берничди милли идеяне дә гамәлләштерү мөмкинлеге юк. Хәер, хәзерге коммуникацион шартларда бу сибелгән татарга гына кагылмый. Үз дәүләтләрендә укмашып яшәүче милләтләрне дә милли яшәеш системасы белән ныгытылган милли культура гына ассимиляциядән саклый алачак. Юкса, глобаль сөреш аларны де йотачак.

Әлеге система нинди булырга тиеш соң? Ул тормышның мөстәкыйль яшәү өчен кирәк булган милли аң һәм мәтди ягын исәпкә алып корылырга тиеш. Гомумислам дөньясында эремәү һәм урыс чукындыруына бирешмәү максатында милли яшәеш системасы ролен элегрәк суфичылык үтәгән (мәсәлән, Ш. Мәрҗани заманнарында). Ләкин хәзерге шартларда ят культуралар агрессиясенә каршы тору өчен суфичылык бирә торган рухи тәрбия генә җитми, аның өстенә милләт катламнарының иҗтимагый-сәяси, икътисадый-социаль яктан да үзара бәйлелеген тәэмин итәргә кирәк. Бу ягын гамәлләштерү өчен җитештерү сәүдә, финанс өлкәләрендә базар системасы тудырган яңа мөмкинлекләрдән киң файдаланырга кирәк.

ЙОМГАКЛАУ СҮЗЕ

Геосәясәт халык белән пространствоны, җирлек белән шушы җирдә гасырлар буе яшәп формалашкан җәмгыяви төркемне-милләтне, аерылгысыз бер организм дип карый. Дала географик-климатик шартлары белән планетабызның башка җирләреннән аермалы булган кебек, монда яшәүчеләр цивилизациясе дә үзгәле. Алар төрле этнос вәкилләре булуларына карамастан, аларның барысы өчен бер бик мөһим һәм яшәү өчен хәлиткеч гомуми урталык бар: алар һәрвакыт сәяси (дәүләти) бердәмлек шартларында яшәделәр һәм яшиләр. Аларга ике төрле омтылыш хас. Бер яктан, алар һәркайсы үз мәдәни һәм социаль-икътисадый мөстәкыйльлекләрен сакларга тырышса, икенче яктан, алар сәяси бердәмлеккә омтыла (мәсәлән, бездәге болгарчылык һәм татарчылык шуның чыгылышы). Шушы ике омтылышның нисбәте дөрес канәгатьләндерелгәндә мондагы этнослар чәчәк ата, бу нисбәт бозылса, урталык җирләрендә кризис башлана. Шулай булды Алтын Урдада Мәскәүгә артык мөстәкыйльлек бирелеп, шулай булды СССРда милләтләрнең-төбәкләрнең мөстәкыйльлекләре юк ителеп.

Дала мөстәкыйль геосәяси әһәмияткә ия, ул бүгәләнә алмый. Ул территорияль бөтенлеген һәм сәяси берлеген сакларга тиеш.

Хәзерге шартларда монда дәүләти берлекне ике генә халык саклый ала: урыслар һәм татарлар. Чөнки аларда гына моның өчен җитәрлек миссиячелек бар. Әмма урысларда, шовинизм чире белән авыру сәбәпле, бу миссиячелек империядә әлеге берлекне төбәкләрнең һәм этносларның мостәкыйльлеген юк итү аркылы, «өстән» көч кулланып саклау күздә тотыла, ягъни әлеге нисбәтне бозу юлы белән. Дәүләт тотучының мондый сәясәте Даланы упкын чигенә китереп терәде. Дәүләт төзелешендә татар инициативаны үз кулына алырга, мостәкыйль төбәкләрнең үз теләкләре белән «астан» берләшү сәрәшен оештырырга һәм шуның белән теге нисбәтне оптимальләштерергә тиеш.

Урталык Җирләре берләшәчәк (БДБ илләрен дә кертеп). Бу монда яшәүчеләр өчен генә түгел, бигрәк тә Көнбатыш һәм Үзәк Аурупа, Ерак Көнчыгыш, Һиндстан, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләренең үзара аралашуы һәм алар арасында балланс тоту, шуның белән дөнья иминлеген саклау өчен дә кирәк. Бу берләшүнең дәүләти-милли шарты — күптөрлелек бердәмлегенең бер кисәге булу, икътисадый-социаль шарты -дөньяви базар системасына керү, җәмгыяви-сәяси шарты-либерализм (демократик тәртип) урнашу. Ә геосәяси максаты — кешелек цивилизациясенең үсеш ихтыяҗларын канәгатьләндерү, ягъни диңгез транспортыннан отышлырак булган тимер юл, автомобиль торбаүткәргеч, һава транспортлары хезмәтен җайга салу һәм шуның ярдәмендә Аурәзия халыкларының аралашу — сәүдә шартларын камилләштерү. Бердәмлекне тотучы — татар милләте булачак. Ул шушы миссияне үтәргә әзер үзтиңләнүле вә менталитетлы, үзгә, Урталык Җирләренә генә хас культуралы һәм Көнчыгыш белән Көнбатыш аралашуында вә хезмәттәшлегендә күпер вазыйфасын үтәрлек универсаль цивилизация вәкиле булып туган. Димәк, татарга шушы сыйфатларны тәрбияләрдәй идеология һәм аларга ирешердәй геостратегия кирәк. Татар геостратегиясе төп дүрт векторны билгеләргә, ә идеология дүрт комплекслы сорауга җавап бирергә тиеш.

I. Халыкның үзенә мөнәсәбәте, ягъни үзтиңләнүе (үзенең мескенлеген аңлыймы, коллыктан арыну теләге бармы, моның өчен ихтыяр күрсәтәме...). Татарда моңа уңай җавап бар - без азатлык көрәше аша хөрлек юлына бастык. Бүген моңа тагын бер нәрсәне өстәү сорала: татар милли хәрәкәте мостәкыйль геосәяси субъект роленә лаек һәм, тарихи сабак күрсәткәнчә, шушы рольдә генә ул үз максатына ирешә алачак. Татар дөньясын, Русияне реформалау үзәге вә үрнәге һәм державачыларга каршы көрәштә төп әчке көч буларак, дөнья җәмәгатьчелеге дә таныргa әзер.

II. Милләт үз алдына нинди максат куеп көрәшә, бармы аның стратегик максаты? Милли хәрәкәтнең төп максаты дип милләтнең физик һәм рухи иминлеген саклау, ә моның өчен аны Урталык Җирләрен җыю миссиясенә әзерләү һәм юнәлтүне санарга кирәк. Максатның беренче өлеше буенча милли аңыбызда фикер уртак сыман. Ә инде тулаем алганда, стратегик максатка мөнәсәбәттә — бездә хаос. Уртак максат та, аның планкасы да, аңа ирешү юлы да билгеләнмәгән. Төрле оешмалар (шул исәптән дини һәм дәүләти органнар да) көндәлек проблемаларны чишү, агымдагы вәзгыятькә тәңгәл тактик бурычларны үтәү белән мәшгуль. Уртак стратегия юк. Аны эшләргә, аңа ирешү этапларын һәм юлларын тәгаенләргә кирәклеге ачык. Әгәр шушы хезмәт бу юнәлештә нинди дер этәргеч булса һәм күмпедер импульс бирсә, автор үз максатына ирештем дип саный алыр иде. Бүгенге шартларда стратегик максатка тәңгәл төп бурычлар рәтенә Татарстанның дәүләти мөстәкыйльлеген ныгыту һәм миллелеген тулыландыру янына Зур Татарстанның мәдәни-идеологик суверенлыгына ирешүне өстәү зарур.

III. Хөрлек юлындагы юлдашларыбызга мөнәсәбәт (кем безнең геосәяси дус һәм дошман?). Милли хәрәкәтнең геосәяси дошманнары — теллурократик империяне яклаучылар, дуслары һәм союзниклары — атлантизм тарафдарлары.

IV. Җиһанга, кешелек дөньясының иминлегенә, дөньяви геосәяси ихтыяҗларга мөнәсәбәт, ягъни милли геостратегияне инсаниятнең, хәттә бөтен биосфераның бербөтенлегеннән чыгып һәм анда бара торган сөрешләр тенденциясен истә тотып билгеләү. Бу җәһәттән шуны искәртергә кирәктер. Безгә Русиядәге сәяси-икътисадый сөрешләр Америка сценариендә барачагына шикләнмәскә, әмма АКШ ярдәменә өмет багламаска кирәк. АКШ геостратегиясендә Русия бүленгән, ләкин бердәм булып карала (ягъни аны территориаль яктан таркату күздә тотылмый). Төбәктәге геосәяси дуализмны җитәкләүче һәр ике як (урыс аурразиячелеге һәм Америка атлантизмы) татар факторына карата булган игътибарны арттырачак һәм, әгәр без аларның берсенә дә турыдан-туры иярмичә, ике арадагы каршылыктан файдалану юлын сайласак, милли хәрәкәт ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлеге туачак.

Дөнья үсеше тенденицияләре безнең файдага ага. Иске, дөньяны зур-зур кисәкләргә бүлгәләгән империяләр заманы узып бара. Аңа алмашка Җиһанны берләштерүче планетар Берләшмә (территориаль мәгънәдә) заманы килә. XX гасырда капиталистик империяләр кысасында милли капиталлар киң үсеш алды.

Гасыр азагына капитализм үсеше шундый дәрәҗәгә җитте ки, хәзерге империяләр кысасына сыймый торган планетар капитал барлыкка килде, планетар дәүләт төзү ихтыяҗы туды һәм, шуңа җавап буларак, глобальләштерү башланды. Бу ихтыяҗ континентализм һәм атлантизм каршылыкларыннан көчлерәк һәм аларны үзенә буйсындыра. Неоауразия геосәясәтчеләре (А.Дугин мәктәбе) моны танымый — искегә ябышып ята. Без вазгыятьне аңлап эш итәргә, дөньяви капитализмда үзебезнең куышны әзерләүне хәзердән үк башларга тиешбез. Бер яктан бу милли капитал туплауга керешү, икенче яктан, яңа чорда туачак каршылыкларга әзерлекне кайгырту дигән сүз. Каршылыклар бердәмлеге һәм көрәше законы җәмгыятькә дә хас: җәмгыять никадәр камил булса да, ул каршылыксыз була алмый — бу объектив хакыйкать, үсеш шарты һәм гарантиясе. Дөнья берләшеп, Яңа Т тип аякка баскач, андагы эчке каршылыклар көрәше нәтиҗәсендә яңа бер конвергенция — капитализмның һәм социализмның уңай якларын берләштерү идеясе үсеш алачак. Җиһанның икътисадый һәм геосәяси дилбегәсен тотучы олигархлар моның белән килешмәячәк, үз позицияләрен бирмәскә тырышачак. Аларга каршы бөтен дөнья «пролетарийлары» берләшәчәк. Ягъни, Марксча әйтсәк, планетар капитализм белән планетар хезмәт каршылыгы кискенләшәчәк. (Сүз уңаеннан искәртеп үтик, Маркс-Энгельс тәгълиматы, социализмны бер генә илдә төзү мөмкин түгел, бөтен дөнья масштабында гына аңа ирешеп була, ди. Ленинизм — большевизм — сталинизм гына, марксизмны урыс империясе ихтыяҗларына буйсындырмакчы булып, бу якны күздән төшерде).

Хәлбүки, бу каршылыкны марксизмга нигезләнеп чишеп булмаячак. Чөнки, беренчедән, инде хәзер үк алга киткән илләрдә чиста пролетарийлар юк (анда төп сыйныф — ул урта класс), икенчедән, гамәли социализм Маркс-Энгельс тәгълиматының хакыйкатькә туры килеп бетмәвен, аның кеше табигатен идеаллаштырып каравын һәм гавәмнең динсез яши алмавын күрсәтте. «Җитештерүдә — капитализм, кулланышта — социализм» принцибы яхшырак. Менә шушы каршылыклы принципны килештерә алырдай, дөнья җәмәгатьчелеген гаделлек һәм экологик иминлек өчен халыкара олигархларга каршы туплардай яңа идеология кирәк булачак. Дөньяда шундый бер генә идеология бар. Ул — татар исламы.

Милли идеология формалаштыру башка юнәлешләрне дә истә тотарга тиештер, әмма аның әлеге дүрт векторга нигезләнүе, геосәясәт күзлегеннән, хәлиткеч әһәмияткә ия.

Хәзерге талассократик планетар берләшү чорында теллурократик Русия империясе сакланып кала алмый - кантиненталь Зур Пространство глобаль Зур Пространство тарафыннан йотылырга тиеш. Һәм бу талассократик Зур Татарстанга, теллурократик империя богауларыннан арынып, үз стихиясенә чыгарга мөмкинлек тудырачак. Бу — беркем дә тыя алмый торган объектив процесс. XYI гасырда геосәяси законнар империя төзелүенә хезмәт иткән булса, хәзер алар империянең таркалуын гарантияли. Империя таркалуы Зур Татарстанга ирек китерсен өчен ул үзен, асылына тәңгәл рәвештә, талассократик көч буларак тотарга тиеш. Шулай булганда, XVI гасырда татар дәүләтенең җиңелүе котылгсыз булганы кебек, XXI гасырда татарның «җиңүе» котылгысыз. Нигә соң «җиңү» (ә җиңү түгел)? Чөнки бу очракта татар дәүләтчелеге бәйсез биләмә - дәүләт шәкелендә түгел (ул заманнар үтте һәм кире кайтмаячак), ә планетар Зур Пространство — «Күптөрлелек Бердәмлеге» составындагы «татар төрлелеге» формасында булачак. (Дөнья Хакимияте урнаштырган талассократик Дөньяви Яңа Тәртип кысаларындагы административ милли-мәдәни мөстәкыйльлелек.)

Бүген Русиянең дәүләт төзелешендә ике төрле тенденция күзәтелә. Бер яктан, хәзерге федерация субъектларының хокуклары киселә, рольләре чикләнә. Икенче яктан, яңа административ бердәмлекләр — федераль округлар формалашып килә. Дәүләт структурасы буларак, аларның роле һәм әһәмияте торган саен артачак дип фаразларга бөтен нигезләр бар. Моннан татар милли хәрәкәте шундый нәтиҗә ясарга тиеш: дәүләтчелек идеясен Татарстан чикләреннән Идел буе федераль округы киңлегенә җәелдерергә. Суверенитет ике юнәлештә үсеш алсын: милли бәйсезлек — югарылыкка, ә дәүләти мөстәкыйльлек — киңлеккә. Ягъни Татарстанда, ирешелгән дәүләти суверенитетка нигезләнеп, аның миллилеген үстерергә (дин, мәгариф, мәдәният системаларының тулы бәйсезлегенә ирешү максатында), ә дәүләти суверенитет мәсьәләсендә «Идел буе округына — мөстәкыйльлек һәм миллилек!» шигарен күтәреп чыгарга. Бурыч — аны төбәктә яшәүче халыклар конфедерациясе буларак формалаштыру.

Татар кояшы чыгып килә. Йокысыннан арынып, дөньяга чыккан милләт вәкилләре аның беренче нурлары җылысы тудырган саба җилләрен инде тоемлый. Өченче меңъеллык — татарныкы. Без анда кыю һәм нык адымнар белән керергә тиеш. Аһ-ваһ кылмаска, гел зарланып тормаска, урысны сүгүдән туктарга, мөшкель хәлебез сәбәбен башкалардан эзләмәскә — Аллаһы Тәгалә бар халыкларга да көрәш мөмкинлеге биргән. Ты-

рыш, уйла, бердәм вә оешкан бул, төшенкелеккә бирелмә, тормыштан сабак вә гыйбрәт ала бел, үз көченә ышан, милли культураңның югарылыгына шик тудырма, ана теленә вә әби-бабалар моңына тугрылыклы бул, иманыңа кайт, зирәклек, тәвәккәллек вә активлык күрсәт — синe дә мөстәкыйльлек һәм хөрлек көтә, и газиз татарым!

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] А.Кузьмич. Россия и рынок в свете советского и международного права. (Тайные пружины истории Новосибирск. 1992). «Заман — Татарстан» гәзите. 7 апрель, 2000 ел.

[3] Г.В.Осипов. Россия: национальная идея. Социальные интересы и приоритеты. Москва. 1997.

[4] Сүз Александр Дугин китабы турында бара (Основы геополитики. Москва, 1997).

[5] Мәсәлән, берәүләр аны халыкара мөнәсәбәтләр теориясе (Политология. Энциклопедический словарь. Москва. 1993), икенчеләре сугыш башлануы һәм аның асылы турындагы фәнни нигезсез, ялган концепцияләр (Военный энциклопедический словарь. Москва. 1984), дип бирә. Әйтергә кирәк, геосәясәтне гыйльми караш, фән буларак танымау СССРны һәлакәткә, ә аның закончалыкларын кулланып эш итү Америка ны салкын сугышта җиңүгә китерде.

[6] ГФРның беренче канцлеры К. Аденауэр да моны таныган булса кирәк — ул, Азия Эльбадан башлана, ягъни Эльбадан көнчыгышка таба азиатлар яши (немецләрне да кертеп), дигән фикерне әйткән.

[7] Конституционные идеи Андрея Сахарова. Москва. 1990.

[8] «Локальные войны в сценариях больших геополитических переделов». Материалы конференций. 25 октября 1996 г. Москва. 1996.

[9] Збигнев Бжезинский. «Великая шахматная доска». Москва. 1999.

[10] Мәсәлән, А. Дугинның «Основы геополитики» дигән китабының 212 битендә шул турыда әйтелә.

[11] Аерым геосәясәтче экспертлар тарафыннан андый фикерләр яңгыраш таба башлады инде. Хосусан, А. С. Панарин төрки-мөселман факторын Русия дә, АКШ та үз файдаларына кулланырга тырышачаклары турында яза. («Русский вопрос: проблемы национальной и международной безопасности». Из ма-

териалов научно-практической конференции. Москва, апрель 1995 г.)

[12] Дәрдмәнд. Исә җилләр. Казан. 1980 (36 бит).

[13] Идегәй. Татар халык дастаны. Казан. 1994 (127 бит).

[14] Л.Н.Гумилев. Древние тюрки. Москва. 1993 (26 бит).

[15] Шунда ук (202–203 битләр).

[16] Город Болгар. Очерки истории и культуры. Москва. 1981.

[17] Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр. Казан. 1997 (17 бит).

[18] С. Х. Алишев. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI в.в. Казань. 1995 (18 бит).

[19] З. Бжезинский. Великая шахматная доска (108 бит).

[20] А. Дугин. Основы геополитики. (213 бит).

[21] Урыс менталитетына мондый бәяне алар үзләре бирә. Мәсәлән, М. П. Мусоргскийга багышланган мәкаләсендә Н. И. Компанейский болай яза: «Вообще в нем было чрезвычайно много типичных сторон дарования и характера русского человека. Он был ленив и беспечен, как русский мужик, никогда не думал о завтрашнем дне, в жизни подпирался авоською и небоською». («Будь здоров» журналы № 1, 2000, 100 бит).

[22] Кол Шәриф. И күңел... (77 бит).

[23] Николай Трубецкой. «О туранском элементе в русской культуре». (Панорама-форум. № 1, 1997, 15 бит).

[24] Суверенный Татарстан. Документы, материалы, хроника. Автор-составитель — Д. Исхаков. Том II. Москва. 1998 (101 бит).

[25] «Звезда Поволжья» гәзите, № 1 (4), 2000.

[26] «Казан утлары» журналы. № 12. 1998 (53 бит).

[27] «Мирас» журналы — 3/2000 (64 бит).

[28] «Идел» журналы — 1/99. Миркасыйм Госманов. Тарих фән генә түгел ул.

[29] Панорама-форум, № 12, 1997. Специальный вупуск. Ислам в татарском мире: история и современность (100 бит).

[30] Т.Миңнуллин Агиделгә багышланган биш йөзгә якын җыр җыйган. (Агиделкәй. Халык җырлары. Казан. 1989).

[31] Мәсәлән, Тәлгать Акбашев моны танып кына калмый, «Глубинный потенциал и национальная безопасность» (Казан. 1997) дигән бизнес-план проектында бу юнәлештә конкрет гамәлләр дә тәкъдим итә.

[32] Ризаэддин Фәхреддин хәзрәтләре бу хакта ачынып яза: Кырым ханы Мөхәммәд Гәрәй, Казанны яклап Мәскәүгә һөҗүм иткәннән соң, Мәскәү кенәзе «Василий бу турыда үзен кыерсытылган итеп күрсәтеп, Төркия солтатына Мөхәммәд Гәрәй өстеннән шикаять итте вә шуңа күрә Төркиянең иң шөһрәтле солтаны Се-

ләйман Кануни Русиягә бу рәвештә зарар салмасын өчен Мөхәммәд Гәрәй ханга катгый фәрман бирде». (Ризаэтдин Фәхретдин. Казан ханнары. Казан. 1995. 87 бит).

[33] Болгар милли конгрессының III съездында кабул ителгән Программасында шундый юллар бар: «Никогда в истории человечества не было татарского национально-освободительного движения, ибо не было такого народа и такого государства» (Программа Болгарского национального конгресса. Казань. 1997).

[34] Кара: Ф. Г. Ислаев. Православные миссионеры в Поволжье. Казань. 1999 һәм Габделбари Баттал. Казан төркиләре. Казан. 1996.

[35] Идел-Урал буенда һәм Далада яшәүче төрки халыкларның нәсел башы дип Нух пәйгамбәрнең улы Яфәс санала. Беренче булып Далага ул килеп урнашкан. Аның улы Таргитай (хәзерге телдәге мәгънәсе — «туры айгыр») токымы Урал һәм Алтайга барып җиткән. (Шиһабетдин Мәрҗани, Мөстәфадел — әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар, Казан, 1989, 100 бит. Ризаэтдин Фәхретдин, Алтын Урда ханнары, Казан, 1996, 62 бит. Де tак Рахмати, Дети Атлантиды, Казань, 1999, 12 бит).

[36] Татар менталитеты борынгы төрки бабаларыбызның гаделлеккә нигезләнгән идеологик (тәңречелек) һәм сәяси (хәрби демократия) системасында формалашып, җәмгыятьне милләтләргә бүлеп карауны таңымаучы ислам ярдәмендә чыгытылган. Урыс исә милләт буларак буйсындыруга һәм кеше хокукларын чикләүгә нигезләнгән идеология (православие) һәм сәяси (варяглар урнаштырган империячел тәрт һпле дәүләттә) системада формалашкан.

Татар һәм урыс менталитетындагы бу мәсьәләгә кагылышлы аерманы эт һәм бүре образларына мөнәсәбәттә күрәбез. Эт белән бүре икесе дә бер үк биологик төркемнән, алар бер-береннән кешегә буйсынгач булуы яки иректә яшәве белән генә аерыла. Татар һәм урыс аларга мөнәсәбәтен ничек белдерә? Татарда бөтен ярамаган нәрсә — этнеке: эт шомырты, эт эчәгесе, этлек итү... Урыста — киресенчә: волчья ягода, волчьи законы, волчье логово...

[37] Г. В. Осипов. Россия: национальная идея... (150 бит).

[38] Алтын Урда варислары казакъ яки үзбәк тә түгел. Аларның бабалары, аның үзәк җирләрен ташлап, көнчыгышка күчеп киткәннәр һәм бу Алтын Урданың хәлсезләнүе һәм җимерелүе сәбәпләренең берсе б улган. Сүз әлбәттә, дәүләти мирас турында гына бара. Мәдәни мираска килгәндә, аның,алар белән генә түгел, күп кенә мәсьәләләрдә хәтта урыс белән дә уртак икәнене-

безне (мәсәлән, дәүләт төзелеше культурасында һәм хәрби сәнгатьтә) танырга тиешбез.

[39] Габдельбари Баттал язуынча (Казан төркиләре... 154 бит), 1917 елга кадәр төньяк төркиләр арасында дин, әхлак, холык, гореф-гадәт, йола, тел һәм мәдәният ягыннан, мәдрәсәләрдә гыйлем бирү (мәгариф) өлкәсендә бертөрле дә аерымлану вә читләшү юк иде. Ул башкорт мәсьәләсенең, «бер сәяси төшенчә» буларак, җиргә (пространствога) мөнәсәбәт билгеләгәндә тууы турында яза. Татар милли хәрәкәте «унитарист»лар рәтендә Дала киңлегендәге милли-мәдәни мөхтәрият идеясен яклаганда, башкортлар, «федералист»ларга ияреп, федерация нигезендә төзелгән Русиядә «Мөхтәриятле Башкорт өлкәсе» төзү кирәклеген күтәреп чыгалар. Күрәсең, татар белән башкорт аерымлануы вакыт ягыннан XX гасыр башына туры килсә дә, аның сәяси-мираси тамырын тарихның тирәнрәк катламнарында эзләргә кирәкте р. Күп гасырлар әлек аларның милли аңы яшәү җирлегенә һәм дәүләтенә (сәяси үзтицләнүенә) бәйле рәвештә «Татар күңеле — Далада» һәм «Башкорт күңеле — Уралда» шәкелендә формалашкан.